Мәшһүр ирләр җыентыгыннан 5 нче кисәк

# *Ибне Тәймия*

Туган вакыты: 661 ел 10 рабигуль-әүвәл

Вафаты: 728 ел 20 зуль-кагъдә

Ризаэддин бин Фәхреддин

Оренбургтагы “Вакыт” типографиясе

1911

# Кереш

Коръән Шәриф һәм Сөннәт гыйлемнәренә хезмәт итеп бөтен гомере буенча тәгассуб һәм бидгать белән көрәшкән Ислам галимнәренең берсе Тәкыйуддин Ибне Тәймия булса кирәк. Бу кеше хакыйкать өчен корбан һәм гыйлем юлында шәһид булучылардандыр. Әлеге сәбәптән "Мәшһүр ирләр" җыентыгының бу кисәгендә без Ибне Тәймиянең биографиясен язарга булдык.

Бу көндә Ислам дөньясында мөселманнарны элгәреге мөселманнар гакыйдәсенә туплау, шуңа бәрабәр төрле милләтләр белән өлфәт һәм мәхәббәттә тору хакына тырышучылар бар. Хакыйкый Ислам дине өлфәт һәм дуслыкка дошман булмаган кебек, гыйлем һәм мәгърифәткә дә каршы түгелдер. Коръән Шәриф һәрбер яман гадәттән тыеп, күркәм әхлак белән боерыр, корыган әгъза кебек эшсез һәм көчсез буш ятудан һәм башкаларның хәзинәләрендә булган нәрсәләргә күз текәп һәм борын сузып торудан тыяр.

Ислам дине, раһбанияттан тыйган: "Өстеңдә гаиләңнең дә хаклары бар, аларны сакларга һәм үтәргә тиешле", дип тәгълим бирәдер. Ислам динен камил белеп тотучыларның зиһеннәре саф булыр, алар тәгассубтан ерак булырлар һәм бер-бере белән дуслыкта яшәрләр. Ислам дине ахирәт камиллеген кәсеп итүгә боерыр, ләкин көчле зарурат булмаганда, кешеләр өстенә йөк булып торырга ризалык бирмәс һәм халык файдасына хезмәт итүдән, иҗтимагый тормышны төзекләндереп башка халыклар белән бертигез булудан тыймас.

Шуның өчен, әгәр дә мөселманнар элекке мөселманнар вакытында булган гакыйдә һәм мәсләк тарафына җыелсалар, араларында булган мәзһәб һәм мәсләк тәгассубларыннан (каршылыкларыннан. Тәр.иск.) азат булачаклар һәм бер-бере белән өлфәт һәм әшнәлек булдырган кебек, һәрбер милләт белән дә бертуган кебек тереклек итәчәкләр. Мәдәниятне алга җибәрү хакында да үз өлешләренә төшкән кадәр тырышлык куеп үз икмәкләрен үзләре таба алачаклардыр. Бу көндә булган динне төзәтү мәсьәләсе әүвәлгеләр мәсләге тарафына җыелу хакында иҗтиһад итүдән гыйбарәттер.

Ибне Тәймия шушы мәсләк каһарманнарының берсе булганга, Һиндстан һәм Мисыр матбугатларында әсәрләре күп булу мөнәсәбәте белән тәрҗемәсен (биографиясен. Тәр.иск.) язарга тиешле таптык.

*"Дан кала, китә мал,*
*Һәр заманның үз дәүләте һәм батырлары бар".*

## 1 нче бүлек

### Исеме һәм нәсәбе. Туган җире. Ватаны. Хәрран шәһәре. Бала чагы һәм шөһрәте. Тууы һәм вафаты.

Ибне Тәймиянең исеме Әхмәд бин Габдулхәлим Әбил-Мәхәсин Шиһабеддин бин Габдуссәләм Әбил-Бәракәт Мәҗдеддин бин Габдулла Әби Мөхәммәд бин әл-Хидыр Әбил-Касыйм бин Мөхәммәд бин әл-Хидыр бин Гали бин Габдулла булып, халык кушкан исеме Әбу әл-Габбас, кушаматы Тәкыйуддин, фамилиясе Ибне Тәймия. Хәрран шәһәрендә яшәп, шул шәһәрдә дөньяга килгәнгә, нисбәте "әл-Хәррани" иде. Ерак бабасы булган Әбу әл-Касыйм әл-Хидырның хатыны Тәймия гыйлем әһле, заһидә һәм габидә, хөрмәтле һәм әдәб иясе бер хатын булганга, "Ибне Тәймия" (Тәймиянең улы) буларак танылды. Гомумән бу фамилиянең атаклы кешеләре һәрберсе "Ибне Тәймия" исеме белән билгеледер.

Хәрран Рум тарихларында Караиһ дип искә алынган борынгы бер шәһәрдер. Дәҗлә белән Фурат елгалары арасында (Месопотамиядә) Җәләб суы астында булып, сабийларның[1] мәркәзләре, бөек гыйбадәтханәләре һәм потханәләре шушы шәһәрдә булыр иде.

Хәрран хәзрәти Гомәр заманында гарәпләр тарафыннан яулап алынды һәм ислам шәһәрләренең берсе булып ислам мәмләкәте урталыгында калды. Сабийлар заманында гыйлем чишмәсе булган бу шәһәр, мөселманнар кул астына кергәннән соң бераз вакыт гыйлем мәркәзе булуын дәвам итсә дә, ахырда харап булды. Сабийлардан беркадәр акыл ияләре һәм фәлсәфәчеләр чыккан кебек, мөселманнардан да бу шәһәрдә беркадәр галимнәр, хөрмәтле кешеләр җитешкән. Габбаси хәлифәләр гасырларында тыйб һәм гыйлем китапларын тәрҗемә итүче затларның күбесе шушы шәһәрдән булдылар.[2]

Татарлар басып алганнан соң, Ибне Тәймия гаиләсе белән бөтен китапларын йөкләп, бер кичәдә Хәрран шәһәрен ташлап, 667 елда Димәшкъ шәһәренә күчеп китте. Безнең Ибне Тәймиябез бу вакытта алты яшендәге сабый бала иде.

Димәшкъ шәһәренә килеп урнашканнан соң, Ибне Тәймия укырга, осталыкка ирешергә кереште. Хәтере куәтле һәм гаять аңлы булганга, моның хәлен белүчеләр гадәттән тыш бер кеше булачагын көтәләр иде һәм шулай булды да. 21 яшендә атасы вафат булды.

Ибне Тәймия бөтен барлыгы белән гыйлем кешесе булып, дөньяда булган ләззәте гыйлем алудан гыйбарәт иде. Караламасыз язган әсәре сәгате белән халык арасына таралыр, һәркем күчермәсен алыр өчен җан атып торыр иде. Мәҗлесе саф гыйлем мәҗлесе булып, гайбәт, кирәксез, артык нәрсә һәм уен булмас иде. Шул сәбәпле гыйлем сөючеләр аның мәҗлесендә булуны үзләре өчен табыш саныйлар иде.

Ибне Тәймия ата-анасын бик ихтирам итә, үзе гаять күндәм һәм канәгатьле, дөньяга илтифатсыз һәм гыйлемгә иҗтиһадлы, гүзәл холыклы, шәригать чикләрен саклаучы иде. Һәрвакыт яхшы гамәлләрне үтәргә боерыр, начар гамәлләрдән тыяр, гыйлем белән гамәл кылудан ялыкмас, укудан туймас, өйрәнмичә һәм эзләнмичә тормас иде. 30 яшендә 691 елда хаҗ кылды.

Кешеләр күп вакытта үзләре арасыннан берсенең югарыга үсүен күтәрә алмаслар. Бигрәк тә соңгы гасыр мөселманнарында үзләренең тиңдәшләренә хәсетләнү һәм көнләшү, форсат булу белән җәбер-җәфа китерү гадәткә әйләнгәндер. Шушы сәбәптән Ислам әһле

---

[1] Йолдызларга гыйбадәт кылучы бер кавем булып "Сидра раббә" исемендәге бер китап белән гамәл кылалар. Телләре гарәп теле булып бу көндә 5000 кадәр җандыр

[2] Гарәп мөәллифләреннән һәм уйлап табучыларыннан булган Сәбит бин Курра әл-Хәррани шушы шәһәрдән булган сабий иде.

арасында чынлыкта камиллек һәм олугълык иясе булган затлар якыннарының фетнәләре астында михнәт күреп гомер сөрергә мәҗбүрләрдер. Бу гадәттән Ибне Тәймия дә котылмады, гасырдашлары аңа да каршы тордылар, үзен һәм әсәрләрен халык күзеннән төшерер өчен һәрбер чаралар күрделәр.

Дин сәүдәгәрләренең гореф-гадәтләре мәгълумдер: җаһилләр арасында үзләрен динле күрсәтү. Шул сәбәпле икмәкләренә май ягу нияте белән башкаларның күңелләренә борын төртерләр һәм имансызлыкларын игълан кылырлар һәм икенче яктан әләкләрләр. Хөсетлек чире, көнчелек хасталыгы өчен бердәнбер дәвалар шушы нәрсәләрдән гыйбарәттер. Бу хәлләр нәкъ шулай ук Ибне Тәймия башына да төштеләр.

Ибне Тәймия никадәр акыллы кеше булса да, йомшак күңелле, эчкерсез һәм һәркемгә яхшылык теләүче булганга, үзенә карата булган мәкер һәм хәйләләрдән хәбәре булмас, бәлки һәрвакыт укыту һәм язу белән мәшгуль булыр, Ислам дәүләтләренең татарлар тарафыннан туздырылуына, җимерелүенә янып-көеп утырыр иде.[1]

Ибне Тәймия дин өчен сугышып йөргән вакытта динче муллалар аңа каршы көрәштеләр, әсәрләренең таралуына чыдый алмаслар, көнчелек ялкыннарына салкынлык бирү теләге белән үзләренең гадәтләре буенча әләк һәм донос ясап торырлар иде.

Татар сугышлары басылганнан соң хөкүмәт тарафыннан Ибне Тәймия кулга алынды һәм тоткын хәлендә Димәшкъ төрмәсендә вафат булды. Бертуганы Шәрәфеддин янында җирләнгәндер. Аллаһ туфрагын җиңел итсен һәм барасы урынын җәннәт кылсын.

Ибне Тәймиянең тууы 661 (1263) елның рабигуль-әүвәл аеның 10 нчы көнендә (январь аенда) булып, вафаты да 728 (1328) елның 20 нче зуль-кагъдә дүшәмбе кичендә (сентябрь) 67 яшендә иде. Җеназасына бөтен Димәшкъ халкы чыгуы, каберенә озатып баручыларның сан вә хисабы булмавы риваять ителәдер. Тарихчылар хәбәрләрендә арттыру булмаса, Ислам дөньясында халык күп булу белән аерылып торган ике җеназа булып, бере Багдадта Әхмәд бин Хәнбәл җеназасы һәм икенчесе Димәшкътә Ибне Тәймия җеназасыдыр. Кабере “суфилар каберлеге” дип аталган урында билгеле.

Шунысы гаҗәп, бидгатькә каршы көрәшүе сәбәбенннән төрмәдә ятып вафат булган Ибне Тәймиянең соңгы юлга әзерләнүе һәм кәфенләнүе үзе риза булмаган бидгатьтән башка гына булмады. Җеназасында кешеләрнең кычкырып елаулары, киемнәрен ертулары һәм госелдән арткан суын бәрәкәтләнү нияте белән үз араларында бүлешүләре, башында булган түбәтәен бәрәкәт алу нияте белән варисларыннан зур акчаларга сатып алулары Ибне Тәймия риза булмаячак бидгатьләрдән иде. Әгәр үзләренә кылынган вәгазь-нәсыйхәтне үтәсәләр, алар өчен хәерле булыр иде.

## 2 бүлек

### Гаиләсе һәм нәселе. Нәселендә булган мәшһүр затлар.

Ибне Тәймия үз гомерендә хатын алмас, җария тотмас, табигый балалары да калмастыр. Ибне Тәймиянең нәселе гарәп кабиләләре эчендә гыйлем вә әдәб белән мәшһүр булып, бу йорттан һәрвакыт билгеле затлар чыгып килгәндер. Ибне Тәймия гыйлем һәм фазыйләтне, әдәб вә кәмаләтне очраклы рәвештә түгел, бәлки нәселдән килү юлы

[1] Мәшһүр Шәхкаб вакыйгасында әһле Исламны сугышка өндәде һәм үзе иң алдагы сафта торып сугышып йөрде. Җәбәл Лүбнән сугышында башыннан ахырына кадәр дәвам итте. Бу вакыйгаларда Ибне Тәймиянең кылычы каләме дәрәҗәсендә кискен икәнлеге мәгълум булды.

белән алгандыр. Анасы Ситтә әл-Нигәм бинт Гәбдус әл-Хәррания гүзәл әхлаклы һәм изге хатыннардан иде. (716 елда шәүвәл аенда вафат булды).

Ибне Тәймия гыйлем әһелләренең сөтләрен имеп җитешеп, кәмаләт әһелләренең күз уңнарында тәрбия алган. Моңа дәлил итеп бу нәселнең кайбер мәшһүр затларын бу урында язсак зарар булмас, алар исә түбәндәгеләр:

1) Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Әбил-Касыйм әл-Хидыр бин Мөхәммәд бин әл-Хидыр. Фәхреддин дип атап йөртелгән бу зат Ибне Тәймиянең бабасы булган Габдуссәләм бин Габдулланың агасының улыдыр. Хәрран шәһәрендә 532 елда дөньяга килеп, 621 елда шул шәһәрдә вафат булды. Багдад шәһәренә барып Әбу әл-Фәтех бин әл-Мәнә исемле заттан фикһ һәм Шәһдә бинт әл-Ибри исемле хатын белән Ибне әл-Мукарраб, Ибне әл-Баттый исемле билгеле шәхесләрдән хәдис гыйлемен алды. Үзе мәгълүм галимнәрдән саналыр иде. Әхмәд бин Хәнбәл мәзһәбенә хас буларак бер мохтасар язып, бу турыда булган гыйлемне мәйданга куеп һәм Коръән-Шәриф буенча бер тәфсир дә яза. Сүз сөйләргә оста һәм мөлаем булганга халык һәм түрәләр аны яраталар иде. Хәрран шәһәрендә вәгазь сөйләү белән мәшгуль булганга, әл-Вәгыйз дип мәшһүр булды. Һәркөн мәгълүм сәгатьтә тәфсирдән дәрес укытыр иде. 603 елда хаҗга барганда Ирбил шәһәренә керде, шушы сәбәптән Ирбил шәһәренә хас кайбер тарихларда тормыш юлы язылган.

Ибне Нәбәтә хөтбәләре рәвешендә хөтбәләре һәм бер шигырь диваны бардыр.

*Сезгә сәлам бирәм, үткән инде үтте,*
*Сез риза түгел аерылуыма.*
*Югалганнан соң минем хакта сорагыз төннән:*
*Күзләрем минем талдымы йокыга,*

бәете әлеге затныкыдыр.

Улы Әбү Мөхәммәд Сәйфеддин Габделгыйнә шулай ук галимнәр төркеменнән булган вәгыйзь һәм хатыйб бер зат иде. Вафаты 639 елда.

2) Мәҗдеддин Әбу әл-Бәрәкәт Габдуссәләм бин Габдулла.

Бу кеше Ибне Тәймиянең якын бабасы булып, якынча 590 елда Хәрран шәһәрендә дөньяга килде һәм 652 елда вафат булды. Кабере Хәрранда. Үзенең агасы Фәхреддин Әбү Габдулла Ибне Тәймия янында гыйлем алганнан соң, агасының улы булган Әбу Мөхәммәд Сәйфеддин Габдулгыйнә белән бергә Багдад шәһәренә барып алты ел буе гыйлем алуда булды. Соңра Хәрранга кайтып кабат Фәхреддин Мөхәммәд төркемендә дәвам итте. Фикһ белән хәдис фәннәрен тулысынча үзләштереп башка фәннәрдә дә камәләте җирендә иде. Диндар һәм зирәк буларак шөһрәт казанды. Коръән Шәриф буенча бер тәфсир язып, фикһ фәнендә "Әл-Мухәррар" исемле бөек бер әсәр язды. "Мунтәкал-әхбәр" дигән әсәре Шәүкәнинең "Нәйлул-әутар" исемле шәрхе белән бергә Мисырда басылып чыккандыр.

Риваять гыйлеме хакында бөек галимнәрдән иҗазә (таныклык) алган хатыны, агасы Фәхреддин Әбу Габдулланың кызы Уммул-Бәдәр үзеннән бер көн элек вафат булгандыр.

3) Шиһабеддин Әбу Әхмәд Габдулхәлим бин Габдуссәләм.

Бу зат Ибне Тәймиянең атасы булып, 627 елда Хәрранда дөньяга килде. 682 елда Димәшкъта вафат булып, Касъюнда җирләнде. Ул да гомерен укыту һәм язу белән уздырган мөгътәбәр галимнәрдән булса да, үзенең атасы белән улы (Ибне Тәймия) арасында булганга шөһрәтенә бер кадәр кимчелек килгәндер. Электр белән лампа уртасында булган шәм нуры күзләргә күренмәячәге мәгълүм.

4) Габдулла Шәрәфеддин бин Габдулхәлим Шиһабеддин.

Ибне Тәймиянең бертуганы булган бу шәхес Хәрранда 666 елда дөньяга килеп, 727 елда Димәшкъта вафат булды. Гаиләсе белән Димәшкъка килгәндә күкрәк баласы бар иде.

Бу зат та олугъ галимнәрдән булып, аерым алганда мирас, хисап, астрономия, тарих фәннәрендә белгеч иде. Берничә мәртәбә хаҗ сәфәренә барды һәм һәрвакыт туганы Ибне Тәймия мәҗлесендә булып файда күрер иде. Бәхәскә оста булуы сәбәпле кем белән бәхәсләшер булса да, өстен чыгар иде. Аның Хафиз Ибне Хәҗәр әл-Гәскаләни хәзрәтләренә таныклык биргән һәм үзе мәшһүр олугъ галимнәрдән таныклык алган Зәйнәп исемле бер кызы бар иде. Ул 799 елда вафаттыр.

## 3 бүлек

Тәрбиясе һәм укуы. Гыйлеме һәм өстенлеге. Куәте һәм зиһене. Кыюлыгы һәм тырышлыгы. Әхлагы һәм холкы. Кыяфәте һәм тормышы.

Ибне Тәймия Димәшкъ шәһәренә килгәннәреннән соң гыйлем алуга керешеп мәхәббәт һәм гайрәт белән дәвам итте. Зиһене һәм сәләте белән нечкә гыйлемнәр белергә муафик булды. Остаз һәм шәйхләре сәламәт була торып, яп-яшь көенчә гыйлем һәм дәрәҗә белән шөһрәте чыкты. Хәдисләр җыентыгыннан “алты китап”ны һәм мөснәдләрне берничә мәртәбә укыды һәм башкаларга укыды. Тәфсир белән мәшгуль булып, тәртибе белән булмаса да, күп сүрә вә күп аятьләргә тәфсир язды. Үзеннән алда язылган тәфсирләрдә булган бик күп хаталарны мәйданга куйды. Бик яшь көенчә Сибәвәйһи “Китабын” тәмам диккать белән укып чыкты. Усуль фикһ, мирас, хисап, алгебра, кәләм һәм фәлсәфә фәннәрендә осталыкка иреште. Фәтвә бирә башлаганда егерме яшь тулмаган иде. Гыйлем мәҗлесләренә йөрер, бәхәсләрдә катнашыр, фәкать бәхәс вакытында үзенә һичкем өстен чыга алмас иде. Мәгълүматы шулкадәр киң иде ки, чит мәзһәбләргә иярүче адәмнәр белән бәхәскә керешсәләр, алар тарафыннан раслатырга керешеп, аларның күңелләренә килмәгән, колаклары ишетмәгән нәрсәләрне үз зарарына сөйләр һәм соңыннан үз тарафыннан тиешле җаваплар бирер иде.

Ибне Тәймиянең хәдис гыйлемендә иң элек ятлаган китабы имам Хәмиди язган “Ике дөрес хәдисләр тупланмасы” булган. Хәдис гыйлеменнән хәбәрдар булуны, белүне шулкадәр кәсеп итә иде ки, хәдисне тапшыручыларның катламнарын, иснәдләренең югары һәм борынгыларын, риваятьләрнең дөрес һәм зәгыйфләрен белер, мәтеннәрен яттан укыр һәм нинди дә булса бер мәсьәлә чыкса, дәлил буларак берничә хәдис шәриф китерер иде. Хәдис гыйлемен кирәк кадәр дәрәҗәдә туплау, ихтимал адәм балаларына җиңел дә булмас, шулай булса да Ибне Тәймиянең осталыгы гадәттән тыш булып, хәтта гасырдашлары моңа гаҗәпләнделәр һәм: “Ибне Тәймия белмәгән хәдис хәдис булмас”, - дип әйтерләр. Ибне Тәймиянең Китап һәм Сөннәт гыйлемнәрендә булган камиллеген атаклы язучылардан берсе: “Башкалар кашык белән эчкән нәрсәләрне Ибне Тәймия чүмеч белән эчәр, башкаларның энә күзеннән күргәннәрен Ибне Тәймия зур тәрәзәдән күрер иде”, - дигән.

Ибне Тәймиянең ятлау сәләте адәм ышанырлык дәрәҗәдән өстен булып, ятлаган нәрсәләрне онытуы бик сирәк булыр иде. Искәндәрия төрмәсендә ятканда Сәбтә хакименең риваять гыйлеме турысында иҗазәт сорап язган хатына каршы, янында һич китап һәм дәфтәр булмаган хәлдә ун кәгазьдән гыйбарәт бер иҗазәтнамә язып, остазларының һәм шәйхләренең исем-фамилияләрен, шөһрәтләрен тәмам күңелдән бәян иткәндер.

Фикһ һәм мәзһәб каршылыкларын, хөрмәтле сәхәбәләр һәм тәбигыйннар фәтвәләрен белүдә, Исламда килеп чыккан дини фиркаларның мәсләкләре белән таныш булуда үз гасырында Ибне Тәймиянең тиңдәше күренмәгәндер.

Ибне Тәймиядә булган кыюлык аның кебек дөньядан киселеп Аллаһ Тәгаләдән башка һичкемнән курыкмас затларда гына табылыр. Ибне Тәймия курку вә каушауның ни икәнен белмәс, кешеләрнең сүзләренә илтифат итмәс, башка берәүнең күңеле булсын өчен белгәнен фида кылмас, хөсетлек һәм көнчелекләренең хәрәкәтләренә әһәмият бирмәс, дин эшләренә боеру, тыелганнардан тыюдан башка белән эше булмас иде. Законлы хөкүмәтләрнең хакимнәренә вә мәхкәмәләренә түгел, бәлки үзләрен “ни эшләсә дә җавап бирмәс” дигән вазыйфага лаек күргән үзбаш Ислам хакимнәре хозурына ничә мәртәбәләр җавапка чакырылды вә ничә мәртәбәләр зинданнарга ташланды вә ничә мәртәбәләр гасырдашлары берләшеп өстенә һөҗүм иттеләр, бу хәлләр Ибне Тәймиягә тәэсир итмәде вә “һаман яла ягу” дигәне ишетелмәде. Зинданда вакытында янында булган каләм вә караларын алгач, күмер һәм корымнар белән төрмә диварына язуы риваять ителәдер.

Төрмәдә вакытында “фәлән сүзләреңне кире алыр булсаң төрмәдән чыгарылырсың, юкса дошманнарың, көнчеләрең сине үтерүне телиләр”, дип солтан исеменнән кереп әйтүче хезмәтчегә: “Мин хак дип белгән гакыйдәмнән вә Китап, Сөннәт белән ныклы ышанычлы булган мәзһәбемнән төрмәдән котылыр өчен кайтачак вә сүземне дә кире алачак һәм икейөзлелек күрсәтәчәк адәм түгел, Хак Сөбхәнә вә Тәгаләдән башка һичкемнән куркуым юк, минем каршымда иртәгә үлү белән бүген үлү, вә табигый үлем белән кеше кулыннан үтү арасында аерма юк!” дип кире җавап биргәндер.

Монгол гаскәр башлыклары вә татар ханнары хозурына илче сыйфатында барырга кешеләрнең кыюлыклары җитмәгәндә Ибне Тәймия үзе сорап гаскәр башы Котлугъ шаһ, Булай яннарына барды вә икенче мәртәбә Газан хозурына китте. Маҗараның дәһшәтле булганлыгын сурәтләгәндә Шиһабеддин Әбү әл-Габбас Әхмәд бин Фадлулла: “Һәлак итүче бу ерткыч, алдакчы “Нәмруд”, хәйләләп котылып калып булмый торган “әҗәл”дән арысланнар калтырап өнсез калганда, йөрәкләр үкчәгә төшкәндә, ут үзенең януында салкынлык тойганда, кылыч өзеп алудан куркып торган бер вакытта, шәйх Ибне Тәймия Солтан Мәхмуд Газан янына утырды, кулы белән күкрәгенә ишарәләде һәм муенына юнәлтеп кире алды. Дога кылуын сорагач, ике кулын күтәреп гадел рәвештә дога кылды, күпчелек өлеше Газанга ачу белән булды. Газан аның догасы белән иман китерде”, - дигән.

Котлугъ бәк исемле хаким халыкларга золым һәм җәбер кылып җәфалаганда шәригать кушканны боерыр өчен Ибне Тәймия аның янына барган. Хаким исә түбәнсетү максаты белән: “Олугъ адәм вә галим булганыгыз өчен мәҗлесегезгә барып хөрмәтле булу ниятендә йөри идем, инде үзегез килдегез”, - дигәненә, Ибне Тәймия: “Муса пәйгамбәр миннән яхшы вә фиргавен дә синнән усал иде, шулай булса да, Муса пәйгамбәр фиргавен янына көненә өчәр мәртәбә барып иманга чакырыр иде”, - дип җавап кайтарган.

Ибне Тәймия Китап һәм Сөннәт гамәлләрен өстен чыгарыр, бидгать әһлен һәм кәләмчеләрне сөймәс, аларның мәсләкләрен шәригать максатыннан авышкан икәнлеген төшендереп кешеләргә сөйләр һәм моның өчен гаклый вә нәкълый дәлилләр китерер иде. Шул сәбәптән үзе хакында бик көчле дошманнар барлыкка килде, күп иза һәм бәхетсезлекләр күрде. Аз булса да, дөньяда хаклык тарафында да бер төркем булып торыр. Ибне Тәймиянең бу гамәлен Коръән вә сөннәт әһелләре бәяләделәр, элекке Сөннәтне тергезгәне өчен хәер-дога кылып мактар булдылар.

Ибне Тәймия гасырында Фәлут дип аталган елгада халык тарафыннан изге дип ышанган бер таш булып, мөселманнар шуны күрергә барырлар, корбаннар чалып шәкертләрне сыйларлар, нәзерләр кылып өстенә ятып еларлар һәм теләкләрен сорарлар иде. Моның кебек эшләрнең Ислам шәригатендә дөрес булмавы хакында Ибне Тәймия күп нәсыйхәт вә вәгазьләр кылып караса да, хорафат яраткан халык вә шәхси мәнфәгатьләрен саклаучы югары катлам өчен бу нәрсәләрнең тәэсире булмады вә гүзәл нәтиҗә бирмәде. Шуңа күрә көннәрнең берендә үзенең шәкертләрен ияртеп барып ташны тузан урынына

тетте вә урынының билгеләрен бетереп билгесез хәлдә калдырды вә шушы гамәле белән шул җирдә булган әһле Исламны ширек бәласеннән коткарырга сәбәп булды.

Ибне Тәймия ак йөзле, урта буйлы, кара чәчле, сакалында ак бөртекләре аз, чәче колак йомшакларына кадәр җиткән, үткен күзле, иң башлары киң вә гаять көр тавышлы, күркәм, матур сүзле иде. Ни туры килсә шуны кияр, ни табылса шуны ашар, канәгать итәр, кеше күзе төшәрлек киемнәрдән сакланыр иде.

Әхлагы гүзәл һәм бөек табигатьле булып, үзенә кискен сурәттә дошманлык итүчеләрдән дә үч алу ниятендә булмады, җәбер һәм әшәкелекләренә җавап кайтармады, хәтта алар хакында шикаятьле сүз сөйләмәде, бәлки киресенчә, “алар, үзләрен дөрес юлда дип санаганга, шуңа ышанганга күрә, мондый хәлләр белән бәлаләнделәр, бу яктан алар гозерледер” дип, барысын да гафу итә, үзенә дошманлык итүчеләрдән Садреддин Ибне әл-Вәкил (Ибне әл-Мәрхәл)нең вафаты хәбәрен ишеткәч: “Мөселманнарның синең өчен кайгыруларын Аллаһ күркәм кылсын, әй, Садреддин”, - дип әйткән.

Пәйгамбәрләрдән башкаларда бу дәрәҗәдә галиҗәнаблык булачагы мөмкин түгел дип санаучылар булыр. Аллаһ Тәгалә кайбер кешеләр күңелләренә шул дәрәҗәдә миһырбанлык вә мәрхәмәт салырга, бөтен гомерләре буенча мәсхәрә һәм мыскыллау астында торганнары хәлдә шулай ук җавап кайтарасы җирдә, хәтта хакларын да Аллаһ Тәгаләгә шикаять итмәсләр. “Мин аларның күңелләре сынган җирдә” астына керү өмете белән булса кирәк, көннән көн үзләрендә мескенлекне арттырдылар. Мондый затларның кайберләрен күрү үзебезгә дә насыйп булганга, Ибне Тәймия хакында шикләнүләребез юктыр.

Мөфтилек, казыйлык кебек хөкүмәт вазыйфаларына кермәде, әмир һәм башкаручылар тирәсендә йөрмәде, байларга һәм дөнья әһелләренә ялагайланмады, вакыф малларга караучы вә ятимнәргә җитәкчелек итмәде. Вакыф һәм хәзинә малларыннан шундагы әмир һәм эш башкаручылардан, бер акча булсын, кабул итмәде, бәлки бөтен шөгыле вә бөтен рәхәте гыйлем белән шөгыльләнүдән гыйбарәт булып, шуннан башка нәрсәләрдән тәм тапмас, бер сәгать гомерен әрәм итмәс, буш вакыты булды исә Коръән Шәриф укыр иде.

Вафат булганда бөтен мирасы китаплары белән гыйлемнән гыйбарәт булып, шуннан гайре һичбер нәрсәсе калмады.

## 4 бүлек

### Остаз һәм шәкертләре. Вафаты соңыннан сөйләнгән мәрсияләр.

Ибне Тәймия атасы янында укый башлап, соңрак түбәндәге кешеләр хозурында файда алгандыр: Шәмседдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Габдулкавий әл-Хәнбәли, Ибне әл-Мәнҗә Зәйнеддин, Ибне Гәсәкир Мәҗдеддин, Ибне Әби әл-Йуср, Кәмәл бин Габд, Кадый Ибне Гата Шәмседдин әл-Хәнәфи, Ибне әл-Сайрафи, Нәҗиб әл-Микъдад, Ибне Әбил-Хайр, Ибне Галән, Әбү Бәкер әл-Һәрви, Кәмәл Габдеррахим, Фәхреддин Ибне әл-Бухари, Ибне Шәйбән, Шәрәф бин әл-Кауuас, Зәйнәб бинт Мәкки вә башкалар. Ике йөздән артык остаздан укуы риваять ителәдер.

Әбү Хәнифә хәзрәтләренең Әбү Йосыф белән Мөхәммәд бин әл-Хәсән Шәйбәнидән башка һичбер әсәре калмаса иде, исемен рәхмәт белән искә алдырыр һәм данын да ерак һәм якыннарга танытыр өчен, әлеге ике зат җитәр иде. Шәйх Җамаледдин Әфгани хәзрәтләренең дөньяда калдырган бөек әсәре Мисыр мөфтие Мөхәммәд Габдүһ

хәзрәтләре. “Мөхәммәд Габдүһ кебек галиҗәнаб, фикер иясе, акыллы бер зат җитештергән кеше өчен башка әсәрләргә күп ихтыяҗ юк. Моның дәрәҗәсендә файдалы бер әсәр калдыру җиңел түгелдер”, диярләр.

Бу яктан Ибне Тәймиянең Ибне әл-Кайим әл-Җәүзидән башка һичбер шәкерте булмаса һәм бер бит язмасы калмаса да, дан йөзеннән шул бер шәкерте җитәрлек булыр иде. Ләкин телгә алынган хәзрәтнең сансыз язмалары калган кебек, гасыр һәм өлкәләрнең атаклыларыннан берничә шәкерте дә калган. Мисал өчен өч-дүртенең исемнәрен бу урында аерым сурәттә искә алачакбыз.

1) Ибне Кудәмә. (Шәмседдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Әхмәд бин Габдулһәди әл-Хәнбәли. 744 елда вафат). Бу зат Ибне Тәймиянең сирәк шәкертләреннән булып, язмалары күп иде, фәкать яшьлегендә вафат булганга каралама хәлләрендә калып юкка чыктылар. Вафат булганда 38 яшендә иде.

2) Ибне әл-Кайим әл-Җәүзия (Шәмседдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Әби Бәкер бин Әюб әл-Димәшкый әл-Хәнбәли. 751 елда вафат). Һәрвакыт остазы белән бергә булып, аннан аерылмаганга, аның белән бергә төрмәгә ябылды. Вафат булганда яше 59 да булып, кабере Димәшкъ шәһәрендәдер.

3) Ибне Кәсир. (Гыймадеддин Исмәгыйль бин Гомәр әл-Басрый әл-Шәфигый. 773 елда вафат). Кабере Димәшкъта шәйхе Ибне Тәймия янындадыр. Хафиз Ибне Хәҗәр әл-Гәскаләни аның шәкерте иде.

4) Ибне Муфлих. (Шәмседдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Муфлих әл-Мукаддәс әл-Хәнбәли. 763 елда вафат). Гариф вә заһид, дини бер зат булуы риваять ителәдер. Шәйхе Ибне Тәймия һәрвакыт аңа: “Син Муфлихның улы түгел, бәлки син үзең Муфлих син”, - дип әйтә торган булган.

5) Ибне әл-Мәнҗә. (Шәрәфеддин Әбү Габдулла Мөхәммәд бин әл-Мәнҗә әл-Тәнвихи әл-Димәшкый әл-Хәнбәли. 724 елда вафат). Сәфәрдә һәм өендә вакытта Ибне Тәймия яныннан аерылмавы, соң дәрәҗәдә тәкъва, Сөннәт белән гамәл кылучы булуы риваять ителәдер.

6) Зәһәби (Шәмседдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Госман бин Каймаз әл-Зәһәби. 738 елда вафат). Мәшһүр галимнәрдән, хаталарны ачыклау һәм төзәтүдә күп эшләгән затлардандыр.

7) Гыймадеддин әл-Васитый (Әхмәд бин Ибраһим әл-Шәфигый әл-Хәнбәли. 701 елда вафат). Ибне Тәймиядән гыйлем алганнан соң шәфигый мәзһәбеннән хәнбәли мәзһәбенә күчте. Заһид вә суфый булуы сәбәпле бу кешегә шәйхе Ибне Тәймия “вакыт сугышчысы” дип әйтер иде.

Ибне Тәймия вафат булганда бик күп кешеләр озын-озын мәрсияләр сөйләделәр. Китапханәбездә әлеге затларның мәрсияләре бар: Хафиз Зәһәби, Ибне Фадлулла әл-Гамри, Ибне әл-Вәрди, Мөхәммәд әл-Гыйраки, әл-Җәзәри, Галәүддин бин Ганәм, Мөхәммәд Ибне әл-Әсир әл-Хәләби, Зәйнеддин Гомәр бин әл-Хусәм әл-Шубәйли, Ибне әл-Хусари, Шиһабеддин Әхмәд бин Габдулкәрим бин Әнуширван әл-Тибризи әл-Хәнәфи, Борһанеддин Шиһабеддин әл-Тибризи улы, Тәкыйуддин Мәхмуд бин Гали әл-Вәквәкый әл-Багдади әл-Мухәддис.

Әгәр бу мәрсияләр бер җиргә җыелачак булса, якынча ике йөз битлек бер китап булыр иде, урын азлыгы сәбәбеннән, никадәр булса булсын, монда күчерү мөмкин булмады.

5 бүлек

Ибне Тәймиянең гакыйдәсе үзенең әсәрләрендә телгә алынган вә бу әсәрләрдән күпләре басылгандыр. Шуның өчен бу турыда озын бәхәс итәргә хаҗәт юк. Түбәндә булган бәетләрне Ибне Тәймия үз гакыйдәсе хакында сөйлидер:

Әй, сораучы мәзһәбем һәм гакыйдәм турында,
Туры юл бирелер, кем һидаять өчен сораса.
Аның әйтүендә дөрес сүзне тыңла,
Кире кайтмас аннан һәм алыштырмас башкага.
Минем өчен мәзһәб - сәхәбәләрнең сөю барысын,
Якыннарны сөю белән сорыйм.
Анык кадер-хөрмәт Һәрберсенә,
Ләкин Сиддыйк иң хөрмәтлесе.
Коръән турында әйтәм: аның турында
Килгән аяте белән  - ул “кадим” “иңдерелгән”,
Сыйфат аятьләре барысы да хаклык белән боерган,
Беренче үрнәк ничек тапшырса.
Җаваплылыгын тапшыручысына кайтарам,
Һәм һәрбер уйдырмадан саклаучысына.
Җирәнгечтер Коръәннән йөз чөергән,
Әгәр дәлил китерер булса, буш сүз сөйләр.
Мөэминнәр күрерләр Раббыларын хак күрү белән,
Һәм сорамаслар “күккә ничек төшә” дип.
Раслыйм мизанны һәм сулыкны мин,
Өметләнәм аннан сусавымны басармын дип.
Шулай ук сират җәһәннәм өстеннән сузылган,
Һәм ул котылганның чиге һәм илтифатсызның ахыры.
Бар җәһәннәм уты, явызның анда керүендә хикмәт булыр,
Шулай ук Аллаһның тәкъва колы да җәннәтләргә кертелер.
Һәр акыллы җан каберендә
Гамәле белән бергә булыр һәм соралыр.
Бу ышану Шәфигыйныкы һәм Мәликнеке,
Әбү Хәнифәнеке, аннан соң күчте Әхмәдкә.
Әгәр алар юлыннан китсәң булыр уңыш,
Әгәр инде яңалык кертсәң, бармы сиңа ышаныч?

Ибне Тәймиянең мәсләге зат вә сыйфат хакында булган аять вә сахих (дөрес) хәдисләрне, “ничек” дип сорау куймау һәм чагыштырып кузалламау шарты белән аңлатырга тырышмыйча һәм үзгәртмичә, бозмыйча ничек бар шулай йөртүдер.

“Әл-Гакыйдәтү әл-васитыйә”дә әйтер: “Аллаһка иманнан – Үзе турында Китабында ничек сыйфатласа, һәм Аның илчесе Мөхәммәд ничек сыйфатласа, үзгәреш кертмичә, бозмыйча, нәрсәгә дә булса яраклаштырмыйча, күзалларга тырышмыйча иман китерү. Аллаһка иман китерүчеләр, Аңа охшаш һични юк, Ул Ишетүче Күрүче дип, иман китерәләр һәм Ул Үзен сыйфатлаган сыйфатларны кире какмыйлар, сүзнең мәгънәсен бозмыйлар, Аллаһның исемнәрендә һәм аятьләрендә көферлек кылмыйлар, Аның сыйфатларын мәхлукълар сыйфаты белән чагыштырмыйлар, чөнки Аның адашы, тиңдәше, охшашы юк, Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә Үзе бар иткән мәхлукъ белән чагыштырылмас. Үзе турында һәм башкалар турында иң яхшы белүче Ул үзе, Аның сүзе иң дөрес сүз, хәбәре иң күркәм хәбәр,

соңыннан, башкалардан, Аның турында үзләре белмәгәнне сөйләүчеләрдән аермалы буларак, Аның дөрес сүзле һәм эчкерсез илчеләре белүчеләр”.

Ибне Тәймия фамилиясе, гомумән, Әхмәд бин Хәнбәл хәзрәтләре мәзһәбендә булганга ул үзе дә шул мәзһәбтәдер. Шуның белән бергә, гомеренең ахырында мәзһәбкә туры килүне сакламас, бәлки үз каршында игътибарга лаек булган дәлилләргә нигезләнеп фәтвә бирер иде. Камил мөҗтәһид булу өчен кирәкле шартлар үзендә бар иде диярләр.

Ибне Тәймия шигырь сөйләргә хәленнән килгән гарәп галимнәреннән булса да, сөйләгән шигырьләре аздыр. Аерым алганда хәдис һәм тәфсир гыйлемнәренең шигырьгә әһәмият бирүләре бик сирәк күренеш.

## 6 бүлек

### Язган китаплары.

Ибне Тәймия күп китап язган галимнәрдән булып, әсәрләре барысы да диярлек Китап вә Сөннәткә көч бирү, бидгатьне кире кагу хакында. Өч йөзләп китапларын саныйлардыр. Китапларын караламасыз һәм күбесен алдан әзерләнмичә язуы риваять ителәдер. Шул сәбәпле булса кирәк, бер мәсьәлә күп урында кабатланадыр. Үзе генә теләмәсә, сүзләрнең аһәңенә, матурлыгына, кыскалыгына игътибар ителмәве күрелер. Бу яктан әсәрләре борынгыларның китапларына охшар. Оста каләмле, гыйбарәләре ягышлы, язуы камил булганга, әсәрләрен тау башыннан атылып төшкән олугъ чишмәгә охшату урынлыдыр.

Мәшһүр хәдисләр җыентыкларыннан соң, ләззәт белән укылачак әсәрләр аның китаплары булса кирәк. Безнең тәҗрибәбез шулайдыр. Тәҗрибәдә хата да булыр, дөреслек тә. Үзенең тәҗрибәсенә күрә сүз сөйләгән кеше шелтәләнмәс.

Китап язу турысында Ибне Тәймия белән Суютый бер-берсенә тәмам капма-каршы булсалар кирәк. Суютый бөтен гомерен башкаларның китапларын кыскартып үз итеп вә үзгәртеп, җөпләп, һәм каршылыклы әсәрләрне бергә җыеп кичергәне хәлдә, Ибне Тәймия бик күп суютыйлар өчен җөпләргә җитәрлек запас калдыргандыр.

Димәшкъ китапханәләре турында язылган бер эчтәлеккә күрә, Ибне Тәймия әсәрләреннән бик күпләре анда саклануда булып, хәтта арада үз каләме белән язылган дип уйланган әсәр бардыр. Соңгы егерме ел эчендә Ибне Тәймиянең язмалары нәшер ителә башлавыннан бу әсәрләргә дөньяның күзе төшүе һәм әһәмият бирелә башлавы аңлашыладыр.

Ибне Тәймиянең бөтен әсәрләренең исемнәрен язу күп урын алачак. Шуның өчен мәшһүр басмаларын бу урында язачакбыз:

- اقتضاء الصراط المستقيم في الرد على اصحاب الجحيم .
- الايمان.
- بيان موافقة صريح المعقول لصحيح المنقول.
- تفسير سورة الاخلاص
- تفسير سورة المعوذتين
- جواب اهل الايمان بتحقيق ما اخبر به رسول الرحمان من ان قل هو الله احد تعدل ثلث القران
- الجواب الصحيح لمن بدل دين المسيح
- الجوامع في السياسة الالهية و الايات النبوية
- رسالة تنوع العبادات

- رسالة العبودية
- رسالة في الرد على النصيرية
- رسالة زيارة القبور
- رفع الملام عن الائمة الاعلام
- فتاوى ابن تيمية
- منهاج السنة النبوية في نقض كلام الشيعة و القدرية (дүрт томда)

Ибне Тәймиянең шәкертләреннән Ибне Мәра Шиһабеддин тарафыннан үзенең иптәшләренә Ибне Тәймия хакында тәгъзия итеп язган озын бер язмасы мөгтәбәр "Әл-Мәнар" җурналында күрелде. Бу язмасында Ибне Тәймия әсәрләренә кагылышлы бер абзац бар. Шуны кыскартып бу җирдә күчерүне тиеш таптык.

Ибне Мәра әйтә: "Әй, туганнар! Безнең вазыйфабыз мөхтәрәм остазыбызның әсәрен җыю һәм нөсхәләрен күбәйтеп әһле Ислам арасына таратудыр. Бу әсәрләрдә никадәр кабатлаулар булса-булсын, асылда кыскартылмасыннар, бәлки үз каләме белән ничек язылган булсалар шулай күчерелсеннәр һәм һәрбере чагыштырып дөресләнсеннәр. Барыбыз бер фикер белән хәрәкәт итсәк, Аллаһ теләсә, бу хезмәтне җиренә җиткерербез. Бу юлда ни кадәр гомер һәм ни кадәр байлык сарыф итәр булсак та, Аллаһ Тәгалә каршында юкка чыкмас. Бу көндә шәйх Әбү Габдулланың (Ибне әл-Кайим әл-Җәүзия) сәламәтлеген табыш дип белегез һәм бу юлда аны җитәкче итеп һәрберегез аның хезмәтенә әзер булыгыз. Мөхтәрәм остазыбыз "Әл-раддү галә гакаид әл-фәләсифә" (Фәлсәфәчеләр гакыйдәсен кире кагу) дип аталган бер китап язган иде. Мин шуны үз каләмем белән тәмам күчереп алган идем. Бу китап шулай таралды. Төрле формалары, төрле кешеләр кулында. Иң элек хезмәт буларак моны бер җиргә җыеп тулы бер китап рәвешенә китерегез. Әлеге китап тиңдәшсез бер әсәрдер. Фәлсәфәчеләрнең дәлилләрен тәнкыйть итүдә моның кадәр шифалы бер китап күрелмәс. Мөхтәрәм остазыбызның барлык әсәрләрен җыеп мәйданга чыгарыр булсак Ислам милләте өчен олугъ хезмәт күрсәткән һәм бөек бер гыйлем хәзинәсен калдырган булырбыз. Бу әсәрләр беренче мөселманнар гакыйдәсен өйрәнүчеләр өчен юлбашчы һәм китап язучылар өчен чыганак булыр. Мәгълүмегездер ки, Әхмәд Ибне Хәнбәл хәзрәтләре үзе сәламәт вакытта үзенең сүзләрен туплаудан тыя иде, әмма вафат булганнан соң шәкертләре аның сүзләрен һәм гыйлемен туплап халыкка белгерттеләр, элекке әсәрләренең таралуына сәбәп булдылар. Инде сез дә Әхмәд Ибне Хәнбәл шәкертләре юлыннан йөрер булсагыз, гүзәл бер эш булыр. Бохари, Аллаһ аннан риза булсын, шәһәрдән куылды, кире кагылды, фәкать шуның бәрабәренә Аллаһ Тәгалә аның күңеленә кермәслек, хыялына килмәслек рәвештә китабының дәрәҗәсен югары күтәрде, Бохари китабы бөтен Сөннәт китапларының өстендәдер. Без остазыбыз китаплары хакында моның белән бер өметтәбез, Аллаһ теләсә өметебез җиренә килсә кирәк. Бөтен максаты ялган һәм бидгатьне кире кагу, элеккеләр юлына һәм Сөннәткә җиңү бирү иде. Моңа өстәп, әсәрләре, хаклык белән язылганга һәм һәрберсе асыл һәм дәлилгә нигезләнгәнгә, башка кешеләрнең китапларыннан аерылып тора".

## 7 бүлек

### Ихтыяр иткән кайбер мәсьәләсе.

Инсаннарның хөрмәт вә олугълыклары тышкы сурәт вә торышларына күрә түгел, бәлки гамәлләренә, игътикад вә фикерләренә күрәдер. Шуның өчен бер кеше биографиясе язылганда гакыйдә һәм гамәлләренә караган мөһим нәрсәләр сөйләнмәсә биографиясе кимчелекле калыр, аны тәртип итүче дә үз вазыйфасын җиренә җиткергән саналмас. Шушы хикмәт өчен без әлеге бүлектә Ибне Тәймия тарафыннан ихтыяр ителгән мәсьәләләрдән мөһимнәрен, кирәк үзе генә булсын, кирәк тарафдарлар вә сәләфләре булсын, бу урында кыска сурәттә сөйләп үтәчәкбез. Бу турыда алганнарыбыз үзенең китапханәбездә булган әсәрләредер. Ибне Тәймия монда әйтеләчәк нәрсәләр хакына җәбер-җәфа күреп, шулар хакына шөһрәт казанып дәрәҗәсе күтәрелеп Исламны саклаучылар җөмләсеннән саналырга лаеклы булгандыр. Мәсьәләләр белән тиешенчә таныш булуны теләүчеләр турыдан-туры үзенең әсәрләренә мөрәҗәгать итерләр. Китап озын булмасын өчен без кайберләрен генә язачакбыз.

Ибне Тәймиянең тоткан мәсләге исә, дини эшләрне бары тик сәгадәт гасырында гамәлгә куелган рәвештә тотудан гыйбарәт булып, шуларга бер нәрсә арттыру һәм кушу хакында һичкемнең хакы юк, инсаннар үз белдекләре белән дин төзүләре Аллаһның шәригатенә каршы җинаять, дияр. Монда язылачак нәрсәләр һәрбере әлеге асылга нигезләнер.

***1) Тәүхид.***

Тәүхид хакында Ибне Тәймия әйтә: “Ислам диненең асылы тәүхидтән гыйбарәт булып, Аллаһ Тәгалә илчеләрен шуңа өндәү өчен җибәргән һәм шуннан башканы кабул итмәячәген аңлаткан. Тәүхид исә Аллаһ Тәгаләне бар һәм дә бөтен галәмне бар итүче дип инану белән генә булмас. Мәккә мөшрикләре дә Аллаһ Тәгаләне бар һәм дә күкләрне һәм җирне барлыкка китерүче дип ышанырлар, хәтта үзләренең иләһләрен мәхлук дип белерләр иде. Бәлки тәүхид, болар белән бәрабәр гыйбадәтне Аңа гына багышлап, үлүһияткә (Аллаһка) хас нәрсәләрдә Аңа һичкемне шәрик-иптәш итмәүдән гыйбарәттер. Үлүһият хосусында булган нәрсәләрдә Халык кылучы белән мәхлукны бер дәрәҗәгә куючы кеше Исламнан аерылыр. Ислам дине ике асылдан гыйбарәттер. Берсе, шәһадәт кәлимәсен әйтү, аны дөрес дип тану һәм эчтәлеген үтәүдер. Икенчесе, хөрмәтле пәйгамбәр өйрәткән рәвештә Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылып монда һичбер мәхлукны тиңләштермәү. Дога, гыйбадәтнең бер төре булганга, Аллаһ Тәгаләгә генә булырга тиешле. Әгәр дә бер кеше, Аллаһ Тәгаләдән башкага дога кылса, мәетләрдән һәм күз алдында булмаганнардан ярдәм сораса, бу кеше шул мәхлукларны гыйбадәттә Аллаһ Тәгаләгә тиңләштергән булыр. Пәйгамбәребез хәзрәтләре Аллаһ Тәгалә каршында мөхтәрәм һәм дәрәҗәле иде. Хезмәте дә Аллаһ Тәгаләнең шәригатен кешеләргә ирештерүдән гыйбарәт булып, хәләл һәм хәрам, кушылган һәм тыелган, вәгъдә һәм кисәтү һәм башкаларны кешеләргә тулысынча ирештерде. Башка пәйгамбәрләрнең хезмәтләре дә шуннан гыйбарәт булды. Әмма догаларны кабул итү, бәлаләрне җибәрү, һидәят бирү, бай һәм сәламәт итү, озын гомерле һәм бәхетле итү хезмәте пәйгамбәрләрдә түгел, бәлки бу нәрсәләрне үтәү Аллаһ Тәгаләнең үзенә генә хас эшләрдер.

Нәтиҗә: Пәйгамбәрләр (аларга салават һәм сәлам) шәригатьне ирештерү хосусында арадашчылар булганга, бу турыда аларны хак дип тану һәм буйсыну тиештер. Шуңа бәрабәр үлүһият эшләрендә аларны Аллаһка тиңләштерү Ислам шәригатенә күрә асылда катгый дөрес түгелдер. Ихтирам нияте белән аларга сәҗдә кылырга ярамаганы кебек, Аллаһ Тәгаләгә генә хас нәрсәләрне алардан сорау да дөрес булмас. Аллаһның илчесе: *“Мине Мәрьям улы Гыйсәне олылаган кебек олыламагыз, хакыйкатьтә мин кол, “Аллаһның колы һәм илчесе” дип әйтегез”*, - дип боера. Ислам дине кешеләр тарафыннан ясалган нәрсәләр түгел, бәлки Пәйгамбәр тарафыннан ирештерелгән нәрсәләрдер. Шуның өчен кешеләр үз белдекләре белән дин төзергә тиеш түгел, бәлки Аллаһның илчесе тарафыннан ирештерелгән дингә буйсынырга тиеш”.

***2) Ихтирам итү, олылау нияте белән каберләр өстенә мәчетләр кору.***

Бу мәсьәлә хакында Ибне Тәймия әйтә: “Пәйгамбәр хәзрәтләре каберләр өсләренә (мәетне олылау һәм ихтирам итү нияте белән) мәчетләр төзүчеләргә ләгънәт кыла һәм: “Әй, Аллаһ! Каберемне гыйбадәт кылыначак пот хөкемендә итмә!” дип дога кылган. Шуңа күрә изге кешеләр дип уйланган затларның каберләре өсләренә гыйбадәтханәләр төзү шәригать кушкан эш түгел. Сәхәбәләр Шам өлкәсен яулап алдылар, хәзрәти Гомәр һәм хәзрәти Госман да Шам өлкәсенә хөрмәт күрсәттеләр. Бу вакытта һичбер сәхәбә Ибраһим галәйһиссәләм каберенә бармады, аның өстендә гыйбадәтханә дә юк иде. Өмәви һәм габбаси хәлифәләр чорында шулай торып, бишенче гасыр ахырында христианнар Шам өлкәсен басып алгач, Ибраһим Хәлил кабере өстенә шундагы бинаны салдылар. Соңрак кире Ислам дәүләтенә кайтарылгач мөселманнар әлеге бинаны мәчет иттеләр. Сәхәбәләр каберләр өстенә бина төзүдән тыя иделәр[1]. Тәстәр шәһәрендә Даниал пәйгамбәрнең кабере пәйда булгач, Әбү Муса әл-Әшгари хатына каршы җавап буларак хәзрәти Гомәр: “Унөч җирдә кабер казытып шулар арасыннан берсенә Даниал пәйгамбәрнең сөякләрен күм, халык белерлек булмасын. Кабере мәгълүм булса халык фетнәләнә башлар”, - дип язган. Пәйгамбәр хәзрәтләре бер вакыт намаз укыган урында бәрәкәт алу нияте белән кешеләрнең чиратлашып намаз укуларын белгәч, хәзрәти Гомәр бу эштән тыйган һәм: “Сездән алда яшәгән өммәтләр үзләренең пәйгамбәрләреннән калган урыннарны, бәрәкәт алу нияте белән, гыйбадәт кылу урыннары итеп харап булдылар. Намаз вакыты керсә туры килгән урында укыгыз, юкса үз йомышыгызга йөрегез”, - дигән. Чынлыкта Ислам тарафыннан боерылган тәүхид шушы рәвештә булыр. Гарәп сәяхәтчеләреннән берсе Багдад шәһәрендә булып Габдулкадир әл-Гәйләни төрбәсе хакында: “Гаҗәп матур биналардан гыйбарәт булып, мәчете шәкертләр белән тулы һәм кешеләрнең аны олылаулары шулкадәр зур, аның белән Аллаһ Сөбхәнәһү вә Тәгаләнең олуглыгы онытыладыр”, - дигән.

Җаһилият гасырында “мәетләрнең рухлары Аллаһ Тәгалә белән кешеләр арасында арадашчы хезмәтен үти” дип ышанганнар һәм шуның өчен мәетләр һәм әрвахлар изгеләштерелер, каберләренә җыелып гыйбадәт төреннән булган гамәлләр кылыныр, корбаннар бугазланыр иде. Шәригать моның кебек ышанулардан саклау белән мәгълүмат бирә. Хосусый сурәттә дәлил килмәгәнгә агач һәм таш, елга һәм чишмәдә изгелек юклыкны белдерә. Пәйгамбәребез аның астында утырып сәхәбәләрдән бәйгать алган агач янына барып бәрәкәт алу нияте белән йөрүчеләр барлыгын белгәннән соң хәзрәти Гомәр әлеге агачны кистереп ташлатты”.

***3) Вәсилә. Тәвәссүл һәм мәетләрдән ярдәм сорау. Каберләрне зиярат кылу.***

Бу мәсьәләләр хакында Ибне Тәймия әйтә: “Шәригать телендә “вәсилә” сүзе Аллаһ Тәгаләгә якынаю сәбәбе булган нәрсәләрне күз алдында тотар. Кайвакыт бу сүздән җәннәттә мәгълүм бер дәрәҗә күз алдында тотылыр. Хак Тәгаләнең: **“Әй, иман китергәннәр! Аллаһтан куркыгыз, Аңа якынаерга омтылыгыз һәм Аның юлында көрәшегез, бәлки сез уңышка ирешерсез[2]”,** һәм: **“Алар ярдәм сорап дога кылган иләһләр үзләре Раббыларына якынаю юлын эзлиләр[3]”** аятьләрендә беренче мәгънә, ягъни арадашчы, хәдисләрдә булган: *”Мөхәммәдкә “вәсиләне” бир”* сүзеннән соңгы мәгънә, ягъни җәннәттәге урын күз алдында тотыладыр. Аллаһ Тәгаләгә якынаю сәбәбе исә иман һәм гамәлдер. Нәтиҗә: “вәсилә” Пәйгамбәребезгә иярүдән гыйбарәт булып, беренче мәгънәдә булган “вәсилә” шәригатьтә башка нәрсәләрне белдереп килми. Әмма “тәвәссүл” сүзеннән өч төрле мәгънә күз алдында тотылырга мөмкин:

1) Пәйгамбәребезгә иярү һәм аның әмерләренә итәгать итүне Аллаһка якынаю сәбәбе итү. Бу мәгънәдәге “тәвәссүл” фарыз булып кешеләрнең иманнары моннан башка тулы булмас.

---

[1] Гыйбадәт кимчелеге булмаса, каберләр өсләренә билгеләр кую, ташлар язып утырту, әлбәттә дөрес булса кирәк.

[2] “Мәидә” сүрәсе, 35 аять

[3] “Исра” сүрәсе, 57 аять

2) Пәйгамбәребезнең догасын вә шәфәгатен “вәсилә” итү. Бу мәгънә белән “тәвәссүл” пәйгамбәребезнең яшәгән вакытына һәм Кыямәт көненә хастыр. Вафат булганнан соң, хосусан кабере янында Пәйгамбәребездән шәфәгать һәм дога сорау шәригать куйган гамәл түгел.

3) Пәйгамбәребезнең затын һәм хакын “вәсилә” итү. Бу мәгънәдә “тәвәссүл” сәхәбәләрдә һәм элекке мөселманнарда булганы билгеле түгел. Хәнәфи мәзһәбендә мәшһүр галимнәрдән булган Кудуриның: “Мәсьәләнең куелышы ук дөрес түгел, чөнки мәхлукъның Халык кылучыдан өстен булырга хакы юк”, - диюенең сәбәбе дә шулдыр.

Истиска (яңгыр сорау) вакытында хәзрәти Гомәрнең: “Әй Аллаһ! Безгә корылык килгәндә Пәйгамбәребез белән “тәвәссүл” кылдык (Пәйгамбәребезнең догасы белән Синнән сорадык) һәм Син яңгыр яудырдың. Хәзер Пәйгамбәребезнең агасы белән “тәвәссүл” кылабыз, безгә яңгыр яудыр!” – дигән сүзендә булган “тәвәссүл” өчен, аның догасы аша Аллаһка мөрәҗәгать иткәндә тере булуы шарт икәнен югарыда әйттек. Әгәр шулай булмаса, хәзрәти Гомәр һәм сәхәбәләр хәзрәти Габбас догасы белән “тәвәссүл” итәсе урында Пәйгамбәр догасы белән “тәвәссүл” иткән булырлар иде. Нәтиҗә: “Мәхлукъларга дога кылмак һәм аларның затларын, хөрмәт вә хакларын “вәсилә” вә “васита”, бу кешеләр кирәк тере вә кирәк мәет булсыннар, кирәк пәйгамбәрләр вә кирәк башкалар булсыннар, кирәк ярдәм сорау, кирәк “тәвәссүл” вә “вәсилә”, кирәк башка сүзләр булсын, Ислам шәригатенә күрә дөрес түгелдер. Аны булдыру кешеләр өчен мөмкин түгел эшләр хакында ялгыз Аллаһ Тәгаләнең үзенә генә дога кылырга вә Үзеннән генә ярдәм сорарга, турыдан-туры Үзенә генә ялварырга тиешле. Хасталыктан шифа табу яки бер бәладән котылу өмете белән Аллаһ Тәгаләдән башкаларга дога кылу, шәйхләрдән ярдәм сорап ялвару Ислам дине тарафыннан тыелган ширектер. Шәйхләренең әрвахларыннан көч сорау белән күпләр адашты, алар шәйхләре гайре табигый көч-кодрәткә ия, шуның белән кешеләрнең күңелләре белән идарә итәләр, шуның белән Аллаһ белән мәхлукълар арасында торалар, Аңа якынайталар дип ышандылар.[1] Дога гыйбадәт, бәлки гыйбадәтнең дә каймагы булганга Хак Сөбханәһү вә Тәгаләнең Үзенә генә хас булырга, монда шәрик-иптәш фәлән тотылмаска тиешле.[2] Сәхәбәләр Пәйгамбәрдән үзләре өчен Аллаһ Тәгаләгә дога кылуны үтенәләр иде. Хәтта үзе дә кайбер сәхәбәгә: “Әй, карендәш! Догаларыгызга безне дә кушыгыз”, - дип әйтүе риваять ителә. Әмма нинди генә вакыйгаларга, нинди генә бәла-казаларга очрасалар да, Пәйгамбәрнең үзеннән сорап дога кылулары, шулай ук аның рухыннан ярдәм сораулары хәбәр ителми.

Мөселман каберләрен, хосусан Пәйгамбәребезнең каберен зиярат итү мөстәхәбтер. Каберләр янына барган вакытта Рәсулуллаһ гадәтенә муафик рәвештә аяк өстендә торып сәлам бирергә, Аллаһ Тәгаләдән гафу һәм сәламәтлек сорарга тиешле. Аллаһның илчесе каберләрне зиярат иткәндә:

"السلام عليكم اهل الديار من المؤمنين و المسلمين و انا ان شاء الله بكم لاحقون و يرحم الله المستقدمين منا
و منكم و المستأخرين و نسأل الله لنا ولكم العافية اللهم لا تحرمنا اجرهم و لا تفتنا بعدهم و اغفر لنا و لهم"

“Сәлам сезгә, мөэминнәр һәм мөселманнар йортлары халкы! Аллаһ теләсә, без дә сезгә кушылачакбыз. Бездән һәм сездән алдан үлгәннәргә һәм ахырдан вафат буласыларга Аллаһ рәхмәтен ирештерсен. Аллаһтан үзебез өчен һәм сезнең өчен иминлек телибез. Әй Аллаһ, безне әҗерләреннән мәхрүм кылма, алардан соң безне фетнәләндермә, безне һәм аларны гафу ит!” - дип, аяк өсте булган хәлдә дога кыла иде. Ислам динендә рөхсәт ителгән зиярат кылу шушы рәвештә булган зияраттыр. Зиярат кылудан максат мәетләрдән һәм

[1] “Әл-Мәнар” 11 т., 510 б.
[2] Хисси ярдәмнәр сорау, Аллаһ Тәгаләгә дога кылуны үтенү, үзенең иманын һәм пәйгамбәргә итәгатен һәм аңа булган мәхәббәтен “вәсилә” кылу башка мәсьәләләрдер.

икенче дөньяга күчкән җаннардан хаҗәт сорау, дога һәм шәфәгать алу түгел. Исламда моның кебек зиярат юк. Каберләрне үбү һәм гыйбадәт рәвешендә булып олылау, нәзерләр һәм корбаннар белән Аллаһка якынаю Ислам шәригатендә шөбһәсез тыелгандыр.

Пәйгамбәребез, аңа кадәр булган пәйгамбәрләрнең берсе дә кешеләргә фәрештәләргә, пәйгамбәрләргә һәм изгеләргә, алар үлгәннән соң да, үзләре юкка чыкканнан соң да, дога кылуны, шәфәгать итүләрен сорауны кушмады. Берәү дә “Әй, Аллаһның фәрештәләре, Аллаһ каршында минем өчен сорагыз, Аллаһтан безгә ярдәм бирүен, яки ризык бирүен, яки туры юлга күндерүен сорагыз”, дип әйтмәс, шулай ук пәйгамбәрләрдән һәм изгеләрдән вафат булганнарына “Әй, Аллаһның пәйгамбәре! Әй, Аллаһның илчесе! Аллаһка минем өчен дога кыл, Аллаһтан минем өчен сора, Аллаһның мине гафу итүен сора”, дип әйтмәс.

Бу рәвештә зиярат итү Пәйгамбәребездән, хәтта сәхәбәләрдән дә күчмәгән бер бидгать, дөресрәге ширектер. Әлеге сүзләрдән аңлашылганча, ике төрле зиярат бар. Боларның берсе “шәргый”, ягъни шәригать дөрес дип тапкан, икенчесе “гайре шәргый”, ягъни шәригатьтә урыны булмаган. Мәетләр өчен дога кылу һәм җеназа уку, фәкыйрьләргә зәкәт бирү кебек бер мәгънәви яхшы гамәлдер. Бу гаять гүзәл эш иде. Ләкин шайтан, кешеләрне һәрвакыт гыйбадәт ишегеннән кереп аздырырга өйрәнгәнгә, аларны аздырыр өчен зиярат итүне дә форсат күрә, алар өчен дога кылып, алар өчен иминлек сорыйсы урында, киресенчә, алардан ярдәм сорау һәм аларга гыйбадәт кылу гадәтен кертүне тели”.

***4) Зиярат өчен сәфәр.***

Бу мәсьәлә хакында Ибне Тәймия әйтә: *“Өч мәчеттән башкаларга сәфәр кылынмас,* (әлеге өч мәчет) *әл-Хәрам мәчете, әл-Әкъса мәчете һәм минем мәчетем”*, дигән хәдис шәрифне Бохари белән Мөслим риваять итәләр һәм гыйлем әһелләре кабул итәләр. Бу хәдис хөкеменә күрә гыйбадәт вә зиярат максаты белән әлеге өч мәчеткә сәфәр кылу шәригатьтә урыны булган һәм күркәм бер гамәл булып, моннан башка урыннарга, кирәк пәйгамбәрләр каберләре, кирәк башка бер мөбарәк урыннар булсын, гыйбадәт максаты белән сәфәр кылу (хосусый дәлил булмаганга) хәрамдыр. Сәфәр хәрамлыгыннан асыл зиярат хәрамлыгы аңлашылмасын, моның әүвәлгесеннән соңгысы лязем түгел. Мәдинәдә булган кеше өчен, шәргый сурәттә булу шарты белән, Пәйгамбәр каберен, шулай ук Бохари, Мөслим һәм бәкыйгъ әһле, Коба һәм Ухуд шәһидләрен зиярат итү күркәм бер гамәлдер. Мәсьәлә зиярат хакында түгел, бәлки зиярат нияте белән сәфәргә чыгу хакындадыр. Зиярат нияте белән пәйгамбәрләр һәм хөрмәтле затлар каберләренә сәфәр кылу элекке гасырларда юк иде. “Пәйгамбәр каберенә бару хакында нәзер кылган кеше өчен нәзерен үтәү тиешме?”, - дигән сорауга җавабында имам Мәлик: “Әгәр дә барудан максат мәчеткә бару булса, нәзерен үтәү тиеш, әмма максаты хакыйкать хәлдә кабер шәрифен зиярат итү булса, бармасын, бу эш тыелгандыр!” - дигән. “Кем хаҗ кылып та, мине зиярат итмәсә, ул миннән читләште. Мине вафатымнан соң зиярат итүче мине исән вакытымда зиярат итүче кебек. Кем мине һәм әтиемне бер елда зиярат кылса аңа җәннәт тиеш булыр. Сезгә куркыныч килсә, кабер әһелләренә барыгыз” кебек хәдисләрне, шулай ук каберләр һәм мәшһәдләргә зиярат итүнең күркәмлеге хакында булган әсәрләрнең күбесен рафидыйлар уйлап чыгарган. Хәтта болар каберләргә зиярат кылуны хаҗ гамәле бәрабәрендә күреп, моның хакында “каберлекләрдә үтәлә торган гамәлләр” дигән китаплар язганнар. Пәйгамбәрнең каберен зиярат кылу турындагы хәдисләр барысы да зәгыйф хәдисләр булып, аларның берсенә дә таяну тиеш түгел. Шуңа күрә дөрес хәдисләрне туплаучылар аларның берсен дә китермиләр, аларны зәгыйф хәдисләрне риваять кылган Дәракутный, Бәззәр һәм башкалар гына китерә.

Пәйгамбәр каберләргә утырудан һәм анда гыйбадәт кылудан тыйды. Сәхәбәләр дә мәчеткә кергәч кабер шәриф янында туктап тормаслар, кайвакыт сәлам бирерләр иде. Пәйгамбәребезгә хөрмәт һәм аны олылау - аның боерыкларын җиренә җиткерү һәм Ислам

рухында могамәлә кылудан гыйбарәттер. Югыйсә, шәригать максатына каршы рәвештә олылау, олылау түгел, бәлки мыскыл итү булыр”.

Ибне Тәймия тарафыннан әйтелгән әлеге сүзләргә күрә Болгар шәһәренә, Биләргә, Сөенбикә манарасын күрергә, Әстерхан әүлияләре, хуҗалар таулары, сын таш чишмәләре, Әхмәд Ясәви һәм Хуҗа Баһаведин төрбәләре, Сөләйман тәхете һәм башка, һәм башка шуның кебек урыннарга баручылар, әгәр дә җәмгыятьләр күрү һәм гаҗәеп табигатьне карау, борынгы әсәрләрне һәм тарихи урыннарны тамаша кылу нияте белән сәфәр кылсалар, монда зарар юк, бәлки файдалы гыйлем һәм гыйбрәт алу ноктасыннан гүзәл эшләр булырга мөмкин. Әгәр дә ярдәм сорау һәм ахирави файдалар өмет итү максаты белән булса, хәрамдыр. Беренче сурәттәге сәфәр, дөньяви һәм мөбах бер гамәл булып, соңгысында исә, диннән булмаган бер нәрсә белән дин тоту буладыр. Уй-фикер белән дин төзү исә шәригать күзлегеннән караганда тыелган бер эштер. Дөресен Аллаһ яхшырак белер.

Чынлыкта, диннәрнең үзгәрүләре һәм бозылулары усаллар, бозык адәмнәр тарафыннан түгел, бәлки яхшы адәмнәр яхшы ниятләр белән аз-аз булса да арттыра барулары сәбәбеннән булыр. Дингә нур бирү һәм динне сөекле итеп күрсәтү изге нияте ахырда зарарлы нәтиҗәләр бирә һәм диннәрнең кагыйдәләре үзгәреп, асыллары бозылуга сәбәп була. Шуңа нигезләнгән булса кирәк: “Шатлык хәбәре килгән вакытта шөкер сәҗдәсе кылсыннармы?” - дип сораучыларга, имам Мәлик: “Кылмасыннар, мондый эш Расүлуллаһ заманында юк иде”, - дип җавап биргән. Сораучы исә кабаттан: “Ямәмәдә мөселманнарның җиңү хәбәрен алгач, Әбү Бәкер әс-Сиддыйк шөкер сәҗдәсе кылган иде”, - дигәненә, имам Мәлик хәзрәтләре: “Мондый вакыйганы ишеткәнем юк, үз уем белән әйтсәм ялган булыр, Рәсүлуллаһ һәм аннан соң мөселманнар ни кадәр шәһәрләр яулап алдылар, әмма һичберендә мондый рәвештә шөкер сәҗдәсе кылганнары хәбәр ителмәде. Алар арасыннан берсенең сәҗдә кылганын ишеттеңме? Бу иҗмаг, әгәр сиңа бер гамәл ирешсә һәм син аны белмәсәң, аны калдыр”, - дигән. Имам Мәлик бу сүзе белән Аллаһ Тәгаләгә сәҗдә кылуны һәм нәфел намаз укуны тыймас, бәлки гасыр сәгадәттә һәм элекке мөселманнарда күренмәгән рәвешләр белән дини бер гамәл барлыкка китерүдән тыядыр.

### *5) Иҗмаг, иҗтиһад һәм тәкълид.*

Әлеге мәсьәләләр хакында Ибне Тәймия әйтә: “Дини бер эш хакында үзенең әһелләре тарафыннан иҗмаг булса, шуңа каршы килү дөрес түгелдер. Һәрхәлдә, өммәт адашу юлына җыелмас һәм шәригатькә каршы карар кылмас. Иҗмаг хакында белергә тиешле кагыйдәләр бик күп. Иҗмаг кылуга күп кешеләр җиңел карыйлар, бер иҗмаг булмас, хәтта ки турыдан-туры Коръән Шәриф һәм Сөннәткә каршы нәрсәләргә иҗмаг дип әйтергә теләүләре күрелер. Кайбер адәмнәр дүрт мәзһәб мөҗтәһиде тарафыннан уртак булган сүзләргә иҗмаг хөкеме бирергә телиләр. Мәшһүр дүрт мөҗтәһид, яки алардан башкаларның сүзләре, каршы килү дөрес булмаслык дәлилләрдән түгел. Дүрт мөҗтәһид тарафыннан килешенгәнгә күрә генә, шәргый иҗмаг булмас. Шуның өчен әлеге мөҗтәһидләр дәлилләрен белмичә үзләренә иярүдән тыйганнар, Коръән һәм Хәдис Шәрифкә каршылыклы күрелгән сүзләре белән гамәл кылмаска нәсыйхәт иткәннәр. Дөреслектә, бөтен хәдисләрне туплап бетерү бер өммәттән һичкемгә насыйб булмас. Сәфәрдә һәм өендә, кичә һәм көндезләрнең күбесендә Пәйгамбәребез янынннан аерылмас булган Әбү Бәкер әс-Сиддыйк хәзрәтләренә кайбер хәдисләр билгеле булмыйча калды исә, башка мөҗтәһидләргә билгеле булырмы? Хосусан мөҗтәһидләр гасырларында мөхәддисләр бик таралган иде. Хәдис китаплары исә, алардан соң язылды. Шул сәбәпле мәзһәбләргә ияргән галимнәр арасында бик күп затлар, бик күп мәсьәләләрдә үзләренең имамнарына, хәтта ачык сүзләренә дә каршылыклы булырлар”.

### *6) Гыйлме кәләм һәм тәсавуф.*

Гыйлме кәләм һәм тәсавуф хакында Ибне Тәймия әйтә: “Дин һәм аның гыйлемен өйрәнү турысында кешеләрнең бер шәргый һәм ике бидгать юллары бар. Бидгать юлларның

берсе гыйлме кәләм юлы һәм икенчесе “әһле риядат” вә “әһле тәсавуф” юлыдыр. Шәргый булган юлы исә, Расүлуллаһ китергән сөннәт юлыннан һәм шуның белән фикер йөртеп, гамәл кылудан гыйбарәттер. Расүлуллаһ алып килгән шәригать гыйлеме кәләм китапларында әйтелгән нәрсәләрдән үзгәдер. Гыйлме кәләм, шөбһәгә тоташтыручы юл булып, аның белән мәшгуль булганнардан күпләр ахыр гамәлләрендә аптырап, чарасызлык эчендә калырлар һәм кайберләре барлык башка кешеләр иманына кире кайтуны игълан иткәннәрдер. (Табигый, белүчеләр һәм хакыйкатьне аңлаучылар, яки галимнәргә иярүчеләр аптырап калмаслар, әлбәттә!) шуның өчен сәләфләр (элекке мөселманнар) гыйлме кәләм белән шөгыльләнүдән тыйганнар. Хөрмәтле сәхәбәләр һәм тәбигыйннар арасында галәмнең барлыкка килүен, хәрәкәт һәм тынычлык, җисем һәм материя барлыкка килүе белән бәйле дип нәтиҗә чыгаручы булмады. Кайберәүләр элекке мөселманнарның гыйлеме кәләмне сөймәү сәбәбен материя, җисем һәм очраклылык кебек яңа терминнарны үз эченә алганга дип күрсәтергә теләсәләр дә, алай түгел. Бәлки кәләмнең кабул ителмәвенең сәбәбе асылда ялган бер нәрсә булганы өчендер. Кәләмдә булган күп кагыйдәләр Коръән һәм Сөннәткә каршыдыр.

Соңгы заманнарда тәсавуф әһелләре үзләренең әлеге юлларын хәзрәти Гомәр белән хәзрәти Галигә нисбәт итеп, һәр икесеннән хирка (суфиларның киеме яки могҗиза-кәрамәт. Тәр.иск.) вакыйгасын риваять итәрләр. Болар каршында хәзрәти Гомәр хиркасының ике иснәде булып, берсе Үвәйс әл-Карни һәм икенчесе, Әбү Мөслим әл-Хуләни васитасы беләндер. Хәзрәте Гали хиркасының иснәден бер мәртәбә Хәсән Басрый, Хәбиб Гәҗәми, Дауд Таъий, Мәгъруф Кәрахи, Сирри Сәкътый, Җүнәйд дип, һәм икенче мәртәбә Гали бин Муса Рида, Мәгъруф Кәрахи, Сирри Сәкътый, Җүнәйд дип тәртип кылырлар. Бу иснәдләр иснәд гыйлеме кагыйдәсенә күрә дөрес түгел. Җүнәйднең Сирри белән, Сирринең Мәгъруф белән күрешүендә шөбһә юк, бу тарихта билгеле. Әмма Мәгъруф Кәрахинең Гали бин Муса Риданы күрүе мәгълум түгел. Мәгъруф “Кәрах” дип аталган җирдә дөньядан киселеп гыйбадәт белән мәшгуль булды. Гали бин Муса исә халифәт варисы иде. Мәгъруф хакында язылган хосусый китапларның һичберендә моңа кагылышлы хәбәр юк. “Мәгъруф Гали бин Муса Рида янында мөселман булып аңа капка сакчысы булып хезмәт итте”, дигән сүз ялгандыр. Шулай ук Мәгъруф Дәуд Таъий белән һәм Дауд Таъий Хәбиб Гәҗәми белән аралашулары да ышанычлы билгеле түгел. Хәсән Басрый хәзрәте Гали белән аралашуы хакында мөгътәбәр тарихчылар бердәм фикердәдер.[1] Хәсән Басрый Әхнәф бин Кайс һәм Кайс бин Гыйбәд кебек хәзрәте Гали сәхәбәләреннән файда күрде. Тәсавуф хакында үзебездә иснәд булганга иснәдләрне тикшерергә кирәк дип тапкан идек. Табылган нәтиҗә шулдыр, әлеге урында күрсәтеп үттек. Сәхәбәләр һәм тәбигыйннар арасында хирка кидерү, шәйхлек һәм мөридлек, мөршидлек һәм дәрвишлек кебек нәрсәләр гомумән юк иде. Бәлки алар арасында берәү дә икенче берәү белән хасланмаслар, кем туры килсә шуннан әдәб һәм гыйлем өйрәнерләр иде. Алар каршында остаз һәм шәйхләр җәмәгать намазында булган имамнар һәм хаҗ вакытындагы дәлилләр урынында булып, дөрес гамәлләренә ияреләр һәм хаталарына иярмәсләр иде. Һәрхәлдә аларда шәйх һәм остазларны гыйбадәт кылына торган зат хөкемендә тоту юк иде. Тәсавуф әһелләрен мактаучылар да, сүгүчеләр дә, һәм һәр ике тарафта чиктән чыгучылар күп. Дөреслектә, алар арасында бик яхшы һәм файдалы затлар булган кебек, бик зарарлы һәм усал кешеләр булуы да кире кагылмас”.

***7) Зул-Карнәйн.***

Коръән Шәрифтә әйтелгән Зул-Карнәйн хакында Ибне Тәймия әйтә: “Аристу (Аристотель) шөһрәтенә хәйран булып та, аның шөһрәтен тарату нияте белән булса кирәк, кайбер мөфәссирләр Аристу вәзирлек иткән Искәндәр әл-Макидонины Коръән Шәрифтә әйтелгән Зул-Карнәйннең үзе диярләр. Бу сүз җаһәләт әсәреннән башка нәрсә түгелдер.

[1] Хәсән Басрый өлкән тәбигыйннардан, Госманны күргән, аның хөтбәсен тыңлаган, Галине күргән, аның сүзләрен тыңлавы билгеле түгел.

Аристу вәзирлек иткән Искәндәр әл-Макидони юнанлы (грек) бер патша булып фарсылар дәүләтен яулап алса да, Чин (Кытай) мәмләкәтенә бармавы, яәҗүҗ-мәәҗүҗ киртә-диварларын бина кылып йөрмәве мәгълүмдер. Зул-Карнәйн исә Искәндәр әл-Макидонидан ничә гасыр элек килгән бер кеше иде”.

***8) Могавия һәм Язид.***

Бу ике зат хакында Ибне Тәймия әйтә: “Имамат дәгъвалары һәм хәлифлек низаглары мәйдан алганнан соң Ислам әһле арасына күп сүз таралды. Кайбер сәхәбәләрнең өстенлекләре хакында күп хәдисләр килеп чыкты. Хәдис һәм сөннәт гыйлемнәрендә оста кешеләр белерләр ки: Могавияне хурлау һәм мактау хакында булган хәдисләр мәудугълар (уйлап чыгарылганнар). Бер тарафның аны хурлап хәдисләр чыгаруына каршы, икенче тараф аны мактап хәдисләр уйлап чыгардылар һәм һәр ике тараф яла ягу һәм ялган белән бәлаләнделәр. Могавия табигате белән йомшак һәм сабыр, акыллы һәм уйлап эш итүче, моның өстенә фәкыйһ бер адәм иде. Тәбигыйннардан Кутәдә: “Әгәр гамәлдә Могавия мисалына ирешсәгез, күпләрегез бу Мәһди дип әйтер иде”, - дигән.

Могавиядә кимчелек булса да, бу кимчелек үзеннән алдагы хәлифәләрдә дә булып, үзеннән соңгыларга караганда күркәм вәгъдәле мөселмандыр. Аның дәрәҗәсендә бер хәлифә ни өмәвиләрдә, ни габбасиларда күрелмәде. Аның хакында “хәзрәте Хәсән радый Аллаһү ганһүгә агу бирдерде” дип чыгарылган хәбәр ышанычлы түгел. Мондый хәбәрне исбатлау өчен я бинаи шәргыйя, я икрар тиеш булыр. Хәлбуки урталыкта боларның һичберсе юк. Имеш-мимеш белән макталуы ышанычлы булмас. Расүлуллаһ: *“Уйдан сакланыгыз, уй хәбәрнең иң ялганы”*, - дигән. Хәзрәте Гали исән вакытта Могавиянең хәлифәлеге дөрес түгел иде. Шулай ук аның улы Язид хакында да кешеләр чиктән чыгып киттеләр. Кайберәүләр: “Язид үзенең туганнарыннан булган Готбә бин Рабига, Вәлид һәм башкаларның Бәдер сугышында мөселманнар тарафыннан үтерелүләренең үчен алу нияте белән Пәйгамбәребез хәзрәтләренең оныгы булган Хөсәен радый Аллаһү ганһүне үтертте һәм бу хакта шатлык белдерде, хәзрәти Хөсәеннең башын Шамга китергәннән соң кулындагы таягы белән хәзрәти Хөсәеннең тешләренә сукты, Язид мөртәд һәм кәфер иде” дигәннәре хәлдә, икенчеләре: “Язид олуг сәхәбәләрдән һәм әүлияләрдән булып, холәфәи рашидиннең берсе иде”, диярләр. Мондый бер-беренә капма-каршы булган сүзләрнең һәр икесе дә чиктән чыгудыр. Язиднең Хөсәен радый Аллаһү ганһү хәзрәтләрен үтерү хакында әмер бирүе төгәл билгеле булмаганы кебек, башын Димәшкъка, Шамга китерү хәбәре дә ялгандыр. Инде тешләренә таяк белән сугу ни җирдә? Бу турыда билгеле бер эш булса, ул да Язиднең Хөсәен радый Аллаһү ганһүне Гыйрак вилаятенә килүдән тыю өчен гаскәр җибәргәндер. Алар бер-берләре белән очрашкач, Язид тарафы әсир итеп алыр, һәм хәзрәти Хөсәен дә әсирлеккә бирелмәс өчен сугыштылар һәм хәзрәти Хөсәен радый Аллаһү ганһү әлеге вакытта шәһид булды. Язид Госман радый Аллаһү ганһү халифәлеге вакытында туганы өчен сәхәбәдән саналмас, диндарлык һәм изгелек белән дә исеме юк иде. Кәфер һәм мөртәдлеге дә шәргый бер дәлил белән исбатланган түгел. Фәкать тормыш юлы гүзәл түгел иде. Аны олуг сәхәбә дип уйлаучылар, агасы булган Язид бин Әби Суфьян белән бутыйлар. Язид бин Әби Суфьян мөхтәрәм сәхәбәләрдән булып, Әбү Бәкер радый Аллаһү ганһү тарафыннан Шам вилаятенә (өлкәсенә) әмир итеп билгеләнде. Мәдинәдән үзенең хезмәт урынына бару нияте белән сәфәр чыкканда Әбү Бәкер әс-Сиддыйк дөясе яныннан озата барды. Язид дөядән төшеп бергә барырга теләсә дә, хәзрәти Әбү Бәкер ризалык бирмәде һәм: “Мин бу адымнарымны Аллаһ юлында атлыйм”, - дип күп җир барды. Аның вафатыннан соң урынына Могавия калып, бөтен Ислам әһле өмәвиләр кул астында калды.

Язид хакында булган яхшы вә яман хәбәрләр дошманнарга каршылык йөзеннән гадәттән тыш зурайтылганнардыр. Шуның белән бергә, аның халифә булуын гомум әһле Ислам мәкруһ күрде. Хәзрәте Хөсәеннең шәһид булуы белән Мәдинә камалышы әһле Ислам өчен тиңе булмаган бәла-казалардан булды. Әгәр дә хәзрәти Хөсәенне үтерергә әмер

бирмәсә һәм үтерелүенә риза булмаса, ризалыгыннан башка хәрәкәт итүче хезмәтчеләренә җәза бирергә тиеш иде. Хәлбуки, мондый могамәләләр күрелмәде. Хаклык тарафдарлары әлеге гамәлләре өчен Язиддән риза түгелләр, фәкать ни кадәр ачулары килсә дә, шәригать кагыйдәләренә каршы килүдән куркып сабыр итүдә булырлар. Билгеле бер шәхескә ләгънәт кылу дөрес булмаганга, ләгънәт кылырга хәлебездән килми. Шуның кебек үк, аның тарафыннан кылынган хәерсез эшләргә дә ризалыгыбыз юк. Әхмәд бин Хәнбәл хәзрәтләренә үзенең улы Салих: “Фәлән кешеләр Язид бин Могавияне мактыйлар”, - дигәненә: “Аллаһ Тәгаләгә һәм Ахирәт көненә иманы булган кеше ни йөзе белән Язидне мактар?” - дигән. Улы: “Алай булгач, үзегез ни өчен ләгънәт кылмыйсыз?”, - дигәненә: “Әй, улым! Әтиең тарафыннан кемгә ләгънәт кылганны ишеткәнең бар?”, - дигәндер. Һич шөбһә юктыр ки, хәзрәти Хөсәен мәзлум булды һәм шәһид булды. Аны үтерү олы гонаһлардан иде. Иншә Аллаһ, бу хәл үзе өчен мәртәбәсе күтәрелергә сәбәп булыр. Аның өчен кайгырырга һәм “Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун” дип әйтелергә тиешле, ләкин киемнәр erту һәм тәннәрне кыйнау кебек Аллаһ Тәгалә һәм Аның Илчесе риза булмаячак нәрсәләрдән тыелу тиешледер. Аллаһның Илчесе: *“Үзен яңаклаучы һәм киемнәрен ертучы бездән түгел”*, - дигән. Хәзрәти Хөсәен үтерелү мөнәсәбәте белән әһле Ислам арасына ике төрле бидгать таралды. Берсе гашура көнендә кайгыру һәм елау бидгате, икенчесе шул көнне бәйрәм итү бидгате. Шигыйлар кайгыру бидгатен мәйданга чыгарганнары хәлдә, аларның каршылары аларга каршылык йөзеннән генә гашурә бәйрәме бидгатен уйлап чыгардылар һәм үз карашларын тарату өчен һәр ике караш әһле хисапсыз уйдырмалар, ялганнар уйлап чыгардылар. Бу бидгатьләрнең һәр икесе чып-чын адашудыр. Ислам динендә гашурә көнендә кайгыру да, бәйрәм итү дә юк! Гашурә көнендә ураза тотуның яхшы булуы турында хәдис бар, шуннан башка бер нәрсә дә юк. Без Язидкә ләгънәт кылмавыбыз, кәфер һәм мөртәдлеге белән хөкем кылмаганыбыз кебек, эшләгән эшләренә ризалыгыбыз һәм үзенә мәхәббәтебез дә юктыр. Бу кешенең хәле безгә түгел, Хак Сөбхәнәһү вә Тәгаләгә тапшырылгандыр. Аллаһ ни теләсә шуны эшли, ничек теләсә шулай хөкем итә һәм колларына золымлык кылмый”.

***9) Гакыл белән нәкыл арасында аерма.***

Ибне Тәймия кәләм әһленең: “Гакыл белән нәкыл арасында аерма булганда, гакыл алдарак булыр”, - дигән дәгъваларын катгый сурәттә кире кагып, бу турыда “Муафакат сарих әл-Мәгъкул лисахих әл-Мәнкул” дип аталган бөек бер әсәр язган.

***10) Кайбер хәдис китаплары һәм мөхәддисләр хакында булган фикере.***

Ибне Тәймия Әхмәд бин Хәнбәл “Мөснәд”е хакында әйтә: “Анда булган хәдисләрнең һәрбере дә Әхмәд хәдисе түгел, бәлки аның улы Габдулла тарафыннан кушылган хәдисләр бар. Хосусан Габдулла, Гали ибне Әби Талиб мөснәдләре арасына күп хәдисләр арттырды”.

Китабул-Фирдәүс хакында әйтә: “Моның туплаучысы булган Ширвия бин Шәһреяр әл-Дәйләми, һәрникадәр хәдис голәмәсеннән булса да, әлеге әсәрендә мәудугъ хәдис бик күптер”.

Бәйһакый хакында әйтә: “Сәхәбәләр фазыйләте хакында зәгыйфь, бәлки мәудугъ хәдисләр риваять итәдер, бу турыда Бәйһакый үзе генә түгел, иптәшләре дә бардыр”.

“Хәлия әл-Әулия” хакында әйтә: “Моның язучысы тугры хәлифәләр фазыйләтләре хакында зәгыйфь, бәлки асылсыз хәдисләр риваять итте. Дәракутный, Бәззар зәгыйфь хәдисләр риваять итүдән сакланмаслар”.

***11) Могҗизалар һәм кәрамәт. Хозыр һәм Ильяс. Котыб, Гәүс һәм Ибдәл.***

Әлеге мәсьәләләр һәм әлеге исемнәр хакында Ибне Тәймия әйтә: “Могҗизаның пәйгамбәрлеккә дәлиллеге булса да, гаҗәеп гадәтләрнең вәлилеккә дәлиллеге юктыр. Бер кешедә гадәттән тыш гаҗәп бер нәрсә барлыкка килүеннән, әлеге кеше Аллаһ Тәгаләгә якын һәм дус булырга тиеш дип табылмас. Аллаһ Тәгаләнең үзенә мәгълүм булган серләр

сәбәбеннән кайвакыт гаҗәп нәрсәләр намаз укымаучы һәм хәрамнардан тыелмаучылар, хәтта ки диннәре бөтен булмаган кешеләрдән, бәлки Аллаһ Тәгаләнең дошманнарыннан да килеп чыгар. Нәтиҗә: могҗизалы гаҗәп нәрсәләрнең һәрберсе кәрамәт булуы шарт түгел. Кайчак милләтләрнең адашуларына иң беренче сәбәпләрнең берсе могҗизалы нәрсәләр булды, шайтан исә боларны әлеге нәрсәләр белән алдады. Насараларның мохтаҗлыкка төшеп ярдәм сораган һәм ялварган чакларында хәзрәти Гыйсә һәм Мәрьям радый Аллаһү ганһәне күрүләре һәм аларның ярдәм сорауларына күренүләре, кабер әһелләренең каберләрдән чыгып күрешүләре һәм кочаклаулары күп тапкырлар күрелгәндер. Кешеләр арасында "серле кешеләр" дип данлыклы булган җаннар хакыйкатьтә җеннәрдер. Алар арасында яхшы затлар булганы кебек, усаллар һәм шайтаннар да күптер.

Чынлыкта әлеге соңгы төркем кешеләрне аздыру хакында һәр төрле сәбәпләргә керешерләр һәм күбрәк вакытта гыйбадәт һәм яхшылык юлларыннан килеп наданнарны аздыруда максатларына ирешерләр. Кайберәүләр билгеле бер шәйх сыйфатына кереп һавада очып йөрерләр һәм кайберләре мәшһүр шәйхләргә тәгам һәм эчемлек, җәй көнендә кышкы ашларны, кыш көнендә җәй нигъмәтләрен китерерләр. Моннан максатлары исә шәйхнең кәрамәт һәм могҗиза гадәтен башкаларга игълан итү, шәйхнең үзен һәм иярченнәрен адаштыру булыр. Китап һәм Сөннәт гыйлемнәреннән хәбәрләре аз һәм Пәйгамбәр хәзрәтләренә иярүләре дә дәлил һәм гыйльми эзләнүгә нигезләнеп түгел, бәлки тәкълид белән генә булган затлар әлеге вакыйгалар сәбәбеннән үзләренең һаваларына ияреп юлдан язганнар һәм язарлар. Кайбер җеннәр арыслан сурәтенә кереп, юлдан яздыру нияте белән, кайбер шәйхләрне өсләренә атландырып йөриләр. Кайбер җеннәр вафат булган шәйхләр сурәтләренә кереп: "Без кабердә тормыйбыз, бәлки халык арасына чыгып йөрибез", - дип әйтерләр, һәм кайберләре Гарәфәттә булган шәйхләр сурәтенә кереп, Багдад һәм Басра кебек ерак шәһәрләрдә күренерләр. Кайберләре кешеләргә Кагъбәне тәваф кылдыруны хыялларына кертеп һәм кайберләренә Гареш, Ләүхул-Мәхфузлар күргән кебек итәрләр. Китап һәм Сөннәт гыйлемнәреннән гафил булганга мондый хәлләр белән фетнәләнүчеләр күп булыр. Китап һәм Сөннәт гыйлемнәреннән өлешләре булган кешеләр исә боларга алданмаслар.

Мондый җеннәрнең кайберләре, кайбер кешеләргә үзләрен Хозыр һәм Ильяс пәйгамбәрләр, шулай ук кайбер кешеләргә хәзрәти Гыйсә һәм Мөхәммәд (аларның барысына салават һәм сәлам булсын) исемнәре белән күренерләр һәм ничек булса да бер бозыклык эшләп файдаланырлар. Бер гаҗәп вакыйга үзебез белән булды: Димәшкъ шәһәрендә төрекләр һәм татарларны иманга чакырып йөрдем, шактый кешеләр Ислам белән хөрмәтләнделәр һәм гыйлем йөрәнделәр. Шуннан беркадәр вакыттан соң Мисырга киттем. Мисырда мине бер кальгага яптылар. Минем һичнәрсәдән хәбәрем булмаганда, минем ябылып торган вакытымда, Ибне Тәймия Димәшкъта татарларны иманга чакырып йөрер имеш. Моны белгәч, минем төрмәдән качуым белән хөкем ителеп, хөкүмәт тарафыннан тикшерү булды. Хөкүмәт мине төрмәдә тапканнан соң ни диярга дә белмәде. Мин үзем: "Мине ярата торган берәр җен минем кыяфәтемдә йөреп, минем вазыйфаны үтәгән булса кирәк", - дип уйладым. "Гыйсә пәйгамбәр асып куелганнан соң хәвариуннарга күренде", - диярләр. Бу хәбәр дөрес булса, ихтимал аның кыяфәтендә берәр җен күренгәндер. Хәлләҗ, асылганнан соң, сәламәт хәлендә күренеп ни кадәр мөселманнар фетнәләнделәр. Вафат булганнан соң, Дәсукый мөридләре: "Шәехебез һәрвакыт мәҗлесебезгә киләдер", - дип, Дәсукый хакында ни кадәр чиктән ашкан сүзләр сөйләделәр. Чынлыкта, болар кыяфәтенә керүчеләр җеннәр булып, кешеләрне адаштыру нияте белән эшләрләр. Хәзрәти Гали һәм дә улы Мөхәммәд бин әл-Хәнәфиянең бу көндә сәламәт күренүләрен әйтүчеләрнең сүзләре шуның кебек ялгышлыкка нигезләнгәндер. Халык ни кадәр надан һәм хорафатларга ышанучы, ялгышучан булса, алар арасында мондый хәбәрләр күп булыр. Болардан саклану өчен бер генә юл бар: дөрес гакыл һәм шәригатьне

Китап, Сөннәттән алу. Коръән Шәриф һәм Пәйгамбәребезнең хәдисләренә күрә, юлчыларга Хозыр белән Ильяс күренүләре риваять ителмәгән һәм ителмәячәк.

Хозыр һәм Ильяс, Котыб һәм Ибдәл кебекләргә ышану мөселманнарга йөкләнмәде. Хәтта болар хакында таралган хәбәрләр дөрес бер асылга да нигезләнмәгән. Шигыйларның көтелгән имамны көтеп торулары ни кадәр мәгънәсез бер нәрсә булса, башкаларның Хозыр һәм Ильясны бүген тере дип ышанулары да шуның кебек бер нәрсәдер. Хозыр һәм Ильяс вафат булмаган, бәлки тере исә, алар хакында Расүллуллаһ хәзрәтләре үзенең сәхәбәләренә ни өчен бер сүз дә әйтмәгән, әйткән булса ни өчен мөхәддисләр тарафыннан тапшырылмаган? Бик күп кешеләр, берәм-берәм Хозырны һәм Ильяс пәйгамбәрне сәламәт күргәннәр һәм сөйләшкәннәр имеш. Болар үзләренә күренгән кешеләрне Хозыр һәм Ильяс икәннәрен каян белгәннәр? Үзләренең хәбәрләреннәнме? Бүген берәү килеп: “Мин Нух пәйгамбәр, әле һаман яшимен!” – дисә, шул Хозыр һәм Ильяс сүзләренә ышанучылар, әлеге кешенең Нух пәйгамбәр икәненә ышанырлармы? Хозыр һәм Ильяс пәйгамбәрләр башка кешеләр кебек табигый гомер кичереп, вафат булганнар, хис һәм хакыйкатькә каршы сүз сөйләү әһле Ислам өчен яраклы түгел, мондый нәрсәләр Ислам диненнән иминлекне юкка чыгаруга сәбәп була. Үзе куйган тәкъдирдә, кирәк суда, кирәк коры җирдә булсын, җаннарны һәлакәттән саклау Аллаһ Тәгаләнең Үзенә генә хастыр. Бу эштә Хозыр һәм Ильяс кебекләргә ихтыяҗы юк. Хозыр һәм Ильяс бүген сәламәт булсалар, кешелек һәм Ислам халкы өчен болардан ни файда булыр? Диңгездә яки коры җирдә һәлак булу, ахирави һәлакәт янында һични түгел. Шулай булгач, Хозыр белән Ильяс кешеләргә котылу юлларын өйрәтеп йөрергә тиеш иде.

Бүген Хозыр белән Ильясны исәннәр дип әйтү бөтенләй нигезсез булганнан тыш, шигыйларның “имам килүе көтелә” дигән ышануларына дәлил хәзерләп бирү, шуннан башка бер нәрсә юк. Котып, Гәус, Әутәд, Ибдәл хакында булган хәдисләр берникадәр Әбү Нәгыйм һәм башкалар тарафыннан риваять ителсә дә нигезләре юктыр”[1].

***12) Тыңлау, бию һәм көферлеккә чыгару.***

Әлеге мәсьәләләр хакында Ибне Тәймия әйтә: “Нәфесне тәрбия итәргә һәм әхлакны төзәтергә сәбәп булган Коръән Шәрифне тыңлау шәригать гамәле булуында каршылык юк. Динебездә иркенчелек булуны белдерер өчен булса кирәк, Рәсүлуллаһ хәзрәтләре туй вакытларында хатыннарның шөлдерле барабан сугуларын һәм гает көннәрендә җарияләрнең шигырь укуларын да тыймаган. Әмма Коръән Шәрифтән башка нәрсәләрне тыңлау, гыйбадәт гамәле дип дәгъва кылырга урын булмаса да, дөрес булу-булмавында сөйләшергә урын бар. Бию тыелган бер нәрсәдер. Гонаһларның иң олысы мөселман кардәшләрне көферлектә гаепләү. Һәрбер хата кылган кешенең кяфер булуы, хәтта фасикъ һәм Аллаһка итәгать итмәүче булуы да шарт түгел. Шуның өчен Ислам милләтен вак, әһәмиятсез нәрсәләр белән бүлгәлиячәк җирдә, мөмкин кадәр һәрберен бер ноктага җыярга тиеш. **“Барыгыз да бергә Аллаһның бауына тотыныгыз һәм аерылмагыз”.**

***13) Талак һәм аеру.***

Әлеге мәсьәләләр хакында Ибне Тәймия әйтә: “Зыйһар ниятләп бер кеше талак белән ант итсә, талак булмас, бәлки кәффәрат кенә тиеш булыр. Хәез вакытында булган талак талак түгел. Коръән укып хатем ителгәндә “өч мәртәбә” дип әйтү, яки тәсбих һәм тәһлил әйтеп тә “йөз тапкыр” яки “мең тапкыр” дип әйткән белән бер тапкырдан артмавы, артыннан сан кушып кына мәгънә булмаган кебек, “талак” сүзендә дә сан кушудан мәгънә юк, бәлки телдәге бер нәрсәдер. Шуңа күрә хатынына: “Сиңа талак өч тапкыр”, - дип әйтер

[1] Хозыр һәм Ильяс мәсьәләләрендә Ибне Тәймия тарафыннан “җен” дип аңлатылган нәрсәне, бүген мәйданга чыгып күп тарафдар пәйда иткән “әрвахлар белән сөйләшү” мәсьәләсе дип әйтергә мөмкин булса кирәк. Күзгә күренмәс нәрсәләрнең һәрберенә “җен” дип әйтү дөрестер. Гайре табигый нәрсәләрнең, табигать серләреннән булуын бүгенге фән исбат итә. Бу сер аз-аз ачылып торуы мәгълүм. Моңа кагылышлы кайбер нәрсәләр “Мәшһүр кешеләр” җыентыгының 4 кисәге булган “Ибне Гарәби” исемле әсәрдә язылды (10 бүлек). Шуңа мөрәҗәгать ителә.

булса, өч түгел, бәлки ялгыз бер генә талак булыр. Аеру нияте белән булган никахлар шәргый яктан дөрес никах түгел. Шуңа күрә аеру нияте белән өйләнгән хатыннар, талактан соң да беренче ирләренә хәләл булмаслар, бәлки кабат шәргый никах һәм аеру тиештер.

***14) Ният, мөсафир һәм җомга сөннәте.***

Әлеге мәсьәләләр хакында Ибне Тәймия әйтә: “Ният тел белән сөйләүдән түгел, ә күңел белән ният кылудан гыйбарәт. Теле бер нәрсә сөйләп тә, күңеле икенче бер нәрсә уйлаган кешенең теле белән сөйләгән сүзенә игътибар булмас: ният шарт булган гыйбадәтләрдә күңел нияте булмаган хәлдә тел хезмәте мәгънәсездер. Бәлки гыйбадәт вакытында тел белән сөйләү бидгать һәм шәригать күзлегеннән чыгып караганда тыелгандыр.

Шәргый гамәлләр хакында кайбер рөхсәтләр белән аерылып торган сәфәр көн һәм ара ераклыгы белән чикләнгән түгелдер. Бәлки гореф-гадәттә сәфәр исеме биреләчәк йөрүләрнең һәрбере сәфәр булып, шуның белән мөсафирлар сәфәр хакында булган рөхсәтләр белән файдалана алырлар.

Җомга азагыннан соң Рәсүлуллаһ мөнбәргә менеп ике хөтбә укыр һәм азан белән хөтбә арасында җомгага өстәмә итеп намаз укылмас иде. Сәхәбәләр һәрвакыт мәчеткә кергәч, үзләре теләгән рәкәгать хисабы белән намаз укыр булсалар да, бу намазлар мәчеттә укылган нәфелләр булып, җомга сөннәтләре түгел. Сөннәт димәк, Рәсүлуллаһтан билгеле булган, ул үтәгән гамәл. Җомгага кадәр Рәсүлуллаһның җомга сөннәте укуы ныклы билгеле булмаганга, хөтбәдән алда “җомга сөннәте” исемендә намаз шәригать билгеләгән эш түгел. Җомга намазыннан соң, Бохари һәм Мөслим риваятенә күрә, ике рәкәгать һәм Мөслим риваятенә күрә дүрт рәкәгать сөннәт укуы мәгълүмдер. Кайвакыт ике һәм кайвакыт дүрт рәкәгать укыган булса кирәк. Чынлыкта җомга намазы ике рәкәгать фарыз белән соңыннан ике яки дүрт рәкәгать сөннәттән гыйбарәттер”[1].

***15) “Әл-Miләл вә әл-нихәл” (“Милләтләр һәм дини тәгълиматлар”) китабы.***

Кулыбызда иң күп кулланууда булган әлеге әсәр хакында Ибне Тәймия әйтә: “Бер шигый түрәсе кулында булган вазыйфага ирешү өчен Шәһристани шигыйлар рәисләренә ялагайланып, мактап “Әл-Миләл вә әл-нихәл” дип аталган әсәрен язды. “Әл-Мусарага” исемле әсәрен дә әлеге максат белән язды. Яхшы уебыз белән Шәһристанины шигыйлардан саныйбыз, әгәр дә яхшы уйда булмасак, без аны исмәгыйлиләрдән санар идек. “Әл-Миләл вә әл-нихәл” башында фәрештәләр белән Иблис бәхәсләре хакында риваять иткән хикәяте нигезсездер. Исламда иң беренче каршылыкка мисал итеп Рәсүлуллаһ хасталыгын китерүе дә дөрес түгел. Нигә дисәң, аннан алда, моннан әһәмиятле каршылыклар да күп булды. “Икенче каршылык Усәмә гаскәренә ияру хакында булды” дигән сүзе дә ялгандыр. Нигә дисәң, бу турыда каршылык фәлән булмады, бәлки Рәсүлуллаһ хәзрәтләренең киңәше белән сабыр итеп торды. Шәһристани, башка кәләм әһле кебек, хәдис гыйлеме һәм сира, сәхәбәләр һәм тәбигыйннәр тормышы хакында мәгълүматы булмаганга, моның кебек ялгыш нәрсәләр язгандыр. Әбү Бәкер, Гомәр һәм Госман халифәлекләре хакында һичбер кылыч күтәрелмәде һәм бер тамчы булсын, кан акмады, бәлки мөселманнар арасында бу турыда низаг та булмады. Гәрчә ансарлар арасында кайберләре сүз сөйләргә керешсәләр дә, үзләренең өлкәннәренең нәсыйхәтләренә колак салып туктадылар һәм олыларына итагать иттеләр. Хәтта Әбү Бәкергә бәйгать бирүдә ансарлар эчендә Сәгед бин Гыйбәдәдән башка кеше каршы да булмады. Шуның өчен бу мәсьәлә хакында Шәһристанинең: “Өммәт арасындагы каршылыкларның иң олысы имамлык өчен каршылык. Чөнки бер вакытта да кылыч кынысыннан имамлык өчен чыкккан кебек, дини кагыйдәләр өчен чыкмады. Аллаһ Тәгалә каршылыкны беренче чорда, мөһаҗирләр белән ансарлар арасында низаг булганда

[1] “Тәхийәтүл-мәсҗид” дип аталган нәфел намазның җомга намазына түгел, хәтта җомга көненә дә бәйләнеше юктыр. Моны исә җомга намазына хас итү халык гадәтедер.

җиңеләйтте: ансарлар бездән дә әмир, сездән дә әмир булсын диделәр һәм Сәгед бин Гыйбәдә әл-Ансари рәислегенә килештеләр”, - дигән сүзе нигездә ялгыштыр. Сыйффин һәм Нәһрауән сугышлары да имамат өчен түгел иде. Могавия хәзрәти Галинең имамлыгын кире какмаганы кебек, үзе өчен дә бу вакытта имамлыкны таләп итмәде. Бу сугышлар башка нәрсәләр өчендер. Бу мәсьәләләр кәләм әһелләренә мәгълүм булмаса да, гыйлем әһелләренә мәгълүмдер. Шулай ук Шәһристаниның: “Мөэминнәр әмире Гали, Аллаһ аны хөрмәтле кылсын, пәйгамбәр галәйһиссәләмнең кушуы буенча аны кәфенләү һәм күмү белән мәшгуль булып, шуннан аерылмады”, - дигән сүзе дә дөрес түгел. Рәсүлуллаһ Гаишә өендә җирләнде, аның өчен чит булган хәзрәти Гали аның бүлмәсендә нинди юл белән һич аерылмастан булсын? Зәкәтне тыючыларга каршы булган сугышны сөйләгәннән соң: “Гомәр хәлифәлеге вакытында иҗтиһад кылды һәм аларга әсирләрен, малларын кире кайтарды, тоткыннарын азат итте”, - дигән сүзе дә һәрбер мөселман белерлек рәвештә ачык ялгандыр. Нигә дисәң, зәкәт сугышында һичбер җан иясе әсир алынмады һәм һичкем тоткын булмады, бу вакытларда Мәдинәдә төрмә дә юк иде. Исламда иң беренче төрмә хәзрәти Гомәр тарафыннан Мәккәдә нигезләнде, Сафуан бин Өмия өен сатып алып, шуны төрмә иттеләр. Шәһристаниның: “Шура хөкемендә тугызынчы ихтиләф, анда фикерләр каршылыгы булды, һәм барысы да Госманга бәйгать бирергә килештеләр”, - дигән сүзе дә ялгандыр. Чөнки, бу турыда ихтиләф-фәлән булмады, бер Габдеррахман бин Гауф кына кешеләрнең фикерләрен белү өчен өч көн буе араларында йөреп әлеге мәсьәлә хакында киңәште һәм кешеләрнең хәзрәти Госман яклы булуларын белде. Шуның өчен Әхмәд бин Хәнбәл: “Кешеләр Госман бәйгатенә килешкән кебек, икенче бер бәйгатькә килешмәделәр. Мөселманнар аны өч көн киңәшкәннән соң сайладылар һәм бер сүздә, бер-берләренә мәхәббәттә, барысы да Аллаһның бавына тотынган хәлдә булдылар”, - дигән.

Шәһристаниның бу китабында болардан башка ялгышлар, ялганнар күптер.

## 8 бүлек

### Аңа каршы булган кешеләр.

Бер кешенең дәрәҗәсен белер һәм хакыйкать хәле белән таныш булыр өчен иң дөрес юл - аңа каршы булучылар. Кешеләрнең дөньялыкта булган яхшы һәм яман гамәлләренең мизаннары дошманнарының шәһадәтләре һәм чыгарган хөкемнәре булыр. Кешеләргә мәгърифәт бирүче, агарту теләгендә булганнар дошманнарының белдерүләреннән файда күрсеннәр. Дуслар аша мәгълүмат алган кисра (шаһ) Пәйгамбәребез хәзрәтләрен ялганга чыгарган хәлдә, дошманнары тарафыннан мәгълүмат алган кайсар (император), чиста дошманлык ниятендә сөйләнгән сүзләр тәэсире белән аның пәйгамбәрлеген таныды.

Шуның өчен без бу бүлектә Ибне Тәймия дошманнарын, һәр заманда булган мәшһүрләрен һәм дошманлыкларына нәрсәләрнең сәбәп булганын язачакбыз.

1) Ибне әл-Мурәххәл (Садреддин Мөхәммәд бин Гомәр). 665 елда Дәмият шәһәрендә туып, 716 елда Мисырда вафат булды. Беркадәр вакытлар Димәшкъ шәһәрендә торды һәм монда “Ибне әл-Вәкил” исеме белән атаклы булды. Шәфигый мәзһәбендә ифрат дәрәҗәдә мөтәгассиб булганлыктан, мәзһәб тәгассубы турысында капма-каршысы булган гасырдашы Ибне Тәймия белән мәсләк дошманлыгы бар иде. Әлеге җиһәттән бу кеше ачык сурәттә Ибне Тәймиягә дошманлык кылырга кереште. 705 нче ел рәҗәб аенда булган мәҗлестә катнашып, беренче сафта көрәшергә керешсә дә, бик күп каршылыклы нәрсәләр кылганга һәм үз ягында булганнар белән бәхәскә керешеп тәртипне бозганга, саташып туктаган һәм бөтен тырышлыгы юкка чыкккандыр.

2) Зәмәлкәни (Мөхәммәд Камаледдин Әбү әл-Мәгали бин Гали әл-Зәмәлкәни). Шәфигыйларның башкалардан аерылып торган галимнәреннән булып, Ибне Тәймиядән бер ел элек 727 елда Каһирәдә вафат булды. Бу кеше башта Ибне Тәймиянең ихлас дусларыннан булып, һәрвакыт мактар иде. Ибне Тәймиянең ”Китәб бәян әл-дәлил галә бутлан әл-тәхлил” исемле әсәре чыккач мактап сөйләгән һәм ”Фәтехул-мәләм гәнил-әиммәт әл-әгъләм” исемле әсәре таралганда өстенә:

Ни сөйлиләр аны сыйфатлаучылар,
Ни әйтәләр аңа сыйфатлаучылар.
Аның сыйфаты өстен чикләүдән,
Ул Аллаһның көчле дәлиле.
Ул безнең арабызда заман могҗизасы,
Ул ачык билге холыкта,
Холкының нуры таңга яктылык өсти,  дип язгандыр.

Ибне Тәймия, Ибне Гарәби һәм аңа ияргәннәрне яратмавы сәбәпле, Зәмәлкәни Ибне Гарәбигә дус булганнан соң, Ибне Тәймиядән читләште һәм Ибне Тәймиягә талак, мәчетләргә сәфәр һәм зиярат мәсьәләләрендә кире кагып китаплар язды[1]. Бәхәс мәҗлесләрендә Ибне Тәймия белән бәхәсләшер. Әлеге бәхәс мәҗлесендә үз урынында ныклы булып та, үз сүзен хурлау сүзе итмичә тугры бер тәртип белән алып баручы кеше әлеге Зәмәлкәни булды, юкса башкалары каршы тора алмадылар диярләр. Шулай булса да, әлеге кеше, Ибне Тәймиягә каршы язган әсәрләрендә хурлаучы сыйфаты белән түгел, бәлки тәнкыйтьче сыйфатында гаделлек белән сөйләшә һәм әлеге яктан мактауга лаектыр.

3) Ибне Җибрил әл-Киләби әл-Хәләби (Әхмәд Шиһабеддин бин Яхья бин Исмәгыйль). 733 елда вафатыр. Бу зат Ибне Тәймияне кире кагу нияте белән “җәһәт” әһелләренә каршы бер китап язса да, бу гамәле белән үзенең хәбәрсезлеген һәм мәсьәләне нигездә аңламаганлыгын дөньяга күрсәткән. Нигә дисәң, Ибне Тәймия “җәһәт” белән түгел, бәлки “билә кәйфә фәукъ” белән әйтүчедер. Боларның соңгысыннан беренчесе аңлашылмас.

4) Ибне әл-Хәҗ (Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Мөхәммәд әл-Габдери әл-Фәси әл-Мәлики). 737 елда вафат. Бу кешенең ачык сурәттә Ибне Тәймиягә каршы килүеннән хәбәребез юк. Фәкать Ибне Тәймия вафатыннан соң язган “Әл-мәдхәл” исемле әсәрендә Ибне Тәймиягә капма-каршы буларак зиярат вакытында мәетләргә тәвәссүл итәргә (арадашчы итеп алырга) һәм гомумән ниятләрнең тормышка ашуы хакында кабер әһелләреннән ярдәм сорарга тиеш икәнен сөйләр, пәйгамбәрләр, сәхәбәләр, тәбигыйннар, галимнәр һәм әүлияләрнең каберләренә булган сәфәрләр хаҗ сәфәре кебек фазыйләтле вә саваплы булган дини бер сәфәр булачак дип әйтер иде. Дөресе, бу урында ни сөйләсә дә, барысын да Ибне Тәймиягә каршы сурәттә сөйләп, әмма ничектер бер урында: “Бәрәкәт алу Пәйгамбәрнең сөннәтенә иярү белән булыр. Җаһилият заманында сыннарга гыйбадәт кылу бәрәкәтләнү нияте белән булды”, - дип, кыек атып туры тидергән кебек, бер кереш җөмлә кыстырып киткән һәм моның белән (үзе белепме яки белмичәме) Ибне Тәймия фикеренә килешү белдергән.

5) Әбү Хәййән әл-Заһири (Әсируддин Мөхәммәд бин Йусуф бин Хәййән әл-Әндәлуси әл-Гарнатый). Әндәлус галимнәреннән булып, 735 елда Каһирәдә вафат булды. Нәхү гыйлемендә шөһрәте билгеле булды. Аның хакында Суютый: “Ул Ибне Мәлик әсәрләрен өйрәнүдә кешеләрнең иң кыюы, аларны укуга иң омтылучы, аларга аның серләрен ачучы, тирән чоңгылларына төшүче һәм Ибне әл-Хәҗибнең мокаддимәсе турында (Кәфия) бу фәкыйһләр нәхуе дип әйтә иде”, - ди. Безнең төрки телебезнең нәхү вә сарыфы хакында

[1] Бу җөмләдән бер китабы "الدرة المضيئة في الرد على ابن تيمية" исемендәдер.

“Әл-идрак фи лисән әл-әтрәк”  һәм “Зәһер әл-мулк фи нәхви әл-түрк”  исемендә әсәрләре бардыр.

Каһирә галимнәренең күпләренә остаз булуыннан, һәрберсеннән бер төрле көләр иде, остазлык хөрмәтен саклау өчен аның әлеге мөгамәләсенә сабыр итәрләр иде. Бу кеше башта Ибне Тәймиягә дус булып, хәтта шигырьләр белән мактый да иде. Соңрак нәхугә бәйле бер мәсьәләдә араларында бәхәс чыгып, Әбү Хәййән үз сүзен раслар өчен “Китап”тан дәлил китергәндә, Ибне Тәймия: “Сибәвәйһи хатадан азат түгел, нәху пәйгамбәре дә түгел иде, “Китап”та 80 урында ялгыш бар, сез моны аңлый алмассыз”, - дигән. Әбү Хәййән нәху гыйлеме белән шөһрәте чыккан бер зат булганга, әлеге сүздән гаять тәэсирләнгән һәм Ибне Тәймиягә хәтере калган. Вакыйганы белдерүдән хурланып: “Ибне Тәймиянең “әл-Гареш” китабын күргәннән соң, мәхәббәтемне алдым, бик бозык сүзе бар”, - дип сөйли башлый. Риваятьләргә күрә әлеге бозык сүз: “Аллаһ Тәгалә гарше өстендә утыра һәм Үзе янында Рәсүлуллаһ утырсын өчен буш урын калдырган”, - дип әйтүдән гыйбарәттер. Аллаһ Тәгалә гафу итсен, бу сүзне Әбү Хәййән бары тик үзеннән генә чыгаргандыр. Нигә дисәң, мондый сүз Ибне Тәймия мәсләге белән туры килмидер.

6) Тәкыйуддин әл-Сәбки (Гали Тәкыйуддин бин Габдулкәфи). 683 елда дөньяга килеп, Ибне Тәймиядән 28 ел соң 756 елда Мисырда вафат булгандыр. Күп санлы китаплары бар. Үзенең улы ”Әл-Табакат әл-кубра” исемле әсәрендә аның мактаулы эшләре хакында сиксән бит кадәр язгандыр. Ибне Тәймиянең ”Минһәҗ әл-суннә” исемле әсәрен гаепләп бер шигыйрь сөйләгәне кебек, зиярат хакында булган сүзенә каршы ”Шифа әл-сәкам фи зиярати хайри әл-әнәм галәйһис-саләтү вәс-сәләм” исемендә һәм талак хакында булган сүзен кире кагу буларак “Әл-Тәхкыйк фи мәсьәләти әл-тәглыйк” исемендә зур һәм ”Рафиг әл-шикак фи мәсьәләти әл-талак” исемендә кечкенә бер китап язгандыр. “Тәкыйуддин Сәбки казыйлык вазыйфасына керергә күңеле төшкәч, әлеге вазыйфа бу вакытта Ибне Тәймия дошманнары кулында иде, шуңа күрә аларга якынаю һәм ярау нияте белән Ибне Тәймиягә каршы килде һәм хезмәт күрсәтү нияте белән югарыда исемнәре телгә алынган әсәрләр язды. Шушы гамәлләре нәтиҗәсе буларак ахырда казыйлык вазыйфасына иреште”, - диярләр[1].

Ибне Тәймиянең шәкерте булган Ибне Кудәмә “Әл-сарим әл-мәнкийфи радди галә әл-Сәбкий” исемле китабын әлеге Сәбкинең “Шифа әл-сәкам” исемле әсәренә каршы язгандыр.

Әлеге ике китап һәм аларның авторлары, алардагы темалар хакында булган сүзләр белән китаплар тулганга, бу кыска язмабызда китерү мөмкин түгелдер. Ибне Кудәмә хакында Нәбһәни: “Үзенең остазы бидгатенә ярдәм бирде, Сәбки кебек бөек галимгә каршы язарга батырчылык итте”, - дигәне хәлдә, “Гаят әл-әмәнә” авторы: “Сәбкинең гыйлемдәге шөһрәте ялган шөһрәттер”, - диде.

7) Гizzеддин Ибне Җәмәгә (Габделгазиз Гиззеддин Әбү Гомәр бин Мөхәммәд бин Ибраһим). 694 елда Димәшкъ шәһәрендә дөньяга килеп, 767 елда Мәккә Мөкәррәмәдә вафат булды. Кайбер китаплары бардыр. Ибне Тәймиягә каршы фирканың күчәре ошбу зат булуы риваят ителәдер.

8) Таҗеддин әл-Сәбки (Габделваһһаб бин Гали). Югарыда телгә алынган Тәкыйуддин әл-Сәбки улы булып, 727 елда Каһирәдә дөньяга килде һәм 771 елда Димәшкътә вафат булды. “Әл-Табакат әл-кубра”  исемле әсәре шушы елларда Мисырда басылды. Аның Ибне Тәймиягә булган каршылыгы үзе чыгарган каршылык түгел, бәлки атасыннан мирас булып

[1] غاية الامانى  ج 2 ص 74

калган мал иде. Әгәр дә арадашчыларга игътибар булса, бу зат Ибне Тәймиягә арадашчылар аркылы шәкерттер.

9) Ибне Батута (Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Габдулла). Гарәп сәяхәтчеләреннән булып, 702 елда Танҗәдә дөньяга килде һәм 779 елда вафат булды. Бу кеше үзенең “Шәһәрләрдә һәм сәфәрләрдә гаҗәеп хәлләр күрүченең шатлыгы” дип аталган язмасында Ибне Тәймия хакында: “Димәшкъта булдым һәм җомга көнендә мәчеткә бардым. Ул (Ибне Тәймия) минбәр өстендә кешеләргә вәгазь сөйләде һәм әйтте: “Аллаһ дөнья күгенә минем шулай төшкәнем кебек төшә”, - диде һәм минбәрнең баскычыннан төште”, дигән эчтәлектә бер сүз язган. Ибне Батута саф күңелле садә бер кеше булганга, бу сүзне дошманлык белән түгел, бәлки онытылу әсәре буларак электән Ибне Тәймиянең дошманнары тарафыннан күңеленә урнашкан рәвешчә аңлагандыр. Ибне Батута тикшерүсез, төзәтүсез язучылардан булган өчен, моның кебек гыйльми мәсьәләләр хакында булган риваятләренә әһәмият бирү дөрес булмас. Монда булган сүзен Ибне Тәймия әсәрләре ялганга чыгарыр. Без исә бу җирдә Ибне Батутаны искә алсак, сүзе ышанычлы булганга түгел, бәлки Ибне Тәймия зарарына булган сүзләрнең яхшы һәм яманнарын бер җиргә җыю өчен. Аллаһ Тәгалә гафу итсен, бу карт кайвакыт тезгенсез китеп барадыр.

10) Ибне Рәҗәб (Зәйнеддин Әбү әл-Фәраҗ Габдеррахман бин Рәҗәб әл-Багдади әл-Димәшкый әл-Хәнбәли). 795 елда вафат булды. Бу кешенең Ибне Тәймиягә каршы язган фикерләре бар.

11) Галәуддин Мөхәммәд әл-Бохари (Аның тәрҗемәи хәле китапханәбездә булган әсәрләрдә табылмады). Хәбәрләргә караганда бу кеше тугызынчы гасыр уртасында Димәшкъ шәһәрендә торган һәм Ибне Тәймиянең үзен, аңа шәйхел-ислам диючеләрне көферлеккә чыгарып бер фәтвә чыгарган. Олуг мөхәддисләр тарафыннан мактап бәя бирелгән “Ибне Тәймиягә “шәйхел-ислам” дип әйтүчеләрне кяфер дип санаучыларга каршы киң җавап” исемле китап, чынлыкта, әлеге кешенең фәтвәсенә каршы җавап буларак язылгандыр.

12) Ибне Хәҗәр әл-Мәкки (Әхмәд Шиһабеддин бин Мөхәммәд бин Гали бин Хәҗәр). 909 елда Мисырда дөньяга килеп, 973 елда Мәккәдә вафат булды. Мисырдагы бер мәхәлләгә нисбәт белән Һәйтәми дип тә шөһрәте бар. Һәр форсат төшкәндә Ибне Тәймия белән аның шәкерте Ибне әл-Кайимга каршы килү һәм аны сүгү бу кешедә табигыйлык хөкеменә кергән һәм кайвакыт әдәп һәм тәрбиягә туры килмәгән гыйбарәләр кулланыр иде. Ибне Хәҗәр ишаннар кулында тәрбияләнеп үскәнгә, аларның мәхәббәтләрендә җитешкән бер заттыр. Шуның өчен ишаннарга каршы сөйләнгән сүзләр аның карашында җәрәхәткә салынган тоз кебек тәэсир итәр иде. Ибне Гарәбигә ифрат дәрәҗәдә дус булганын “Ибне Гарәби” исемле язмада бәян иттек. Хәтта аның кире кагыла торган сүзләрен һәртөрле аңлатмалар белән төзәтер иде. Моның кебек бер мәсләк сахибы, Китап һәм Сөннәт, дөрес гакыл һәм иҗмагтан башканы кабул итмәгән Ибне Тәймия мәсләге белән килешмәячәге табигыйдыр. Ибне Хәҗәр әл-Мәккинең Ибне Тәймия хакында кулланган гыйбарәләрен бу урында китерәбез: “Ибне Тәймия, Аллаһ ярдәменнән ташлаган, адаштырган, сукырайткан, чукракландырган, түбән төшергән кол, аның хәленең бозыклыгын, сүзләренең ялганын аңлаткан имамнар шуны әйтәләр. Кем моны белергә теләсә, имам мөҗтәһид, имамлыгында, олуглыгында, иҗтиһад мәртәбәсенә ирешүендә бердәм фикер булган Әбү әл-Хәсән әл-Сәбки, аның улы Таҗеддин әл-Сәбки, шәйх имам Гиззеддин бин Җәмәгә, гасырдашлары һәм башкалар арасыннан шәфигый, мәлики, хәнәфи мәзһәбе әһелләре сүзләрен укысын. Аның каршылыгы соңгы гасыр суфиларга каршы әйтүе белән генә чикләнми, Гомәр бин әл-Хәттаб һәм Гали Ибне Әби Талиб кебекләргә дә каршы сөйләгәндер[1]. Аның сүзенә һич әһәмият бирелмәс, киресенчә ялгызлыкта, хурлыкта, хәсрәттә калыр, аның уйлап чыгарылган, ялган

[1] Бу турыда киләчәктә сүз булыр.

һәм адаштыра торган, гаять надан булуында шик булмас. Аллаһ Тәгалә аны юк итсен һәм безне аның юлы, гакыйдәсе, гамәле кебек нәрсәдән сакласын”.

“Шәрхү әл-Шәмәил” исемле әсәрендә Ибне Тәймия белән шәкерте Ибне Кайим хакында: “Җиһәт һәм җисем турында исбатларга тотындылар, шуның өчен озак вакыт уйландылар һәм, колаклар тонарлык, ялганга чыгарылачак кабәхәтлекләрдән, бозык игътикадтан тыйган өчен, сөннәт әһленә каршы чыктылар, Аллаһ Тәгалә аларны һәм аларның сүзен сөйләүчене җирәнгеч кылсын”, - дип бер гыйбарә әйтүе һәм “әл-Җәүһәр әл-мунәззам” исемле әсәрендә: “Аллаһ Тәгалә Ибне Тәймияне адаштырды, туры юлдан яздырды һәм оятка калдырды, аны һәлак итте, нәтиҗәдә хурлыкка калдыра, аннан читләштерә торган яла ягу һәм ялганга кертте... Ибне Тәймия белән ни генә булса да, һичкайчан колак ишетмәгән хатамы, начарлыгы һәрвакыт дәвам иткән бәхетсезлекме, гаҗәп түгел, чөнки мөҗтәһидләр белән булып уңышка ирешүдән аны нәфес һавасы һәм шайтаны котыртты, ул мескен күп мәсьәләләрдә аларга каршы булып, алар фикеренә каршы килгән билгеле ахмаклыклар белән имамнарын, бигрәк тә тугры хәлифәләрне төзәтеп, үзенең иң бозык әшәкелек эшләвен белмәде. Халыкка минбәрләрдән торып “җиһәт” (тараф, як), “тәҗсим” (гәүдәләнеш) турысында әйтеп һәм моңа ышанмаганнарның элеккеләрен дә, хәзергеләрен дә адаштырырга теләп, әлеге колак ишетергә теләмәгән, акыл кабул итмәгән хорафатлары белән һәртөрле кимчелекләрдән азат, камиллек иясе булган Аллаһка карата чиктән чыгып зур гонаһка кертә торган нәрсәләр әйтте, Аның олуглык һәм бөеклек пәрдәсен ертты. Чордаш галимнәр аңа каршы чыгып, солтаннан аңа үлем җәзасы бирүен яки кулга алуын һәм чара күрүен таләп иттеләр. Солтан аны төрмәгә яптырды, үлгәнче шунда булды һәм әлеге бидгатьләр бетте, караңгылык юкка чыкты. Соңыннан моңа ияргәннәр булды, Аллаһ аларны өскә чыгармады, әһәмият һәм куәт бирмәде, киресенчә, карышулары һәм явызлыклары сәбәпле аларны түбән төшерде һәм Аллаһның ачуына дучар булдылар”, - дип сөйләгәне риваять ителә[1].

(Ибне Хәҗәр әлеге рәвештә сүксә дә, үзе дә кеше сүзеннән имин калмаган.
*“Кем, калган имин кешеләр теленнән,*
*Үзе сөйләп алар турында белер-белмәс?!”*

Бу урында сөйләгән сүзләренә каршы мөгътәбәр галимнәрдән берсе шушы җөмләләрне язган: 1) ”Ибне Хәҗәргә ышанып булмый, ул шәйхел-исламга яла яккан”. 2) “Ибне Хәҗәр иман китергәннәргә иң дошман булган кешеләрнең берсе дип әйтүгә лаек, чөнки аның китаплары Аллаһның тәкъва колларын, хәдис әһелләрен, пакь сөннәт хезмәтчеләрен, данлыклы шәригатьне сүгү белән тулы. Заманыбызның һәм әүвәлгеләрдән булган кайбер гыйлем әһелләре аның хаталарын, ялганнарын, яла ягуларын, гыйлемне тапшыруда булган хыянәтен, сүзләрне бутап урыннарын алмаштыруын, Аллаһка һәм Кыямәт көненә иман китергән кеше эшләмәс башка гамәлләрен ачыклап, аның сүзләрен кире кагу кирәклеген әйтәләр”. 3) “Ибне Хәҗәрнең сүзләре шәйхел-исламга зарар итмәс, чөнки ул аның килешә алмаслык дошманнарыннан”. 4) “Шәйхел-ислам Тәкыйуддиннең (Ибне Тәймия) китаплары таралганчы, Ибне Хәҗәр дөресен әйтә дип уйлаучылар булгандыр. Китаплары таралганнан соң, акылы булган һәркем өчен Ибне Хәҗәрнең ялган сөйләве һәм яла ягуы ачыкланды, моннан соң аңа беркем дә ышанмады, Аллаһ күңел күзен томалап сукырайтмаган һәркем каршында дәрәҗәсе төште”. 5) “Ибне Хәҗәр сөйләгән сүзләрендә ялганчы, яла ягучы, карышучылардан, диннәрендә мәҗбүр ителүчеләрдән”.)

13) Хафәҗи (Әхмәд Шиһабеддин бин Мөхәммәд бин Гомәр әл-Хәнәфи әл-Мисрый). 1069 елда рамазан аенда вафат. Бу кешене Мөхәммәд әл-Мәхби: “Үз гасырындагы язучыларның рәисе булып, һәрбер өстенлек хосусында үзеннән алда булган галимнәрдән югары чыккан һәм үзеннән соңгыларны үзенә җиткермәгән бер зат иде”, - дип мактаган. Бу зат “Шифа”да булган *“Әй, Аллаһ, каберемне миннән соң гыйбадәт кылына торган нәрсә*

---

[1] جلاء العينين ص 257 .      غاية الامانة , ج 2 ص 76- 87

*итмә. Пәйгамбәрләренең каберләрен табыну урыны итеп алган кавемгә Аллаһ Тәгаләнең ачуы катыдыр!"* хәдисе шәрхендә: "Бел, бу Ибне Тәймия һәм Ибне Кайим кебек аның бозык сүзенә иярүчеләр, аңа таянып көферлеккә чыгара торган хәдистер, (әс-Сәбки бу турыда мөстәкыйль китап язды), аның сүзе Пәйгамбәрнең каберен зиярат итүдән һәм аңа барудан тыя. Ул хорафатлар белән тәүхидне саклыйм дип уйлый, әлеге хорафатларны телгә дә алырлык түгел, чөнки акыллы кешедән андый нәрсә чыкмас, хөрмәтле галимнән, Олуг һәм Бөек Аллаһ гафу итсен, бигрәк тә", - дигән. Үзенең тиңдәше булмаган әлеге зат, бу турыда зиярат итү белән сәфәр чыгу мәсьәләсен бер-бере белән катыштырып укучыларның хаталануларына сәбәп булгандыр. Ибне Тәймия бәхәсе зиярат хакында түгел. "Шифа" кебек мөбәрак бер китап шәрхендә, мөмкин кадәр шәхси үпкәләрне бер тарафка куеп, дөреслеккә хезмәт итәргә тиешле иде. Расүлуллаһ хакында хезмәт итүчеләр өчен әдәп шуны таләп итә, ләкин Аллаһ Үзе генә гонаһсыз. Хафәҗинең атасы Ибне Хәҗәр әл-Мәкки шәкерте булганга атасына булган ихласы, Хафәҗины мондый ялгышка китергән булса кирәк. Әлеге хәдис шәрхендә Гали әл-Кари: "Зиярат кылу үзе диндәге гыйбадәт гамәлләреннән, аны кире кагучының хөкеме кяфер, дип әйтүчеләр арттырган кебек, Ибне Тәймия зиярат өчен сәфәрне тыюы белән хәнбәлиләрне уздырды", - дип, һәр ике як риза булмаячак сурәттә фикер бәян иткән.

14) Габдулхәй әл-Кәнви – (Әбү әл-Хәсәнәт Габдулхәй бин Габдулхәлим әл-Һинди). 1304 елда рабигуль-ахирда яшьлегендә вафат булды. Үз гасырының күркәм холыклы, хыялы тәгассуб хасталыгыннан сәламәт, иҗтиһадлы, хәнәфи мәзһәбендә булган хәлдә мөмкин кадәр Коръән һәм Сөннәт буенча гамәл кылуга омтылучы бер зат булуы әсәрләреннән аңлашылыр. Бу кеше, дөреслектә, Ибне Тәймиягә Ибне Хәҗәрләр рәвешендә дошманлык итүчеләрдән булмаса да, зиярат өчен булган сәфәр хакында Сәбки фикерен хуплар, һәм исеме онытылган бер әсәрендә дә, җиңел уйлавы һәм үлчәп фикер йөрмәве белән гаепләгәндер. Шулай булса да, мондый мөгамәләләре, "Галине сөйгән өчен түгел, ә Могавияне яратмаган өчен" дигән кебек, Ибне Тәймияне сөймәвеннән бигрәк, араларында һәрвакыт көндәшлек һәм тарткалаш булып торган Садыйк Хәсәнханга каршы булачагы хәтеремә килә. "Әл-Нәфигъ әл-кәбир" исемле әсәренең кырында: "Безнең гасырда Ибне Тәймия хакында кешеләр ике төркемгә бүленделәр: берсе аның барлык сүзләрен дә күктән иңгән вәхи кебек дип уйлый һәм аны гамәлгә алуда, җөмһүр галимнәргә яки Ибне Тәймиядән өстенрәк булганнарның ачык аңлатуларына каршы булса да, чиктән аша, икенче төркем, җөмһүр галимнәр сүзенә каршы килгән кайбер сүзләре өчен, аны сөннәт әһленнән санамый. Мин берсенә дә катышмыйм, һәм әл-Зәһәби кебек мин дә әйтәм: ул тиңдәшсез гыйлем дәрьясы, шәйхел-ислам, шуның белән бергә ул кеше, аның гонаһлары һәм хаталары бар, кем дә булса аны сүгүдән саклансын, әйткән сүзләрен яхшылап уйласын", - дип әйтә.

15) Дәхлән (Әхмәд бин Зәйни). 1304 елда рәҗәб аенда вафат булды. Мәккәдә шәфигыйларның мөфтиләреннән һәм мәшһүр галимнәреннән иде. Рәхмәтулла әл-Һинди җәнабләренең "Изһар әл-хак" исемле әсәренең кереш өлешендә исеме телгә алынган һәм 1301 елда Фадыл Мәрҗәнигә язган бер хаты "Вафият әл-әсләф"тә китерелә. Китапханәбездә булган әсәрләрендә Ибне Тәймияне сүккән сүзләре күрелмәде. Аны Ибне Тәймиягә каршы булганнар арасында язуыбыз башкаларның хәбәрләренә ышану сәбәбеннәндер. Шулай да Дәхлән белән Ибне Тәймия мәсләкләре арасында каршылык камил икәнендә шөбһә юк. Чөнки Дәхлән каберләрдә булган вәлиләрнең рухларыннан зиярат итүче кешеләргә бәрәкәт һәм муллык хасил булачагын дәгъва кылыр, шәехләрнең каберләрендә яткан хәлдә мөрид тәрбияләүләрен дөрес санар, Фәхреддин әл-Разиның "Әл-Мәталиб әл-галия" исемле әсәрендә: "Кабердә булган камил әдәмнәрдән гыйлем һәм мәгърифәт алу мөмкин", дигән сүзләреннән чыгып шул фикергә килер[1].

[1] Дәхләннең әлеге мәсләгенә каршы мөхәддис Габдулла әл-Синди тарафыннан "Кешенең Дәхлән вәсвәсәсеннән саклануы" исемендә бер әсәр язылганын Мисыр матбугатыннан укыдык.

(Әл-Разидан китерелгән сүз - бозык сүз. Аңа Коръәндә дә, Сөннәттә дә, элекке тәкъва мөселманнардан да дәлил юк. Ул сүз юнан фәлсәфәчеләреннән алынган. Кызганычка каршы, Рази кебекләр, аннан тапшырылган сүзләр мисалында сөйлиләр)[1].

16) Садреддин әл-Мөфти (Садреддин Хан Баһадир). Бу кеше инглиз хөкүмәте тарафыннан Дәһли шәһәрендә министр вазыйфасына куелган иде. Ибне Тәймиягә каршы буларак өч мәчеттән тыш башкаларга да сәфәр кылу фазыйләтле эш икәнен исбатлау өчен бер язма эшләгән. Әлеге язма хакында “Әл-йәнигъ әл-җинни” авторы: “Язмасында анык булган, Аллаһ аны сәламәт кылсын”, - дигәне хәлдә, Сиддыйк Хәсән Хан: “Әлеге язмасында бик нык ялгышкан, зур ялгышы аның мәсьәләгә кагылышлы дәлилләрне бик аз белүен, вакыйгалардан бик аз хәбәрдар булуын күрсәтә. Һинд галимнәренең кайберләре аны кире кактылар. Болардан “Әл-Сарим әл-мәнкий фир-радди галә ибни әл-Сәбки” китабы да җитәрлек булыр”, - дигән. Бу кеше үзе әлеге Сиддыйк Хан остазларыннан булып, шәех Габделгазиз бин Әхмәд Мөснәделвакыт әд-Дәһләви әл-Гамри замандашы иде. Мөгаен күптән вафат булса кирәк.

17) Әбү әл-Һүдә (Мөхәммәд Әбү әл-Һүдә Ибне Хәсән әл-Саййади). Солтан Габделхәмид гасырында җитәкче буларак кешеләрнең бәхет һәм кайгылары хакында йогынты ясап торган шәехләрдән иде. Мөгътәбәр гарәп газеталарының берсе аның хакында: “Аның бүген ерак көнчыгыштан алып көнбатышка кадәр биш йөз меңнән ким булмаган тарафдарлары бар. Алар арасында атаклы кешеләр, казыйлар, мөфтиләр, язучылар, җитәкчеләр, вәзирләр, олуг кешеләр һәм башкалар бар”, дигәннән соң, аны мактап язылган шигырь, мәкалә һәм китаплардан иллеләп исем санаган иде.

Олуг адәмнәр тирәсендә булган кешеләрнең бөтен өметләре аларга якын булу хакында иҗтиһад кылмак һәм бу турыда үзләре кебекләргә көнләшү гыйбарәт булыр һәм моның өчен дөнья да фида кылыныр һәм ахирәт тә! Нәкъ шулай солтан Габделхәмид хозурында ике бөек шәйх бер-бере белән көндәшлек кылырга керештеләр. Аларның берсе кадәриләрнең башлыгы булып, икенчесе рифагыйлар башында торучы Әбү әл-Һүдә иде. Әлеге ике зат хизбуллаһ һәм әһле ахирәт хакында булган дошманлык, ике тараф кешеләренең һәрберсенә кагылды һәм иң соңыннан бу тарткалаштан бөтен әһле исламга бөек бер өлеш чыкты.

Үзләрен бөек күрсәтү өчен, алар үз төркемнәренә караган шәйхләрне бөек күрсәтү юлына керделәр һәм аларны мактауда ике як бер-берсеннән уздырып хисапсыз мәкаләләр һәм китаплар язып бастырдылар, гарәби һәм төрки, мисри һәм туниси, һинди һәм ирани гәҗитләрнең битләрен тутырдылар. Кешеләрнең бөеклекләрен гади халык кәрамәт һәм могҗизалар белән үлчәгәнгә, әлеге әсәрләр гайре табигый, могҗизалы булган хикәятләр белән тулды, бу турыда хәтта алар “дини могҗиза һәм кәрамәтләр” дип мәшһүр булган христианлыктан да бераз уздырдылар. Әлеге китаплардан һәркем туйса һәм бизсә дә, бу әсәребезне укучылар үзләренең инсафлары һәм сәламәт акыллары белән хөкем йөртсеннәр һәм ислам дөньясы өстенә таулар кебек бәлаләр чыгып торганда, юлбашчылык фикерендә булган затлары нинди файдасыз нәрсәләр белән мәшгуль булганнарын белсеннәр, Аллаһ Тәгаләне риза итмәячәк һәм кешеләргә файда китермәячәк нәрсәләргә бирелеп һәлакәт чокырларына өстерәүләрен аңласыннар өчен, бу урында бер-ике мисал язуны тиеш таптык. **“Аллаһ бер кавемнең хәлен, шул кавем үзе үзгәрә башлаганчы үзгәртмәс”[2].** Көферлек турында әйтү көферлек булмаган кебек, бу мисалларны язуыбыз хакында җаваплы булмасак кирәк: 1) Аллаһ Тәгалә тарафыннан Габделкадир әл-Кәйләнигә хат җибәрелде, конверт тышына адрес: “Бу хат сөючедән сөеклегә юллана” дип язылган. 2) Габделкадир әл-Кәйләни мөридләреннән берсенең җанын алып Газраил галәйһиссәләм

[1] 1271ص   1 ج  غاية الامانى

[2] “Рагед” сүрәсе, 11 аять

күккә менеп киткән. Моны белгәч, Габделкадир ачуланып куа китте һәм дүртенче кат күктә Газраил галәйһиссәләм артыннан басып җитте дә, кәрзинкәсен тартып алып, астын-өскә китерде, мөриденең җанын түбән төшереп җибәрде. Җан кире тәнгә кайтып, мөрид тә урыныннан торды. Бу вакыт кәрзинкәдә никадәр җан булса, һәрберсе түгелделәр һәм очып кайтып үз тәннәренә кире керделәр. 3) Габделкадир әл-Кәйләни мөридләреннән берсе ввафат булгач, каберенә сорау алу фәрештәләре килеп: “Раббың кем?” – диделәр. Мөрид: “Габделкадир!” – дип җавап бирде. Фәрештәләр: “Пәйгамбәрең кем, динең нинди дин?” – дип сорадылар. Мөрид: “Габделкадир!” – диде. Фәрештәләр әлеге вакытта моңа сугар өчен чукмарларын күтәргәннәр иде, шулук вакыт Габделкадир килеп керде дә, фәрештәләрнең икесен ике якка сугып екты һәм ләхеттән куып чыгарып җибәрде. Фәрештәләр Габделкадир өстеннән Хак Тәгаләгә шикаять итәргә киттеләр. Аллаһ Тәгалә: “Габделкадир олуг кеше, аның белән дәгъвалашмагыз, бу эшне ташлагыз!” – диде. 4) Мигъраҗ кичәсендә Расүлуллаһ хәзрәтләрен йөртүче зат Габделкадир иде. 5) Габдеррәхим әл-Рифагый әгәр дә үзе теләсә үтерә һәм тергезә, бай һәм фәкыйрь кыла, бәхетле һәм бәхетсез итә иде. 6) Әхмәд әл-Рифагый шул дәрәҗәгә җитте: күкләр аягы астында булыр иде. 7) Әхмәд әл-Рифагый Мәдинәдә кабер-шәриф янына баргач, Расүлуллаһ аңа кабереннән кулын чыгарып сузды, Рифагый да аны тотып үпте. 8) Әхмәд Рифагый: “Аллаһ Тәгаләдә хаҗәте булган кешеләр минем каберем ягына карасыннар да, җиде адым алга барсыннар, моннан соң миннән ярдәм сорасыннар, теләгәннәре хасил булыр”, - диде.

Ибне Тәймия Коръән һәм Сөннәт юлында булмаган суфиларны кабул итмичә, аларның дәлилләренә ышанмаганга, алар турында таралган мондый гаҗәеп хәбәрләр хакында: “Моның кебек хикәятләрне гыйлеме һәм дине аз булган кеше генә чыгара”, - дигән сүзләр сөйләгәнгә һәм хосусан, рифагыйлар хакында “Әхмәди шәйхләренең хәлен ачыклау һәм шайтаный хәлләрен аңлату” исемле китап язып, күп хурлыклы эшләрен мәйданга куйганга, могҗиза сөйгән шәйхләр һәм мөридләр аңа дошманнардыр. Әбү әл-Һүдә аларның берсе булганга, табигый, Ибне Тәймиягә каршы фиркалардан иде. (Рифагыйлар белән кадәриләр файдасыз низаглары белән Ислам дөньясын кайнатып торуларыннан бизгәнгә Багдадта олуг галимнәрдән берсе үзенең бер әсәрендә: “Бу гасырның суфилары Китап һәм Сөннәт белән гамәл кылучы түгелләр. Рифагыйларның Истанбулда булган шәйхләре хәйлә һәм мәкерлелектә иблисләрне дә артта калдырды һәм кадәриләр хәмер һәм башка тыелган нәрсәләр белән бәлаләнгәнгә Ислам диненә йөз каралыгы булды. Моның кебек шәйхләр Ислам милләтенә бу көннәрдә олы бәла булдылар, боларның кылмаган кабәхәтлекләре калмады”, - дияр.)

Монда телгә алынган кәрамәт һәм могҗиза хикәятләре никадәр аңлатылса да, никадәр тышкы яктан чиста ителсәләр дә, насараларның “өчлек” (троица) хакында булган аңлатмаларыннан гүзәл булмаячагын һәркем аңласа кирәк. Уңыш килгән вакытта булган биш йөз мең иярченнең кемнәр икәнлеген Әбү әл-Һүдә әфәнде хөррият соңыннан килгән уңышсызлык вакытында белсә кирәк. Моның кебек мәшәкать һәм бәлаләр, әгәр дә шәйхләр һәм ишаннарга каршы булган һәм аларның гамәлләрен тәнкыйть итүчеләр башларына килсә, һич шөбһә юк, “ишаннарның фатихалары орды, тиешле җәзасын алды” дип, катгый бер хөкем кылырлар иде. “Һәрбер эшне гамәлгә куючы Аллаһ Тәгалә, хикмәт һәм сәбәпләре Аның Үзенә генә мәгълүм булыр” диючеләр һичкемнең башына килгән эш хакында хөкем кылмасалар да, һәм хөкем кылырга үзләренең хаклары юк икәнен белсәләр дә, башкалар, әлбәттә, мондый рәвештә бу тараф калмаслар. Алар күп вакыт үзләре яратмаган кешеләр башына килгән бәла-казалар хакында: “Бу эш фатихасызлык сәбәбеннән булды”, дип, һәм үзләре сөйгән кешеләр башына килгән бәла-казалар хакында “Бәла күрү пәйгамбәрләр гадәте, югары дәрәҗә өчен булыр” дип хөкем кылырлар. Ибне Тәймиянең төрмәгә утыртылуын Аллаһтан җәза алу дип хөкем кылган ишаннар, Әбү әл-Һүдә әфәнденең төрмәгә ябылуын югары дәрәҗә өчен дип хөкем итәчәкләре мәгълүмдер. Әбү әл-Һүдә әфәнденең тууы 1266 елда рамазан аенда Мәгәрра әл-Ногман шәһәрендә иде.

18) Нәбһәни (Йосыф бин Исмәгыйл бин Йосыф). Бу гасырыбызда Ибне Тәймия һәм Ибне әл-Кайимга дошманлык итүче фирканың (алар күбрәк ишаннар һәм мөридләр) башында торучы зат әлеге кешедер. Ибне Тәймия һәм Ибне әл-Кайим хакында сөйләнгән ни кадәр яман сүзләр булса бу адәм шуларны бер җиргә җыеп китап рәвешендә туплар, берсе өстенә икенчесен нәшер итәр. Искә алынган затларның әсәрләрен укудан саклану хакында динле мөселманнарга һәм хосусан ислам шәкертләренә нәсыйхәтләр бирер. Ерак җирләрдә булса да, вәлиләр каберләренә сәфәр кылып зиярат итү саваплы эш булуын, вафат булган шәйхләрнең рухларыннан ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә тиешлекне сөйләр. Расүлуллаһ хәзрәтләренең һәр урында һәм һәр заманда бар булуын хикәят кылыр һәм: “Инде Коръән һәм хәдисләргә таянып хөкем йөртү вакытлары үтте, иҗтиһадны исә бидгатьчеләр һәм ваһһабилар[1] дәгъва кылыр, шуның өчен иҗтиһад дәгъвасын кылучы кеше шәригатькә ялган кертүче кеше булыр”, - дияр. Нәбһәни мәкаләләре күбрәк бушка таралтылганга, Ибне Тәймия һәм Ибне әл-Кайим исемнәренең Русия мөселманнарының урта катламнары арасында мәгълүм булуларына зур хезмәт булды. Бер шагыйрьнең:

Хөсетлек кылучыларга булсын Аллаһның рәхмәте,
Эшләре өчен алар лаек рәхмәт ишетергә бездән.
Безне хурлап, тараттылар безгә хөрмәт,
Ниятләре хурлык иде, безнең өчен булды дан,

дигән бәетләре күрсәткәнчә хурлау һәм дошманлык, олылау һәм мактау нияте белән язылган әсәрләрнең күпләре, нинди сер һәм сәбәпләргә күрәдер, кире нәтиҗәләр бирүе мәгълүм. Бу көндә Русиядә ваһһабиларны хурлап язучылар да бар. Болардан нинди нәтиҗәләр чыгачагын дөрес фикер ияләре шуннан бераз аңласалар кирәк.

Шәйх Әбү әл-Һүдә, солтан Габделхәмид каршында киңәшче булып торуында икмәкләренә май ягуны һәм ничек булса да дөньяларын тәэмин итүне теләүчеләрнең һәрберсе Әбү әл-Һүдә әфәндегә якынаерга һәм табигый аның дошманнарының гайбәтләрен сатуны кулланырга мәҗбүр иделәр. Әбү әл-Һүдә әфәнде, Ибне Тәймиягә дус булмавын югарыда сөйләдек. Чынлыкта, шәйх Әбү әл-Һүдәгә якынаю нияте белән Нәбһәни дә рифагыйларны һәм гомумән, тарикать шәехләрен мактап, Ибне Тәймия һәм аны ихтирам итүчеләрне хурларга мәҗбүр булгандыр. Нәбһәнинең бу гамәле Әбү Тәмәмәнең:

Әгәр Аллаһ теләсә таратырга бер яхшы эшне,
Билгели аның өчен көнче телне.
Ботакның хуш исе беленмәс иде,
Әгәр яндырмаса ут тирә-юньне,

дигән шигырьләренең хөкеменә туры килсә дә, асыл максатына ирешкән, олуг бер дөньяви вазыйфада озак вакытлар калган һәм әлеге Әбү әл-Һүдә һәм Гыйззәт пашалар белән бергә урыныннан чыгарылгандыр.

19) Ибне Җирҗис (Дауд бин Җирҗис бин Сөләйман әл-Гыйракый). Аның хакында: “Бу зат шәфигый мәзһәбе өчен тәгассуб кылучыларның чиктән ашучыларыннан булып, сыену, ярдәм сорау һәм Аллаһ Тәгаләдән башка затлардан сорауның дөреслеге хакында колакларга ишетелергә тиеш булмаган сүзләр сөйләде. Надан бер адәм булганы кебек, дөреслекне бозарга һәм яшерергә дә батырчылыгы җитә иде. Җисемнәр һәм җан ияләре белән тәвәссүл итүне дөрес күреп, әлеге мәзһәбен сәләф салихлар, сәхәбәләр һәм тәбигыйннарга нисбәт итте һәм әлеге саташуларын үзенә бер мәсләк итте, бу турыда үзенә

[1] Үзләренең ачулары килгән адәмнәр өстеннән “падишаһны сүкте” дип донос итүчеләрдән, үзләрен галимнәрдән санаган адәмнәр үз фикерләрендә булмаган кешеләрнең һәрберсен “ваһһабилык” белән гаепләрләр һәм моның белән халык каршында түбән төшерергә мөмкин булачагын өмет итәрләр.

каршы сөйләүчеләрне ваһһабилык белән гаепләр иде. Инде бу көндә һәлак булды”, - диярләр[1].

Ибне Тәймия һәм Ибне әл-Кайимгә каршы булучылар болар гына булмаса кирәк. Фәкать үзебезнең китапханәбездә булган әсәрләрне тикшереп әлеге кешеләрне генә таптык. Шулай булса да, бу адәмнәрнең күпләре әлеге гамәлләрендә:

“Яшь егет яманлар белмәгән нәрсәсен,
Һәр көндәш мәшгуль сүгү белән үзенең көндәшен.
Кызның чибәрлеген яман эше бозган кебек,
Дөреслекне бозар ахмаклык”,

шигырьләренә дәлил булсалар гаҗәп түгел.

## 9 бүлек

### Тәнкыйтьләр.

Ибне Тәймия дошманнары тарафыннан язылган китапларны, яки башка китапларда темадан тыш сөйләнгән бәхәсләрне үзебезнең китапханәбездә булган әсәрләрдән тикшергәннән соң күбесе Ибне Хәҗәр әл-Мәккинең “әл-Фәтәуә әл-хәдисия” исемле әсәрендә язылган бәхәсләр астына керүен күрдек. Шуңа күрә без бу урында “әл-Фәтәуә әл-хәдисия”дән күчереп язачакбыз.

Ибне Хәҗәр әл-Мәкки, Ибне Тәймия хакында: “Ибне Тәймия Аллаһ ярдәменнән ташлаган, адаштырган, сукырайткан, чукракландырган һәм хурлыкка калдырган бер бәндә”, - дип, әдибанә җөмләләр китергәннән соң, мондый сурәттә бәхәскә керешер: “Ибне Тәймия әһле Ислам иҗмагына каршылыклы буларак әйтә:

1) Талак белән ант иткән кеше антын бозса, кәффәрат кенә тиеш булып, хатыны талак булмас;
2) Хәез вакытында талак булмас;
3) Бер сүз белән өч талак булганы сурәттә “өч” сүзе ләгави булып, бер генә талак булыр;
4) Хайван төшеп үлүе сәбәпле сыеклыклар нәҗесләнмәс.
5) Хәезле хатын шул көенчә тәваф кылыр булса, кәффәрат ваҗиб түгел.
6) Шәһәрдә була торып җөнеб кеше өчен кичәдә тәяммум белән нәфел намазы уку дөрес.
7) Ниятләп калдырылган намазлар каза кылынмас.
8) Налог хәләлдер.
9) Гәрчә зәкәт исеме белән бирелмәсә дә, сәүдәгәрләрнең налог түләүгә тотылган акчалары зәкәттән хисапланыр.
10) Вакыф тарафыннан кылынган шартлар буш сүздер.
11) Иҗмагка каршы булучы кәфер дә, фасикъ та түгел.
12) Аллаһ Тәгалә ниндидер бер урында булырга мөмкин булган кебек, гәүдә төзелеше һәм бер якта булуы да мөмкиндер.
13) Коръән Аллаһ Тәгалә затында яңадыр.
14) Галәм кадимдер.
15) Пәйгамбәрләр гонаһсыз түгелләр.
16) Расүлуллаһ каберенә зиярат нияте белән сәфәр кылу гонаһлы сәфәр җөмләсеннән.
17) Инҗил һәм Тәүратның сүзләре алышынмаган, бәлки мәгънәләре генә үзгәртелгәндер.

---

1 غاية الامانى ج 2 ص 108 - 109

18) Тәмугъ бер вакыт бетәчәктер”.

Ибне Хәҗәр әлеге мәсьәләләрне Ибне Тәймиядән дип китергәннән соң, хәзрәти Гомәр һәм хәзрәти Гали хакында: “Гомәрнең нинди генә хата-кимчелекләре юк. Гали өч йөз урында ялгышкан” дияр, һәм Газали, Ибне Гарәби, Ибне Сәбгыйн, Гомәр бин әл-Фарид һәм Шәзили кебекләр хакында катгый сурәттә тәнкыйть итте, дип хикәят кылыр.

Ибне Хәҗәрнең Ибне Тәймия хакында якынча 67 юлдан гыйбарәт тәнкыйте хакында Багдад мөфтие Алуси Сәед Ногман Хәйреддин “Җәлә-ул-гәйнәйн фи мухәкәмәтил-әхмәдийин” исемле олуг бер китап язып, үзе исән вакытта 1298 елда Мисырда бастырды. 360 биттән гыйбарәт булган бу әсәр мөһим һәм файдалы мәгълүмат белән тулыдыр.

Алуси: “Ибне Хәҗәр әлеге Ибне Тәймиягә бәйләп әйткән сүзләрен болай кыска рәвештә язган җирдә беркадәр ачык тәртип кылырга һәм бу сүзләрне Ибне Тәймиянең кайсы әсәрләреннән алганын бәян кылырга тиеш иде. Фәлән кеше фәлән рәвештә сүз сөйләгән дип, дошманлык кылырга керешү, әдәпкә каршы киләдер, бәлки иң элек аның әйткәнен исбат итәргә һәм китапларын күрсәтергә кирәктер”, - дигәннән соң, йомшаклык белән Ибне Тәймия тарафыннан әлеге җавапларны биргән:
1) Талак белән ант итү сурәте гомумәнчә түгел, бәлки зыйһар нияте булган мәддәгә махсустыр. Ибне Тәймия әсәрләрендә бу мәсьәлә ачык аңлату белән бәян ителгән, әлеге сүздә Ибне Тәймия үзе генә түгел, бәлки бу сүз Әхмәд бин Хәнбәл мәзһәбенең сүзе булган кебек, аны әйтүчеләр элгәреге мөселманнарда күптер, сәхәбәләрдән тапшырылган фәтвәләр дә моңа каршы түгел. 2) Хәез вакытында талак булмаганы Сәгид Ибне әл-Мөсәиб һәм тәбигыйннардан бер җәмәгатьтән дә хәбәр ителәдер. 3) Бер сүз белән өч талак булмавы элгәреге мөселманнардан бөек бер җәмәгать мәзһәбе булганы кебек, Мәлик һәм Әхмәд, Шәфигый һәм Әбү Хәнифә мәзһәбендә булган галимнәрдән дә күпләр шулай әйткәннәрдер. 4) Нәҗес төшү сәбәбеннән майдан башка сыек нәрсәләрнең нәҗесләнмәвен ялгыз Ибне Тәймия генә түгел, бәлки Ибне Хәзем һәм аннан башка галимнәр дә әйткәннәр. 5) Таваф мәсьәләсендә Ибне Тәймия сүзе Әбү Хәнифәдән тапшылырган риваятькә туры киләдер. 6) Җөнеб мәсьәләсе хакында Ибне Тәймиядән шундый бер сүз булса, иҗтиһади мәсьәлә булганга, тыгызланырга һәм аның өчен дошманлык кылырга урын юк. 7) Укырга теләмичә калган намазларның казасы булмавын, каза хакында булган дәлил бары тик йоклап калучы һәм онытучы хакында гына булганга, Ибне Хәҗәр ифрат дәрәҗәдә дус тоткан Ибне Гарәби дә ихтыяр иткәндер. Каза юклык исә, гонаһсы зур булып та, бурыч төшерү өчен каза белән эш тәмам булмавыннандыр (ялган антка кәффәрат булмаганы кебек). 8-9) Налог дип сәүдәгәрләрдән шәргый булмаган рәвештә алынган малларга әйтелә. Табыштан алынган малларның ният белән зәкаттән саналачагын Әбү Хәнифә мәзһәбенә ияргән соң имамнар арасында дәгъва итүчеләр бар. Һәр ни бу мәсьәлә Ислам галимнәре арасында каршылыклы. Бер-беренә хилаф сүзләрнең берсен алган өчен Ибне Тәймия кайсы яктан гаепле булыр? Фәкать, хакыйкать хәлдә, бу сүзне Ибне Тәймиягә нигезләү яла ягудыр. 10) Вакыф мәсьәләсендә Ибне Тәймия рәвешендә бер дәгъваны хәнәфиләрдән дә дәгъва кылучылар бар. Хәнәфи мәзһәбендә булган имамнар әлеге дәгъвалары белән дошман тотылмаслар, бәлки иҗтиһади мәсьәлә булганга гафу ителсәләр, бер Ибне Тәймия генә ни өчен дошманлыкка лаек булыр? 11) “Иҗмагка каршы булучы фасикъ та, кәфер дә түгел” дигән сүзнең Ибне Тәймиядән икәнлеге ышанычлы булса да, монда гаҗәпләнерлек нәрсә бармы? Мөгътәбәр галимнәрдән Әбү Зәрга: “Иҗмагка каршы булучыларны ничек көферлеккә чыгару мөмкин? Иҗмагның үзен инкар итүчене дә көферлеккә чыгармыйбыз, ахыр чиктә әлеге кеше бидгатькә мөнәсәбәтле булыр”, - дияр. Чынлыкта Ибне Тәймия мондый сүз сөйләмәс, Ибне Хәҗәрнең әлеге сүзләре яла ягудыр. 12-14) Ибне Тәймия Коръән турында Әхмәд бин Хәнбәл мәзһәбендә булганга һәм хәнбәлиләрнең тәхкыйк мәзһәбенә күрә Коръән хакында булган сүзләрдән Аллаһ Тәгаләнең урында булуы һәм Коръән дә Аллаһ Тәгаләнең яңа булуын белдермәгәнгә Ибне Хәҗәр бәхәсләре нигезсездер.

Шулай ук җисем һәм җәһәт һәм галәмнең кадим булу иснәдләре дә Ибне Тәймиягә аталган яла ягудыр. Ибне Тәймиягә башлап бу яланы ягучы (гареш хакында) дивана булган. Ибне Тәймиянең галәмнең кадимлеге хакында фәлсәфәгә һәм җисем хакындагы арттыруларга каршы язган мөстәкыйль һәм аңлаешлы әсәрләре мәйданда икән, моның кебек яла ягуларның таралмаячагы мәгълүм. Диванининың: “Мөҗәссимнәрнең (гәүдәләндерүчеләрнең) күпчелеге Коръәннең һәм Сөннәтнең тышкы мәгънәләрен алучы заһирилар һәм күпчелеге яңартучылар. Ибне Тәймия һәм аның тарафдарларына җиһәтне (тараф) исбатлауда зур омтылыш, аны кире кагуны сүгүдә чиктән чыгу хас. Кайбер китапларында аек акыл каршында ул юк дип әйтү белән, аны һәр җирдән эзләдем табалмадым дип әйтү арасында аерма юк диеләә, кире кагучыларны алласызларга кертә һәм бу, аның әсәрләренә иярүчеләр аның гыйлемдә дәрәҗәсе зур дип тануларына карамастан”, - дигәненә, Алуси Шиһабеддин: “Ибне Тәймия гәүдәләндерүчеләрдән булуыннан Аллаһ сакласын, киресенчә ул Аллаһ Сөбханәһү Үзе һәм Расүлуллаһ теләгән мәгънәдә “югарыда булуны” әйткән кешеләрнең иң гонаһсызы һәм бу тирән мәгънәләрдә элгәреләрнең мәзһәбе. Ибне Тәймия гәүдәләндерүдән ерак тора. Җәләледдин әл-Дивани һәм аның кебекләр хәдисләрне һәм элгәреге мөселманнарның сүзләрен белми торган иң надан кешеләрдәндер”, - дип үз каләме белән язып куйгандыр. 15) Пәйгамбәрләрнең гонаһсызлыгы мәсьәләсендә Ибне Тәймия җөмһүр мәзһәбендә булып, башка бер сүзе юк. 16) Зиярат мәсьәләсендә Ибне Тәймия бер үзе генә түгел, бәлки Китап һәм Сөннәт гыйлемен яхшы белгән күп затлар аңа тарафдарлардыр. Әлеге хосуста язылган әсәрләрне өйрәнүчеләр бу мәсьәләнең хакыйкатен белерләр. “Ибне Тәймия зиярат кылудан тыядыр” дигән сүз фәкать ялгандыр. Нигә дисәң, Ибне тәймия зияраттан түгел, ә зиярат нияте белән сәфәрдән һәм мәетләрдән ярдәм сорап мөрәҗәгать итүдән тыядыр. 17) Тәүрат белән Инҗил хакында булган сүз өчен гаеп итәргә урын юк. Нигә дисәң, имам Бохари[1], Ибне әл-Хатыйб Фәхреддин әл-Рази да шулай ук дәгъва кылалар. Бохари белән Рази әлеге дәгъва сәбәпле ачуга дучар булмаганнары хәлдә, Ибне Тәймия ни өчен булыр? Ибне Хәҗәрнең әлеге иснады да фәкать яла ягудыр. Ибне Тәймия андый дәгъва кылмаган, моңа әсәрләре шаһиттыр. Ибне Хәҗәр үзе дошман күргән Ибне Тәймиягә гаепләр тагудан гаҗиз калганнан соң, бик күп дәлилсез нәрсәләрне тагарга мәҗбүр була һәм ничек булса да өстенә гаеп йөкләтергә сылтаулар, ялган сәбәпләр табарга тырышадыр. Ибне Гарәби һәм башка тәсауф әһленә, Ибне Тәймиядән дип әйтелгән сүзләрдән дә яманрак сүзләр әйтелсә дә аларны дөресләр өчен бөтен көчен сарыф итәр, хәтта ки кайвакыт булуы мөмкин булмаган ерак ихтималларга кадәр барыр. 18) Ибне Хәҗәрнең Ибне Тәймиягә исбатсыз иснадларыннан берсе тәмугъның юкка чыгу мәсьәләседер. Ибне Тәймия мондый бер дәгъваны кайсы әсәрендә әйткәндер, гаҗәп?! Инде килеп, Ибне Тәймия шундый бер дәгъвада булса, аның өчен Ибне Тәймиягә дошманлык кылырга юл бармы? Мондый сүз Ибне Хәҗәр уйлаган кебек иҗмагны бозу да түгел. Ибне Хәҗәр Ибне Тәймиягә дошманлык кылырга бер сәбәп тапканга булса кирәк, әлеге тәмугъ мәсьәләсенә гаять әһәмият бирер. “Әз-зәүәҗир гән икътираф әл-кәбәир” исемле китабында: “Ибне Тәймия көннәрнең берендә тәмугъның бетәчәген сәхәбәләрдән хәзрәти Гомәр, Габдулла бин Габбас, Габдулла бин Мәсгуд, Әбү Һүрайра, Әнәстән һәм тәбигыйннардан Хәсән әл-Басри, Хәммәд бин Сәлмә, Гали бин Талха әл-Вәлиби һәм мөфәссирләрдән бер җәмәгатьтән алыр. Кайберәүләр Әхмәд бин Хәнбәл хәзрәтләре Габдулла бин Гомәрдән риваять иткән: “Килер бер көн, җәһәннәм ишекләре ябылыр, анда беркем булмас, бу анда озак вакыт торганнан соң булыр” хәдисе белән әлеге мәсьәлә хакында дәлил китереләр. Фәкать, әлеге хәдисне тапшыручылар арасында ышанычсыз һәм ялганчы адәм барлыгы риваять ителер һәм Хәсән әл-Басри бу турыда аннан дип әйтелгән сүзне кире кагуын ышанычлы әйтер. Күренгәнчә, Ибне Тәймия хәбәр алган кешеләрнең мондый дәгъвада булулары дөрес түгел. Дөрес булган тәкъдирдә дә, анда (җәһәннәмдә) гонаһлы мөселманнардан берәү дә калмас, ләкин

[1] جامع الصحيح ج 8 ص 216

кәферләр үз урыннарында тулган хәлдә мәңге аннан чыкмаслар, дип әйтү күздә тотылыр. Шулай да, Ибне Тәймия сүзенә туры килгән бер сүзне Фәхреддин әл-Рази үзенең тәфсирендә риваять иткән”,- дияр.

Чынлыкта Ибне Хәҗәр сүзенең нәтиҗәсе шушыдыр.

Җәһәннәмнең мәңгелек булу-булмавы хакында элгәрегеләрдән һәм хәзергеләрдән билгеле ике төрле риваять бар. Берсе, бетмәячәк дигәне хәлдә, икенчеләре юкка чыгачагын сөйләрләр. Беренче сүз дөресрәк булуында шөбһә юк. Ибне әл-Кайим исә соңгы сүзгә өстенлек бирүдәдер. Имам Суютый “Әд-дурру әл-мәнсүр” исемле тәфсирендә хәзрәти Гомәрдән: “Ут әһелләре утта чүлдәге ком бөртекләре санынча торганнан соң бер көн аннан чыгарлар”, - дип, Әбү Һүрайрадан: “Җәһәннәмгә бер көн килер, анда беркем дә калмас”, - дип, Габдулла бин Мәсгудтән: “Аңа (җәһәннәмгә) бер заман килер, ишекләре шапылдап ябылыр”, - дип, һәм Шәгъбидән: “Җәһәннәм ике йортның иң тиз төзелә торганы һәм иң тиз җимерелә торганы”, - дип күчерер.

Моңа нигезләнеп, әгәр дә Ибне Тәймиядән җәһәннәмнең юкка чыгуы турында сүз чыккан булса, моның өчен дошманлык кылырга урын юк. Чөнки әлеге сүз кайбер элгәреге һәм кайбер соңгы мөселманнардан күчкән иске бер сүздер. (Риваятьләр хакында Ибне Хәҗәрнең тикшерүләре кабул ителмәс. Габдулла бин Гомәргә нисбәт ителгән хәдистә ялганчы булса, Хәсән Басридан ышанычлы арадашчы аша риваять ителгән хәдистә ялганчы юклыкны Ибне Хәҗәр кайдан белгән?) Хәзрәти Гомәр һәм хәзрәти Гали хакында әдәпсез сүзләр чыгаруы Ибне Тәймиягә асылсыз бер яла ягудыр. Ибне Тәймиянең гакыйдәсе мәгълүм һәм китаплары дөньяның һәр тарафында таралганга мондый яла ягу “кешеләр күңеленә коткы салу” хөкеменә лаек булган кеше гамәленнән башка түгел. Ибне Тәймия Газали һәм Ибне Гарәби Ибне Сәбгыйн, Гомәр бин әл-Фарид һәм Шәзили кебекләрне кире какса, имеш-мимеш сүзләргә нигезләнеп түгел, бәлки әсәрләрендә күрелгән ачык шәригатькә хилаф булган сүзләре хакында кире кагадыр. Бу яктан Ибне Тәймия ялгыз түгел, бәлки Ибне Тәймия кебек башка Коръән һәм Сөннәт галимнәреннән күпләр дә әлеге кешеләрне кире кагырлар[1].

Нәтиҗә: Ибне Хәҗәрнең иҗмагны бозды дип, Ибне Тәймия хакында кылган дәгъвасы нигезсездер. Бу кеше күбесенчә Ибне Тәймия әсәрләрен күрмәгән, бәлки аннан-моннан ишеткән сүзләргә күрә каләм йөрткән.

Алусиның яклавы монда тәмам булды. Монда әйтелгән мәсьәләләрнең кайберләре хакында “Гайәт әл-әмәнә” авторы шулай ук өстәп ачыклау белән сәйләгән. Мөрәҗәгать ителә.

Көндәш каршында дәлил булмаган нәрсәләргә нигезләнеп исбатлау юлына керү бәхәс кагыйдәсенә хилафтыр. Шуңа күрә, Ибне Тәймия сүзләрен тикшерер өчен Сәбки, Ибне Хәҗәр әл-Мәкки фикерләрен алу дөрес булмас. Чөнки Ибне Тәймия Китап, Сөннәт һәм иҗмагдан башканы дәлил итеп алмаганга бер Сәбки, бер Ибне Хәҗәр түгел, аның каршында ун Сәбки һәм ун Ибне Хәҗәр сүзенең дә әһәмияте юктыр. Бәлки Ибне Тәймиянең теле боларга каршы: ”Әгәр дөреслектә булсагыз, дәлилләрегезне китерегез”, - дияр.

## 10 бүлек

### Дошманлыклар.

[1] “Мәшһүр кешеләр” җыентыгыннан 3 нче кисәк булган “Имам Газали” исемле мәкаләгә мөрәҗәгать ителер.

Ибне Тәймиягә каршы булган фиркаларның башкаларыннан кайберләре, хосусан дөньялары төзек булган бай һәм дәрәҗәле кешеләр Ибне Тәймия хакында: “Ибне Тәймия, Аллаһ Тәгаләдән башкага дога кылырга ярамый, һәм мәетләрдән ярдәм сорау дөрес түгел, дип мөселманнар арасына тәшвиш салды. Гакыйдәләрнең бозылуына һәм тәсаууф шәйхләренең хөрмәтләре бетүгә сәбәп булды. Аллаһ Тәгаләне хакыйкый тәэсир итүче дип ышанганнан соң, әрвахларны һәм шәйхләрне арадашчы итеп, алардан ярдәм сорауда ни зарар бар? Шуның өчен булса кирәк, Ибне Тәймия китапларын укучы юк, бәлки китаплары китапханәләрдә таралып көя азыгы булып ятадыр. Әлеге дәгъваларының шомлыгы һәм ишаннарның фатихасы булса кирәк, үзе төрмәгә салынды һәм төрмәдә вафат булды”, - диярләр.

Чынлыкта, бу сүзләр тәнкыйть-фәлән түгел, бәлки ачык бер дошманлыктыр. Акыллы һәм фикерле булу шарты белән һичбер мөселман мондый сүз сөйләмәс, аңы булган адәм мондый сүзләргә хакыйкать төсе бирмәс. Ибне Тәймия хата сөйләр, фикере ялгышыр, бу нәрсәләр мөмкиндер, моны кире кагып булмас. Хата сүзләрен дәлилләр белән исбат итәргә, фикеренең ялгыш булуы хакында нигез табарга (моңа көче җитү шарты белән) һәркемнең хакы бар. Шәригать куйган юл белән һәркем хәрәкәт итәр. Фәкать моның өчен Ибне Тәймиянең шәхесенә тыкшынырга һәм Аллаһ Тәгалә вазыйфасы булган тәкъдиргә катышып, алдан сөйләп торырга һичкемнең хакы юктыр.

Һич шөбһә юк, Ибне Тәймия төрмәгә ябылды һәм төрмәдә килеш вафат булды. Ләкин, бу хәлләр Ибне Тәймия өчен бер бәхетсезлекме, әллә гаделсез булган бер сәгадәт идеме? Моны белгән кем бар? Һич юк! Бу нәрсә Аллаһ Тәгаләнең Үзенә хас серләреннәндер.

Кешеләрнең язмышлары гаҗәп рәвештә төрле булуы мәгълүм. Берсе, алдында булган хисапсыз нигъмәтләрнең кайсына кул сузарга белмәгән хәлдә, икенче берсе ачлыктан җан бирер. Кайберләре мирас маллары белән этләр тәрбияләгәне хәлдә, кайберләре үз балаларының ачлыктан үлүләренә дә чара таба алмаслар. Кайберәүләр иң зур шәһәрләрдә урам тулы йортларга хуҗа булганнары хәлдә, икенчеләре кош оясы кадәр урын булмаганга юлда көн кичерерләр. Иң ахмак кешеләрнең нигъмәтләргә батып та, иң акыллы кешеләрнең гаҗиз булып гомер сөрүләре күрелмәгән нәрсәләрдән түгел.

Чынлыкта, мондый нәрсәләр тәкъдир серләредер. Моңа тыкшынырга бәндәләрнең хаклары юк. Үз вазыйфасын белеп, Җәнабе Хакның олуглыгын күңеленә китергән зат, теләсә зур галим булсын, теләсә аңсыз надан булсын, динсезлеккә авышмас. Әлеге хәлләр **“Ни теләсә шуны эшләр”** булган бер куәт иясенең әсәредер.

Кешеләр өчен дин һәм милләт юлында тоткын булу бүгенгә кадәр гарьлек булмады, моннан соң да гарьлек булмас. Төрмәгә ябылу гарьлек түгел, куркаклык һәм икейөзлелек һәм дә дин исеме белән дөнья туплау һәм шәригать белән сәүдә итү гарьлектер. Хөрмәтле милләтләр хис-тойгылары кешеләр, дин һәм милләт һәм дә халык файдасы өчен булган тоткынлыклар белән горурланырлар. Гарәпләрдән галиҗәнәб бер зат әйтер:

“Тоткын булдың, диделәр, әйттем:
Әсирлегем миңа зарар итмәс,
Кайсы кылыч кынысына куелмас.
Яки күрмәдеңме? Олуглар дус булды арысланга,
Түбән ерткычлар аны кире какканда”.

Икенче берсе:

“Синең кебек гаделсезлек белән тоткын булган,
Һәм тарлыкта калган кеше өчен,
Үрнәк юкмы Аллаһның илчесе Йосыфта ?!

Төрмәдә күркәм сабырлык күрсәтте бераз вакыт,

Һәм китерде аны күркәм сабырлык патшалыкка", - дип, бер дустын юатыр. Тоткын булган кешеләрнең һәрберсен дә үтерүче, карак, хыянәтче, сатлык дип санау дөрес түгел. Ихтимал араларында Аллаһ Тәгалә ризалыгы өчен бөтен рәхәтләрен корбан иткән, золым һәм тиранлыкка каршы көрәшүдә булганнар, дәүләт һәм милләт файдасы өчен алдан йөрүче хезмәтчеләр, Китап һәм Сөннәт юлында тырышкан хакыйкый галимнәр дә булыр.

Без үз гасырыбызда дөньялары иркен, тәннәре сәламәт һәм үзләренә күрә дә мәгыйшәтләре хуш булган кайбер затларны күрдек. Алар үзләренең мондый рәвештә бәхетле буларак дөнья кичерүләрен үзләрендә булган өстенлекләргә, шәйхләр каршында булган хуш күрелүләренә, гамәл һәм гакыйдәләренең нәтиҗәләренә бәйләп, башкаларга килгән бәлаләрне ул кешеләрнең догасыз булуларына һәм Хак Тәгалә каршында кыйммәтсезлекләренә бәйләрләр. Әмма бер миллионер яклы булуны дөнья һәм ахирәт матурлыгы дип санаган, үзе турында үз дәрәҗәсеннән күпкә югары фикердә булган берәү, Мисыр мөфтие Мөхәммәд Габдуһ хәзрәтләре белән остазы шәех Җәмаледдин Әфгани хәзрәтләренең күргән бәлаләрен бәхетсезлекләренә дәлил итеп матбугатта нәшер иткән иде. Икенче берәү дә, яшь бер галим вафат булып үзенең Хуҗасы хозурына сәфәр иткәч: "Яшь хәлендә бетте, Аллаһның җәза бирүедер!", - дип, җеназасы артыннан матбугат аша таш атып калган иде.

Һәркем белергә тиешледер ки, дөньябыз җәза йорты түгел, бәлки гамәл йортыдыр. Шуның өчен дөньяда вакытта адәм башына килгән нәрсәләрнең һәрберсен җәзадан санарга мөмкин булмас. Бер динсезнең дөньяви сәгадәтнең биегенә ирешеп тә, бер иманлының җәфа астында җан бирүе мөмкиндер. Коръән Шәрифтә: **"Әлиф, ләм, мим. Әллә кешеләр, иман китердек, дип әйткәннәреннән соң, үз ихтыярларында калырлар һәм сыналмаслар дип уйлыйлармы?! Без инде алардан алда килгәннәрне сынадык. Аллаһ, әлбәттә, иманнарына тугры булучыларны һәм ялганчыларны белер[1]"**, - дип әйтелә.

Моңа нигезләнеп, бер кешенең төрмәдә вафат булуыннан бәхетсез булуы, һәм мәхкәмәдә рәис булып торудан яки үз-үзенә дин галиме исеме бирүдән икенче бер кешенең бәхетле булуы аңлашылмас. Пәйгамбәребезнең күз нурлары Ислам дөньясының иң таркау вакытында куй урынына бугазландылар, әмма Язид халифлек минбәрендә бик гыйззәтләр эчендә яшәде. Тәкъдир середер, әфәндем, тәкъдир сере!

Ибне Тәймия мәетләрдән ярдәм сорауны дөрес дип санамавы һәм үз гасырында булган тәсаууф шәехләренә ышанучы булмаганы өчен аларның догалары һәм мәгънәви күрсәтмәләре сәбәбеннән тоткын булсын, ләкин дөнья тормышын тулысынча шәйхләр һәм мөршидләр кулларына биргән, ярдәм сорауны хәтта үтәлүе тиешле гамәл дәрәҗәсендә күргән затлар ни өчен тоткын булдылар? Бер бабасының Әхмәд Рифагый һәм икенче бабасының да Габделкадир әл-Кәйләни икәнен дәгъва кылган асылзадә ни өчен бәлагә очрады? Әлеге мәсьәлә хакында китаплар һәм мәкаләләр нәшер итеп, бөтен дөнья мөселманнарына дәгъвәт иткән кеше ни өчен ихтыярсыздан дәрәҗәсен югалтты? Чынлыкта моның кебек нәрсәләрнең сәбәпләрен тикшерү бәндәләр вазыйфасы түгел. Кешеләр үз чикләрен үзләре белергә, тәкъдир серләре белән чуалмаска тиешле.

Ибне Тәймия төрмәгә салынып, төрмәдә вафат булса да, ат урлаганы һәм чит хатын белән шәргый булмаган сурәттә мөнәсәбәттә булганы өчен, яки гыйддәле хатыннарны өч, биш сум бәрабәренә икенче иргә никах белән бирүе, вакыф һәм ятимнәр малларын ашаганы өчен яки үзенең диндәшләре өстеннән донос кылып, мәктәпләрне һәм шәкертләрне таратканы өчен түгел, бу хәл һәркемгә мәгълүм.

---

[1] "Гәнкәбут" сүрәсе, 2,3 аятьләр

Хак сүзлелек, эчкерсезлек һәм кыюлык сәбәбеннән төрмәгә ябылучылар һәм төрмәдә вафат булучылар арасында Ислам галәмендә ялгыз бер Ибне Тәймия генә түгел, бәлки бик күп “ибне тәймия”ләр бар.

Сәгыйд бин Җәбирнең башы киселде, Мәлик бин Әнәс җитмеш камчы сугылып, куллары чыгарылды, Әбү Хәнифә йөз камчы сугылды һәм бер риваятькә күрә төрмәдә вафат булды. Әхмәд Ибне Хәнбәл богауланган хәлдә егерме сигез ай төрмәдә ятты, соңыннан җан әсәре генә калганга кадәр суктырдылар. Имам Шәфигыйның атаклы шәкертләреннән булган Бувәйтый адәм күтәрмәслек авырлыкта булган богаулар белән муеннары, кул һәм аяклары богауланып, Мисырдан Багдад шәһәренә җәяү барырга мәҗбүр ителде һәм әлеге мәшәкатьләр тәэсирендә Багдад төрмәсендә вафат булды[1]. Имам Нәсәине аяклары белән таптап үтерделәр. Сибәвәйһи остазы булган Әбү Гомәр Гыйсә әл-Сәкафи богауланган хәлдә Басрадан Багдадка барды, Багдадта камчы белән суктырдылар. Әһле тәсауф шәехе булган Әбү әл-Габбас Әхмәд бин Гата камчы белән кыйналганнан соң вафат булды. Боларның мисаллары бик күптер. Әгәр дә язмабыз күләме мөмкинчелек бирсә, бәла күргән кешеләрнең бик күпләрен монда язар идек. Монда исемнәре телгә алынган кешеләрнең гаепләре нәрсә иде? Бу турыда мәгълүмат алу өчен вакыйганы күреп торучы кешеләр исән булмаса да, тарих исәндер.

Дөнья әһле белән бәйләнеше булмаган, гыйлемнән башка нәрсәдән ләззәт алмаган һәм үз гакыйдәсен һәм вөҗданын һич нәрсәгә алыштырмаган Ибне Тәймия газап чигеп тә төрмәдә вафат булса, бу нәрсә гаҗәпмени?

Кайбер язучылар Ибне Тәймиянең акылында зәгыйфьлек булуы һәм үзенең уйламыйча, нигезсез хәрәкәте сәбәпле башына бәла китерүен кайвакыт ачыктан-ачык, кайвакыт ишарәләп әйтерләр.

Бөтен уйлары, хәләл-хәрамга карамыйча, балалары өчен мал җыю, шәһвәт әсирләренең оятсызлыкларына кул чабып тору, бөек адәмнәр каршында койрык болгап югары исем-дәрәҗәләрен саклаудан гыйбарәт булган кешеләр каршында, һич шөбһә юк, Ибне Тәймиянең үз нәфесенә бу кадәр мәрхәмәтсез булуы һәм дөньясы өчен тырышмавы акылсызлыктыр. Фетнәдән-фетнәгә, михнәттән-михнәткә, төрмәдән-төрмәгә күчеп йөрүе саксызлыктыр. Әгәр дә Мисырга кергәч тарафдарлары илтифатларына бәһа куйган булса иде, бөтен эше юлына куелган булыр иде. Фәкать, Ибне Тәймия карашынча мондый нәрсәләр үзләре акылсызлык һәм сабыйлык саналып, акыл исә, моннан бөтенләй башка нәрсә иде.

Сәяси һәм мәдәни, гыйльми һәм дини инкыйлабларга сәбәп булган затларның һәрберсе акылсызлыкта гаепләнер һәм һаман да гаепләнәләр. Акыллыларның акыллысы булган Пәйгамбәребез хәзрәтләре дә мондый гаептән читтә калмады. Ихтимал, мондый хәл, диванаханәләрдә тотылган юләрләрнең үзләрен иң акыллы адәмнәр санап та, үзләрен ябып тотучыларны хакыйкать хәлдә диваналар дип белүләре кебек бер нәрсә булыр.

Аллаһ Тәгаләнең хакыйкый тәэсир итүче булуы кире кагылмаган сурәттә әрвахлардан ярдәм сорау һәм шәйхләрдән мәгънәви ярдәм сорау зарар күрмәү иң акылсыз һәм иң ялган бер фикер икәнлегендә шөбһә юк. Милләтләрдән бер милләткә караган кавемнәрнең һичберсе Аллаһ Тәгаләнең хакыйкый тәэсир итүче булуын кире какмас, һәм һичберсе сынымнар һәм башкаларның тәэсир итүдә катнашуларын дәгъва кылмас. Иң вәхши урында тереклек итүче рус халкы да үзенең троицасын бары тик шәфәгатьче һәм Аллаһ белән ике арада арадашчы икәнен сөйләр. Бу турыда гарәпләрнең җаһилият вакытларында сөйләнгән шигырьләрен тикшерергә яки диннәр тарихы белән танышырга ихтыяҗ юк. Коръәндә булган хисапсыз аятьләр мөшрикләрнең үз сынымнарының бары тик

[1] طبقات الشافعية الكبرى. ج 1 ص 275

арадашчы гына булуларына ышанулары турында сөйләр. **“Үзләренә яклаучы буларак Аннан башка затларны алучылар, без аларга фәкать Аллаһка ныграк якынайтсыннар өчен генә гыйбадәт кылабыз, диләр[1]”. “Һәм алар Аллаһтан башка затларга, аларга зарар да, файда да китерә алмый торган нәрсәләргә гыйбадәт кылалар һәм әйтәләр: “Алар Аллаһ каршында безнең яклаучы шәфәгатчеләребез”, - дип[2]”.** Чынлыкта Ислам шәригате боларны да кире кагып ширек саный, хакыйкый тәэсир итүче Аллаһ Тәгалә генә дип белеп тә, бары тик арадашчы гына булачакларын өмет итеп Ләт һәм Гуззәгә дога кылган Мәккә мөшрикләрен кәферләр дип хөкем итәдер.

Ибне Тәймия китаплары гамәлдә кулланылмыйча китапханәләрдә көя азыклары булып ятуда булсалар, алар сәбәбеннән мөселманнар арасына нинди юл белән тәшвиш төшсен дә, һәм бу әсәрләрнең тарикать шәйхләренең дәрәҗәләре кимүгә кайсы яктан тәэсире булсын? Китапларның китапханәләрдә җыелып ятулары ул китапларның файдасызлыгына һәм киресенчә күп таралулары кабул ителүләренә дәлил булмас. Имам Шәфигый, Мөхәммәд бин әл-Хәсән әл-Шәйбәни, Әбү Йусуф әсәрләре бик аз таралганнары хәлдә, “Мең дә бер кичә” һәм дә “Шерлок Холмс” исемле әсәрләр белән дөнья тулган. Моннан исә әүвәлгеләренең фатихасыз һәм соңгыларының фатихалы булулары аңлашылмас. Шулай да Ибне Тәймия китаплары дөньяның һәр тарафына таралганнар, Китап һәм Сөннәт галимнәре тарафыннан игътибар казанганнар. Шуның өчен Ибне Тәймия хакында мондый рәвештә дошманлыклар кылу нигезсез һәм мәгънәсездер.

Хакыйкый инсан шулдыр ки: үзенең хак дип тапкан гакыйдәсе һәм дөрес дип белгән мәсләге хакында дөньяның һәртөрле ачы мәшәкатьләрен һәм авырлыкларын күтәрер дә, моның өчен шикаять итү түгел, хәтта күңеленнән дә зарланмас.

## 11 бүлек

### Тарафдарлары һәм аларның мактау сүзләре.

Гыйлем әһелләренең дошманнары күп булу нисбәтендә тарафдарлары һәм мактаучылары да булыр. Бу эш гыйлем әһелләренең авырлыкларын җиңеләйтәчәк иң бөек юанычтыр. “Дошманнарың явызлык кылалар һәм дусларың мактыйлар”, диюче кешегә имам Мәлик хәзрәтләре: “Кешеләр һәрвакыт шулай, ләкин без сөннәттән башкага иярүчедән Аллаһка сыенабыз”, - дигән[3].

Ибне Тәймиянең дошманнары, көнләшүчеләре күп булса да, тарафдарлардан һәм мактаучылардан да мәхрүм булмаган. Әсәрләрен диккать белән укучылар ихтимал ки дусларының мактауларына, көнләшүчеләрнең дошманлыкларына мохтаҗ булмаслар һәм үзләре турыдан-туры үз үлчәүләренә куеп аның кем булуын таныйлар. Фәкать һәрбер галимнең язганнарын укып чыгу бөтен кеше өчен җиңел булмас. Шуның өчен бер кешенең тәрҗемәи хәле язылганда дошманнарының явызлыклары, тарафдарларының мактау-олылаулары язылыр булса, тәрҗемәсе язылачак кеше хакында гаделлек белән бер хөкем йөртү байтак адәмнәр өчен кулай булыр.

Ибне Тәймиянең каршылары, аларның тәнкыйтьләре һәм дошманлыклары әйтеп кителде (8-10 бүлекләр). Инде бу урында тарафдарлары һәм аларның мактау сүзләреннән мисаллар китерәчәкбез. Безгә мәгълүм булган тарафдарлары түбәндәгеләр:

---

[1] “Зумәр” сүрәсе, 3 аять

[2] “Юныс” сүрәсе, 18 аять

[3] تذكرة الحفاظ ج 1 ص 191

1) Ибне Дәкыйк әл-Гыйд (Тәкыйуддин Әбү әл-Фәтех Мөхәммәд бин Гали әл-Кушайри). 702 елда вафат булды. Шәфигый мәзһәбендә мөгътәбәр бер галим булып, язган китаплары күптер. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Аны бөтен гыйлемне туплаган кеше дип таптым, гыйлемнең кай өлешен теләсә, шуны кулланыр”, - дигән.

2) Габдулла әл-Гыйракый (Габдулла бин Хәмид әл-Шәфигый). Ибне Тәймиянең гасырдашларыннан булган бу зат Ибне Кудәмәгә язган шәхси хатында әйтә: “Элгәреләрнең һәм хәзергеләрнең китапларында зәгыйфь һәм буш сүзләр күреп гаять хәсрәтләнер һәм Ислам әсәрләре ялганнар һәм уйдырмалар белән тулганга, өметсез булган идем. Чиста Сөннәттән һәм элгәреләрнең юлыннан гыйбарәт булган әсәрләрне эзләр идем, фәкать таба алмавым сәбәпле Аллаһ Тәгаләгә дога кылырга керешер идем. Аллаһ Тәгалә бер вакыт дөнья имамы булган Ибне Тәймия әсәрләрен күрергә насыйб итте. Күңелем хасталыгына шифалы дәваны алардан таптым. Укып чыкканнан соң күңелем ачылды. Очрашыр өчен Димәшкъ шәһәренә сәфәр чыгарга хәзерләнгәндә шәйх хәзрәтләренең вафат булу хәбәре иреште. Башыма төшкән әлеге кайгыны белдерергә кодрәтем юк. Хәтеремә төшкән саен хәсрәт яңарып торадыр. “Иннә лилләһи үә иннә иләйһи раҗигун үә лә хәулә үә лә кууәтә иллә билләһил-галийил-газыйм”. Моннан алдагы хатыгызда шәйх хәзрәтләренең китапларының эчтәлеген җибәрергә вәгъдә иткән идегез. Әгәр дә әлеге вәгъдәне үтәсәгез Аллаһ юлында әҗерле гамәлдән хисапланыр иде. Шәйх хәзрәтләренең дусларына, олылар һәм кечеләренә, картлар һәм яшьләренә сәламебезне тапшырсагыз мәрхәмәтегездән булыр”.

3) Бәрзәли (Гыйлмеддин Әбү Мөхәммәд әл-Касим бин Мөхәммәд әл-Әшбили). 739 елда вафат булды. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Аның кебек һәр нәрсәне белгән икенче бер имам юк иде, иҗтиһад дәрәҗәсенә ирешкән һәм анда мөҗтәһидләрдә булырга тиешле шартлар тупланган иде. Әгәр тәфсир кылса, аның күп белүеннән, дәлилләрне яхшы китерүеннән, һәр сүзне үз урынына, дөресен-дөрескә, зәгыйфен-зәгыйфкә, ялганын-ялганга куюыннан һәм һәрбер фән күзлегеннән чыгып сөйләвеннән кешеләр таң калалар иде. Һәм бу, дөнья шөгыльләреннән аерылуы, зөһедлеге, Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылу белән мәшгуль булуына карамастан”, - дигәндер.

4) Ибне Кудәмә (Шәмседдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Габдулһүдә әл-Хәнбәли). 744 елда вафат булды. Бу зат Ибне Тәймиягә ярдәм йөзеннән Тәкыйуддин әл-Сәбкигә каршы “Әл-сарим әл-мәнки фир-радди галә әл-Сәбки” (“Сәбкине кире кагуда катгыйлык”) исемле бер әсәр язды. Бу әсәре исә, үз гасырыннан башлап шөһрәт тапкандыр.

5) Зәһәбий (Шәмседдин Әбү Габдулла Мөхәммәд бин Госман бин Каймаз). 748 елда вафат булган. Бу кеше Ибне Тәймиягә мактау сүзләре әйткәннән соң: “Ул үрнәк тормышына әһәмият бирергә иң лаек кеше һәм аның кебек икенче бер кешене күргәнем булмады һәм ул үзе дә күрмәде дип әйтсәм, ялгышмам”, - дигән.

6) Әбү әл-Хәҗҗәҗ әл-Мәзий (Йусуф бин Җәмаледдин бин әл-Зәкий Габдеррахман бин Йусуф әл-Кәлбий әл-Кудагый әл-Шәфигый). 742 елда Димәшкъ шәһәрендә вафат булды. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Аның кебекне күргәнем булмады һәм ул үзе дә күрмәде. Аның кебек Аллаһның Китабы һәм Илчесенең Сөннәтен белгән һәм алар белән гамәл кылган икенче бер затны күрмәдем”, - дигән.

7) Ибне Фадлулла (Шиһабеддин Әбү әл-Габбас Әхмәд бин Мөхийиддин әл-Гәмрий). 749 елда Мисарда вафат булды. Ибне Тәймия хакында: “Хафиз, ышанычлы галим, мөҗтәһид, мөфәссир, шәйхул-Ислам, гасырның сирәк кешеләреннән, үзе бер өммәткә тора иде. Мәзһәбләр арасындагы таркаулыкны туктату, берләштерү дәрәҗәсенә җитте.

Кешеләрнең иң зиһенлесе, ятлаганын бик аз оныта иде. Тәфсирдә һәм Коръән фәннәрендә имам, фикһны һәм фикһ галимнәре арасындагы каршылыкларны яхшы белә иде”, - дигән.

8) Ибне әл-Вәрдий (Сиражеддин Әбү Хафс Гомәр бин Музаффар). 749 елда вафат булды. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Хәдисләрне тапшыручы кешеләрне, аларның дәрәҗәләрен бик яхшы белә, аларны тикшерүдә һәм төзәтүдә тәҗрибәсе зур иде. Хәдис фәннәрен яхшы белә, хәдисләрнең сүзләрен яттан белеп, алардан дәлилләр чыгаруына гаҗәпләнерлек иде. Хәдисләрне “Алты китап” һәм “Мөснәд”тән булуларын күрсәтүдә гаять төгәл иде”, - дигән[1].

9) Кәтбий (Фәхреддин Мөхәммәд бин Шакир әл-Хәләбий). 764 елда вафат булды. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Ул Аллаһны танып-белгән имамнарның имамы, өммәтнең мөфтие, гыйлем дәрьясы, хафизлар әфәндесе, сүзләрне һәм мәгънәләрне белүче, үз гасырының бердәнбер әйдаманы, шәйхел-Ислам, халыкларга үрнәк, заманның галиме, Коръәнне аңлатучы, заһидларның башлыгы, бидгатьчеләрне тыючы, мөҗтәһидләрнең ахыргысы”, - дигән.

10) Ибне Кәсир (4 нче бүлектә 3 нче булып күрсәтелгән зат). Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Аңа хөсетлек һәм дошманлык кылдылар, шулай да әрләүченең битәрләве аны Аллаһтан аермады һәм үзенә дошманлык кылучыга ачу тотмады. Явызлык белән аңа тәэсир итә алмадылар, иң күбе, аны төрмәгә ябуга ирештеләр, шуңа да карамастан, Мисырда булсын, Шамда булсын, эзләнүдән туктамады, аңа нинди генә яла яксалар да игътибар итмәде”, - дигән.

11) Ибне Насыйреддин (Шәмседдин Мөхәммәд бин Әби Бәкер бин Габдулла әл-Шәфигый әл-Кайсый). 777 елда туып, 842 елда вафат булган. Бу кеше Ибне Тәймияне яклап “Әл-радду әл-вафир галә мән зәгәмә әннә мән әтлака галә Ибне Тәймия шәйхул-ислам кяфир” исемендә мөстәкыйль бер әсәр язган. Бу китапның басылу-басылмавында мәгълүматыбыз юк. Фәкать, Истанбулда солтан Баязид мәчете китапханәсендә кулъязма нөсхәсе булуыннан хәбәребез бар.

12) Ибне Хәҗәр әл-Гаскаләний (Шиһабеддин Әбү әл-Фадыл Әхмәд бин Гали әл-Хафиз). Әһле хәдис һәм шәфигый фәкыйһларыннан бөек бер зат булып, 773 елда Мисырда туды һәм 852 елда вафат булды. “Сахих Бохари”дан булган “Фәтхул-бәри” исемле әсәре Мисырда ике тапкыр басылгандыр. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Кояштан да атаклырак шәйх, аның “шәйхул-ислам” дип аталуы кичә әйтелгән кебек, алга таба да дәвам итәр һәм моны, аның дәрәҗәсен белмәүчеләр һәм гаделлек сөймәүчеләрдән башка, һичкем кире какмас. Шәригать галимнәре иҗтиһадка кирәкле нәрсәләрнең аңарда туплануын таныйлар”, - дигән.

13) Гәйний (Бәдреддин Мәхмуд бин Әхмәд). 725 елда дөньяга килеп, 855 елда вафат булды[2]. Хәнәфи фәкыйһләреннән һәм мәшһүр галимнәрдән иде. “Сахих әл-Бохари”га карата булган “Гамдәтул-карий” исемле шәрехе Истанбулда басылды. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Ул динне динсезләрнең уй-фаразларыннан саклаучы, Пәйгамбәрдән килгән хәдисләрне җентекләп тикшерүче. Аның әсәрләре дөньяга таралды һәм аларда хактан авышуны һәм фетнәгә китерүне күрсәтә торган берни дә юк. Зиярат кылу һәм талак мәсьәләсен тикшергәннән чыккан хөкеме, фәкать рөхсәт ителгән иҗтиһадтан гына. Мөҗтәһид ике хәлдә дә әҗер-савапка ия, иҗтиһад өчен аны сүгәргә һәм гаепләргә урын юк”, - дигән.

14) Бәлкыйный (Гыйлмеддин Салих бин Сиражеддин Гомәр). 869 елда вафат булды. Шәфигыйлардан иде. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Заманының галиме,

[1] تتمة المختصر ج 2 ص 286-287

[2] Аның вафат булу елы “Камус әл-әгъләм”дә ялгыш күрсәтелгән.

замандашларының бөеге, теле һәм каләме белән шәригатьне яклаучы, чиста диннең көрәшчесе", - дигән.

15) Суютый (Җәләледдин Әбү әл-Фадыл Габдеррахман бин Мөхәммәд). 849 елда "Суют" шәһәрендә дөньяга килеп, 911 елда вафат булган. Беркадәр китаплары Европада һәм Мисырда басылган. Бу кеше Ибне Тәймияне: "Пәйгамбәрләрнең варисы, мөҗтәһидләрнең соңгысы, Исламның бәрәкәте, галимнәрнең дәлиле, Сөннәтне тергезүче", - дип мактаган.

16) Күраний (Ибраһим бин Шиһабеддин Хәсән әл-Шәһер Зүрий әл-Күрдий әл-Шәфигый). 1025 елда Көрдестанда дөньяга килеп, 1101 елда Мәдинәдә вафат булды. Китаплары күп булып, һәрбер әсәрендә Ибне Тәймиягә тарафдарлык күрсәтә һәм һәр урынлы җирдә аның көндәшләренә каршы чыга.

17) Гали әл-Карий (Гали бин Мөхәммәд бин Солтан әл-Һәравий әл-Хәнәфи). 1014 елда Мәккәдә вафат булды. Мәшһүр Коръән укучылардан һәм хаттатлардан иде. Бу кеше Ибне Хәҗәрнең "Шәмәьил" шәрхендә Ибне Тәймия белән Ибне әл-Каййим хакында сөйләгән дошманлыкларына каршы "Мишкәт" шәрхендә (427-428 битләр): "Алар Сөннәт вә җәмәгать әһленең олуг галимнәре һәм бу өммәтнең әүлияларыннан[1] иде", - дип кире каккандыр.

18) Мәргый әл-Хәнбәли (Мәргый бин Йусуф бин Әби Бәкер). 1033 елда Мисырда вафат булды. Бу кеше Ибне Тәймия хакында "Әл-кәүәкиб әл-дүррия фи мәнакыйб әл-имам әл-мүҗтәһид Ибне Тәймия" исемле мөстәкыйль бер китап язган.

19) Вәлиулла әл-Дәһләви (Әхмәд бин Габдеррәхим әл-Гамрий). 1110 елда дөньяга килеп 1172 елда вафат булды. Һиндстанда мәшһүр һәм мөхтәрәм галминәрдән булып, язган китаплары бик күптер. Бу кеше "Әл-тәфһимәт әл-иләһия" исемле әсәрендә Ибне Тәймия хакында: "Без аның Аллаһның Китабы Коръәндә галим булуына, аның телдәге һәм шәргый мәгънәләрен яхшы белүче икәнлегенә, Расүлуллаһның Сөннәтен һәм элгәреге гыйлем әһелләренең әсәрләрен саклаучы һәм аларның телдәге һәм шәригатьтәге мәгънәләрен белүче булуына инандык. Ул нәхү һәм тел гыйлемендә остаз, хәнбәли мәзһәбенең нигезен һәм юнәлешләрен хаталардан арындыручы. Гаять зирәк акыллы, телгә бай, сүзгә оста булып, Сөннәт әһле гакыйдәсен саклаучы иде. Анннан бозык һәм бидгать сүз чыкмады. Һәр нәрсәгә Коръән, Сөннәт һәм элгәреләрнең әсәрләреннән дәлиле бар иде. Галәмдә сирәк шәхесләрдән булган бу шәехнең һәм шәригатьне бидгатьләрдән арындыруда, катгый дәлилләр китерүдә аның дәрәҗәсенә ирешкән кешеләрнең мисалы һәм каршылыклары иҗтиһадтан һәм галимнәрнең бәхәсләреннән үсеп чыкса да, Аллаһ Тәгалә алып килгән хөкемнәрнең уннан беренә дә ирешә алмаган каршы булучыларның мисалы, сәхәбәләрнең үз араларында булган бәхәсләре кебек. Һәм бу турыда, яхшы яктан искә алудан тыш, артык тел озайту тиеш түгел", - дигән һәм моннан соң Ибне Тәймиягә күрсәтелгән дошманлыклар хакында җавап биргән.

20) Сүвәйдий (Әбү әл-Мәгали Гали бин Мөхәммәд Сәгыйд бин Әби әл-Бәрәкәт Габдулла әл-Багдадий әл-Габбас әл-Шәфигый). Хәдис гыйлемендә "әмируль-муэминин" дип мәшһүр иде. 1237 елда рәҗәб аенда Димәшкъта вафат булды. Бу кеше Ибне Тәймиягә мактау сүзләре әйтә иде. Язган китабы бардыр. Алусий Әбү әл-Сәнә шәйхләреннән иде[2].

21) Шәүкәний (Мөхәммәд бин Гали әл-Йәмәний). 1172 елда дөньяга килеп, 1250 елда вафат булды. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: "Ибне Хәземнән соң, аның кебек икенче берәүне белмим, озак вакыт дәвамында әлеге ике кешегә охшаган, аларга якын булган кеше булмады. Аңарда шартлары тупланганга күрә, ул иҗтиһад кылырга лаек булды. Аның фәтвәләре өч йөз томнан артып китте. Ул һәрвакыт хак сүзне сөйли иде һәм сүгүчеләрнең

[1] Соң галимнәр берсен мактаганда "әүлия", яманлаганда "кәфер", "динсез" димәсәләр күңелләре канәгать булмас.

[2] غرائب الاغتراب و نزهة الالباب ص 16-17

сүзләре аны Аллаһтан аермады. Дин белән уйнаучы, хөкемнәренә җиңел караучы, аның мәсьәләләрендә шәһвәт белән эш итүче, теленә ни килсә шуны әйтүче булмады, киресенчә, Коръән, хәдис һәм кыястан дәлилләр китерә һәм аларны ачыклый, үзеннән алда килгән галимнәр белән чагыштырып, бик нык эзләнә иде. Дошманнарының ачуы һәм кире кагулары күңелләрдә дошманлык уята, әгәр шулай булмаса, иҗмаг сүзе булыр иде, чөнки олы галимнәр аның гыйлемен таныйлар, очсыз-кырыйсыз дәрья, бетмәс хәзинә булуын беләләр. Кешеләр аңа карата ике төрле караштa: берләре аның кадер-хөрмәтен киметергә тырышалар, хәтта зур гаепләр тагалар, икенчеләре аны сыйфатлауда чиктән ашалар. Бу кагыйдә, гыйлеме зур, үз замандашларына караганда югары булган, Коръән һәм Сөннәт буенча гамәл кылган һәм шуның белән бергә авырлыклар күргән, соңыннан эше бөек, сүзе кабул булган, әлеге бәлаләр аркасында башкалар каршында туры сүзле булып танылган, гыйлемдә башкаларда булмаган өлешкә ия булган һәр галимгә карата кулланыла. Әлеге галимнең хәле әнә шундыйлардан иде. Аны санга сукмаучылардан тыш барысы да, үлеменнән соң кадерен белә башладылар, мактау сүзләре әйтелде. Язган китаплары таралды, мәкаләләре билгеле булды, бер төркем тәрҗемә дә итте. Аны мактадылар, шагыйрьләр аны искә алдылар. Дөньяга кызыкмады, ахирәт өчен тырышты, үз заманының иң акыллы, иң тотнаклыларыннан, иң аңлы һәм киң зиһенлеләреннән булды. Камил акыллы, киң гыйлемле, яхшы гамәлле булганы өчен аннан көнләштеләр һәм хаклыкка буйсынганы һәм халыкка тәэсир иткәне өчен аны дошман күрделәр”, - дигән.

22) Алусий (Әбү әл-Сәнәэ Шиһабеддин Мәхмуд бин Габдулла). Багдад шәһәрендә хәнәфиләр мөфтие булып, 1270 елда вафат булды. “Рух әл-мәгәни” исемле тәфсире Мисырда басылган. Бу кеше Ибне Тәймия хакында: “Ибне Тәймиянең бер мәкаләсен укыдым, хәнбәлиләр аңа әһәмият бирә, һәм анда гакыйдә мәсьәләсендә гаепләрлек берни дә күрмәдем. Фәкать үзеңнән чыгып аңлатуны кире кагуда катылык, мәгънәләрнең дөреслеге бозылмавына чиктән тыш омтылыш бар, әлеге омтылыш “тәҗсим” һәм “тәшбиһ”кә инанмавын катгый раслый һәм моны ачык аңлаешлы итеп әйтә. Аллаһны гәүдәләндерүне, күзаллауны, охшатуны кире кага торган әлеге ачык аңлаешлы сүзләрен ташлап, ул әйтмәгән сүзләрне аңа тагулары гаҗәп. Һәрхәлдә күп шәйхләрнең шәйх Мөхийеддин турында сөйләгәннәре кебек, аның турында да шулай сөйлиләр”, - дигән.

23) Садыйк Хәсән (Әбү әл-Тайиб Садыйк бин Хәсән әл-Хөсәйни). Бәһүпал дигән җирдә урынбасар булып, 1307 елда вафат булды. Бу кеше һәр җай чыкканда Ибне Тәймияне мактар, исемен ихтирам белән искә алыр иде.

24) Җәмаледдин Әфганий. 1314 елда Истанбулда вафат булды. Петербург шәһәрендә хозурына кергән вакытта “Әл-җавап әл-сахих лимән бәдәлә дин әл-мәсих” исемле китабы хакында мәгълүмат бирде һәм бөтен Ислам милләте бу китап өчен мөәллифе Ибне Тәймиягә рәхмәт әйтергә бурычлы булуын сөйләде.

25) Алусий Зәдә (Ногъман Хәйреддин). Багдадта мөфти булып, 1317 елда вафат булды. Ибне Тәймияне яклап “Җәләэ әл-гайнәйн” исемле олуг китабын нәшер иттергән.

26) Мөхәммәд Габдүһ (Мисыр мөфтие). 1323 елда вафат булды. Бу кеше Ибне Тәймиягә тарафдарлык итәр иде. Кайбер әсәрендә: “Мөселманнар үз диннәрендә галим булган вакытларында бөтен дөнья өстендә торырлар иде, әмма үз диннәреннән хәбәрсез була башлагач, дөнья мәсхәрәсе булып калдылар. Болар башка диннәрдә генә түгел, ә үз диннәрендә дә надан булганнан соң, хәтта үзләренең Китап һәм Сөннәткә хезмәт итүдә булган галимнәрен дә көферлеккә чыгара башладылар. Имам Газалинең “Ихйә”се Гарната урамында яндырылуы һәм дин юлында иң гайрәтле хезмәт итүче булган Ибне Тәймиягә “адашкан” һәм “адаштырылган” дигән исем бирелүе галимнәр киемен кигән наданнар сәбәбеннән булгандыр. Бу, үз диннәрендә надан булган галим кыяфәтле юлбасарлар

хакында канлы яшьләр белән еланса да урынлы булыр. Дин Исламны түбәнгә сөйрәүчеләр, ныклы дин тамырына балта чабучылар шулардыр", - дип әйтер.

Безнең үз гасырыбызда да Ибне Тәймиянең хәленә кереп, әсәрләрен тәкъдир иткән затлар бар. Бу җөмләдән Мөхәммәд Шүкри әл-Алусий, мөгътәбәр дини журнал "Әл-манар" сахибы Сәед Мөхәммәд Рәшид Риза, Габделкадир әл-Мәгърибн, Рафик бәк әл-Газыйм, Җәмил бәк әл-Газыйм, Мөхәммәд Бәдреддин әл-Хәләби, Мөхәммәд Күрд Гали һәм башкалар. Боларның әлеге хосуста булган әсәрләрен һәм матбугатта күренгән мәкаләләрен укыдык. Фәкать бер кешенең хөрмәтенә берләшеп әсәрләрен тәкъдир итүдән, аның һәр сүзен дөрес санап, һәр хосуста аңа килешү тиеш булмас. Шуның өчен тарафдарлык иткән әлеге кешеләрнең Ибне Тәймия фикерләренең һич беренә, яки кайберләренә килешмәүләре дә мөмкиндер.

## 12 бүлек

### Русия мөселманнары арасында Ибне Тәймия.

Русия мөселманнары арасында Ибне Тәймия әсәрләре тарала башлавы яңа нәрсәдер. Моннан егерме биш еллар элек аның исеме һәм тоткан мәзһәбләре башкаларның китапларында сүз арасында гына телгә алына иде.

Русия мөселманнарының аз санлы галимнәре арасында үзенең китапларында иң беренче буларак Ибне Тәймияне өйрәнгән зат (безнең фикеребезчә) Фазыл Мәрҗәни булгандыр. "Гакаид гаддия" кырларында әлеге рәвештә бер гыйбарә бар: "Әбү әл-Габбас Әхмәд Ибне Тәймия хәнбәлиләрнең "тараф" һәм "урын" турында әйткән хөрмәтле затларыннан, хәдис әһелләреннән. Аның тоткан юлы "урын"ны "гареш" дип раслаудан гыйбарәт булса, аның галәмнең барлыкка килүен әйтүе мөмкин түгел, бүлектән күренгәнчә шәхесләрнең барлыкка килүе белән канәгать була".

Ун елга якын булыр, Ибне Тәймиянең басылган әсәрләрен турыдан-туры укып килә идем. Бу язманы туплаганда тагын бер кат күздән кичердем һәм "җиһәт" белән "мәкән" маддәләренә аерым диккать иттем. Фәкать күземә андый бер нәрсә күренмәде. Ибне Тәймия үзенең һәрбер әсәрендә бер юл аңлатма бирә һәм һәрбер җай чыкканда "җиһат" һәм "мәкән" әһелләрен, хосусан мөҗәссимнәрне кире кага, хәтта мондый мәсьәләләрдә сүз сөйләүне бидгать саный. "Муафәка сарих әл-мәгъкуль лисахих әл-мәнкул"дә: "Аллаһның гәүдәсе бар яки гәүдәсе юк, материаль яки материаль булмаган хәлəттә, бөтен нәрсәне иңлиме, әллә юкмы, бер тарафтамы, әллә юкмы, очраклылыклар аның белән бәйлеме, әллә юкмы, һәм шуның кебек башка сүзләр барысы да яңа кәләм әһелләре арасында таралган сүзләр, мондый сүзләрне элгәреге мөселманнар һәм галимнәр бөтенләй сөйләмәгәннәр", - дип әйтә.

Дөрес, Ибне Тәймия Аллаһ Тәгаләнең Үзенә мәгълүм булган мәгънә белән "югары" "урнашу" кебек сыйфатларны исбат итәр, ләкин болардан "җиһәт" һәм "мәкән" булуы мәҗбүри түгелдер. Без күргән әсәрләренең һичберсендә Ибне Тәймия галәмнең мәңгелеген әйтми һәм мәзһәбенә дә моның белән бер нәрсә килмәгән һәм килмәс. Моңа бәрабәр Фазыл Мәрҗәнинең мондый бер сүзен тикшерми-нитми күчермәячәге дә мәгълүм. Мәсьәлә белән таныш булу өчен әлеге хәзрәтнең "Гакаид гаддия"гә язган аңлатмасының төп нөсхәсен күрү һәм "Вафият әл-эсләф"исемле әсәрендә Ибне Тәймия тәрҗемәсе хакында язган нәрсәләрен уку зарур күрелде. Әлеге сәбәптән гыйлемгә хезмәт итүне бәхет санаган

затлардан берсенә[1] мөрәҗәгать иттек. Алган җавабыбыз: “Фазыл Мәрҗәни тарафыннан “Гакаид гаддия”гә карата язылган аңлатманың караламасын карадым, монда исә басылган нөсхәдән артык бер нәрсә юк. “Вәфият әл-әсләф” караламасыннан 473 нче елдан игътибарга алып 757 нче елга кадәр булган бүлек хәзерендә табылмады, Садыйк әфәнде Ибне Галәйкәй мөлке булган камил нөсхә шулай ук үзендә түгел, бәлки читтәдер. Әлеге сәбәптән “Вафият әл-әсләф” китабында булган Ибне Тәймия тәрҗемәсен күрә һәм сезгә күчереп җибәрә алмадык”, - диюдән гыйбарәт булды. (Бу көндә Русия мөселманнарыннан Фазыл Мәрҗәнигә нисбәте булган затлар арасында шөһрәтле мөдәррисләр, имам һәм мөхәррирләр, дөньялары бик иркен байлар, акыллы һәм фидакарь сәүдәгәрләр күп булган хәлдә барлык әсәрләрен нәшер итү хакында җитди бер ныклык күрелмәде. Мисыр галимнәреннән шәех Бәхит белән кайбер Коръән сәүдәгәрләре иҗтиһадлары белән басылган аңлатмасы һәм дә икенче китап “Мөстәфәд әл-әхбар” чыгарма булсалар, башка әсәрләре исә үзе исән вакытта үзенең тырышлыгы белән нәшер ителделәр. Мәрҗәни хәзрәтләренең вафатына егерме еллар кадәр вакыт үткәне хәлдә тәрҗемәи хәле хакында кыскача булсын, галәм матбугатында бер нәрсә күренмәде. Фазыл Мәрҗәни исеме дөньяга таралган булса, башкаларның хезмәтеннән артык үзенең тырышлыгы сәбәбеннән таралгандыр.)

Оренбург шәһәренә баргач Фазыл Мәрҗәнинең балалары белән бу турыда сөйләшеп: “Юкса Фазыл Мәрҗәни “Гакаид гаддия” аңлатмасында булган сүзен Диванинын “Гакаид гаддия” шәрхендә хикәят иткән сүзенә таянып язганмы?” – дип соравыма: “Әтиебез хәзрәтләре моның кебек әһәмиятле мәддәләрдә Дивани сүзенә таянмас, әгәр дә Ибне Тәймиянең үз әсәрләреннән берсен күреп күчермәгән булса, башка бер галим сүзенә таянган булыр. Әтиебез күчергән әсәрләрнең һәрбере дә үз китапханәсендә булмас иде, бәлки Бохара һәм Сәмәрканд китапханәләренә дәвам иткәндә бик күп нәрсәләрне шулардан күчереп яки күңеленә алган нәрсәләргә таянып әсәрләренә керткәндер”, - дип җавап бирде. Һәрхәлдә бу турыда Фазыл Мәрҗәни кемнәргә таянганы безгә мәгълүм булмады һәм әлеге сәбәптән мәсьәлә ачыкланмаган хәлдә калды.

Мәрҗәни чордашларыннан һәм аннан алда булган галимнәр арасында Ибне Тәймия әсәрләре белән шөгыльләнүчеләр булуыннан хәбәребез юк, уебызча мондый нәрсә булмагандыр. Әмма бүгенге яшь галимнәребезнең күбесе Ибне Тәймия һәм Ибне әл-Кайим әсәрләре белән таныш булулары безгә мәгълүмдер.

Мөхтәрәм Галимҗан әл-Барудий хәзрәтләре безгә язган хосусый бер хатында: “Ибне Тәймия хәзрәтләре хакында яхшы фикердә булучы элек гасырларда Русиядә, ихтимал ки, фәкыйрь бер ялгызы гына булгандыр. Соңрак вакытларда бу турыда сезнең дус булуыгызны уйлый идем. Ибне Тәймия мәсләге гомумән гүзәлдер. 1872 милади елда гадәтемчә һәм теләгәнемчә күпме әсәре аркылы һәм соңрак та әлеге хәзрәт әсәрләренең үзеннән файда күрдем. Дошманнары тарафыннан китерелгән бәхәсләрнең күбесе, минем уемча, нигезсездер. Гыйлеме һәм калебе куәтле бер кеше булып, һәрбер сүзендә һәм тоткан мәсләгендә гайрәтле һәм батырдыр. Фәкать тәсавуф юлында тәрбияләнмәгән һәм аларның зәвыкларыннан өлеш алмаган булса кирәк. Әлеге сәбәптән дәрья кадәр булган гыйлемен рәсми дәрәҗәдә калдырган дип уйлыйм. Әлеге сүзләрем бер сөеклемә каршы һәм аның турында булган сүзләрдер. Актив яшьләрнең дүрт имамга иярүдән чыгу теләгендә булганнары хәлдә әлеге хәзрәткә сукырларча иярүләре һәр җирдә күреләдер. Әлеге хәлләре беркадәр ашыгу кебек күреләә”,- дияр.

Соңгы юллары хакында остаз мөхтәрәм хәзрәткә әйтәчәк бер сүзебез бар: яшьләр әгәр дә мәшһүр мәзһәб имамнарына иярү кирәк түгел дисәләр, Ибне Тәймиягә иярүнең тиешлеген дәгъва итәр булсалар, мондый нәрсә мантыйксызлыктан гыйбарәт булачагы

[1] Кәшшаф әфәнде Тәрҗемәни

мәгълүм. Фәкать яшьләр фикере башка төрле булуы аңлашылыр. Бу турыда алар белән фикер алышу һәм максатларын да турыдан-туры аңлашуда зарар булмас иде. Мондый бер хезмәт гадел һәм әхлаклы бер галим өстенә төшәчәгеннән олы затлар аны йөкләмә алсалар, урталыкта булган бозык аңлауны кире кагучылардан булырлар иде.

## 13 бүлек

### Ибне Тәймиянең михнәте.

Өстенлек һәм камиллек әһелләренең дөньяда бәла һәм мәшәкать астында гомер сөрүләре гадәт хөкеменә кергәндер. Кешеләргә ялагайланмаган һәм койрык болгамаган кешеләрнең насыйблары бәхетсезлектән башка нәрсә булмас. Имам Бохари бөтен дуслары хәтта ки шәкертләренең дә үзеннән читләшүләрен күргәч дөньядан бизгән һәм җанын алу хакында Аллаһ Тәгаләгә мөнәҗәт иткәндер. Хәзрәти Гомәр дә: “Гомәрнең дусты өчен хаклык ташланмас”, - дигән. Суфьян Сәүри дә: “Күршеләре тарафыннан макталган кеше ташланыр, чөнки тугры кеше макталмаска тиеш”, – дигән.

Ибне Тәймия гомере буенча ширек һәм бидгатькә каршы көрәшкәнгә һәм хак сүзле булганга чордашлары дошман булдылар, хосусан, гыйлемдә булган камиллеге өчен көндәшләренең хөсетлек тамырлары хәрәкәтләнде. “Галине сөйгән өчен түгел, киресенчә Могавияне яратмаганга” дигән кебек, бер-беренә ачык дошман булган рафидилар, “вәхдәт вуҗуд” (пантеизм) әһелләре, каберләргә гыйбадәт кылучылар һәм башка төрле бидгать таратучылар һәрберсе Ибне Тәймия зарарына берләштеләр һәм бу турыда һәртөрле сәбәпләргә тотындылар. Үзен түгел, хәтта аны “шәйх әл-ислам” дип әйтүчеләрне көферлеккә чыгарып фәтвәләр төзеделәр.

Ибне Тәймиянең беренче михнәте 698 елда “Әл-гакыйдә әл-химәвия әл-күбра” рисәләсе таралганда булды[1]. Бу вакытта Ибне Тәймия якынча 38 яшьләрендә иде. Чынлыкта дошманнар әлеге рисәләне алып халыкны котыртырга керештеләр, “әһле сөннә вә җәмәгә сүзенә каршы сөйли” дип мәсьәләне гаять зурайттылар, казыйлар һәм мөфтиләр тирәләрендә йөреп халык фикерен үз тарафларына бордылар, “Әл-гакыйдә”нең сүзләрен боздылар һәм бик күп урыннарда ялганнар уйлап чыгардылар, Аллаһ сакласын, “җисмият белән сөйли” дип яла яктылар. Хәнәфиләр казые булган Җәләледдин бу эшне үз өстенә алып, “Дәр әл-хәдис әл-әшрафия”дә бер мәҗлес төзеде һәм җавап алыр өчен дип, Ибне Тәймияне чакыртты. Ибне Тәймия исә казый хәзрәткә: “Үз эшеңне яхшы һәм тугры эшлә, игътикад тикшерү һәм мондый гыйльми мәсьәләләргә керешү синең вазыйфаң түгел, юк белән зәхмәт чигеп йөрмә!” – дип җавап язып җибәргәндер.

Әлеге җавап сәбәбеннән казыйның оятка калуыннан ачуы эченә сыймады. Урамга сөрән салучы чыгарып: “Әй, җәмәгать, белегез, Ибне Тәймиянең гакыйдәсе бозык, аңа иярә күрмәгез”, дип кычкыртып йөртә башлады. Әлеге вакыйгадан хәбәр алып, Димәшкъ шәһәре башлыгы Сәйфеддин Җаган: “Казыйларның, мөфтиләрнең мондый мәсьәләләргә керешергә хаклары юк, алар бары тик дошманлык һәм дәгъваларны хәл кылыр өчен куелган кешеләр генә, мондый гыйльми мәсьәләләргә катнашмасыннар!” – дип, кычкырып йөрүчеләрнең үзләрен камчылап кертте. Фәкать мәсьәләнең хакыйкатен аңламаулары сәбәпле халык арасында тавыш-гауга басылмады. Әлеге сәбәптән Ибне Тәймия шәфигыйлар казые Имамеддингә хәбәр җибәреп, бөтен халык каршында әлеге гакыйдәне укыячагын вәгъдә итте. Мәгълүм булган сәгатендә мәҗлескә барып Ибне Тәймия “Әл-гакыйдә әл-химәвия әл-

---

[1] Бу рисәлә бер-ике тапкыр басылды.

күбра”ны укып чыкты. Уку тәмам булганнан соң, шәфигыйлар казые халыкка мөрәҗәгать итеп: “Дөнья тутырып шаулап йөрдегез, инде гакыйдә укылды, Коръән һәм сәләф мәзһәбенә каршы ни нәрсә бар?” – диде. Җавап бирүче булмагач: “Кем дә кем моннан соң Ибне Тәймия гайбәтен сөйләп йөрер булса, мин аңа дошман булырмын”, - дип игълан итте. Бу фетнә шуның белән тәмам булды.

Әлеге вакытларда Мисырда Насыйр әл-Мәнбәҗий исемле бер шәйх чыгып, үзенә бик күп кешене ияртте, түрәләр арасына керде һәм гадәттән тыш шөһрәт тапты.

Бу кешенең Ибне Гарәби һәм Ибне Сәбгыйнгә ярау йөзеннән “хәдәс вуҗуд” гакыйдәсен яклавын һәм аны тотуын белдергәнгә һәрбер китабында әлеге мәсләкне кире кагып язучы Ибне Тәймия зарарына тырышлык куярга кереште. Мөгътәбәр кешеләр янында йөреп чыкты һәм мәликиләр казые Ибне Мәхлуф тә моның фикерен хуплаганга, икесе бергә бу эшкә тотынырга карар кылдылар. “Хәдәс вуҗуд” әһелләре белән рафидыйлар һәм башкалар үз араларында берләшеп: “Ибне Тәймия Ибне Тәүмәра кебек хакимият алырга тырышадыр”, - дип ачык ялган бер сәяси гаеп тактылар. “Гаиләлеләрнең һәр хәбәрен ишетү белән хатын-кызлар кияүгә чыгарга шикләнә башлый” дигән кебек, бу эшкә түрәләр дә әһәмият бирә башладылар. Моның нәтиҗәсе буларак Димәшкъ шәһәрендә булган дүрт мәзһәб галимнәреннән гыйбарәт бер мәҗлес төзеп Ибне Тәймиянең гакыйдәсен, мәзһәбен тикшерергә боерып Мисыр хакименнән Димәшкъ башлыгына хәбәр килде. Шуның нигезендә шәһәрдә булган галимнәр, мөфти һәм казыйлар, түрә һәм шәйхләрдән гыйбарәт бер мәҗлес төзелеп, 705 елның 8 рәҗәбендә дүшәмбе көн (1306 милади елның январенда) мәҗлес ачылды. Ибне Тәймия исә мәҗлескә барып түргә менеп утыра иде. Халык җыелып беткәннән соң әмир мәҗлесне ачты һәм бу мәҗлес Мисырдан килгән указ буенча Ибне Тәймия хакында булуын бәян итте, Ибне Тәймиягә мөрәҗәгать итеп: “Бүген сезнең гакыйдәгезне һәм үз мәзһәбегезне дәгъват кылып Мисырга язган хатыгызны тикшерәчәкбез”, - диде.

Ибне Тәймия: Минем һич кемне дәгъват кылып китап язганым юк, бәлки миннән сорарлар, мин исә шуларга җавап буларак язган идем. Минем гакыйдәм Китап һәм Сөннәттән гыйбарәттер. Шуннан башка мәзһәбем юк.

Әмир: Без гакыйдәңне үзеңнән туры язачакбыз.

Ибне Тәймия: Языгыз!

Әмир: Сөйләгез.

Ибне Тәймия: (Үзенең гакыйдәсен беркадәр аңлатканнан соң) Мин игътикадымны телдән аңлатыр булсам, минем өстемнән шикаять итүчеләр ихтимал ки: “Зарарлы игътикадларын белеп яшерде, монда әйтмәде”, диярләр. Шуның өчен моннан җиде ел элек язган гакыйдәмне укысыннар, бу гакыйдә исә халык арасына таралгандыр. - Әлеге гакыйдә китабын китергәннәрен көтеп торырга мәҗбүр булганга, Ибне Тәймия халык алдында әмиргә мөрәҗәгать итеп, - Бер кадәр белемсез кешеләр миңа яла ягып өстемнән солтанга гариза тәкъдим иткән. Гүзәл! Фәкать монда татарлар килде, Ислам мәмләкәте бәла-каза астында калды. Шул вакыт татарлар белән сугышыр өчен халыкны чакырып йөрүче мөгътәбәр затларга ихтыяҗ булды. Татар түрәләре, татар ханнары һәм гаскәр башлыкларына илчелек белән барырга һәркем курыкканга кеше кытлыгы күрелде. Шул вакытта әлеге минем өстемнән мәзһәб һәм гакыйдәмнең бозыклыгы белән әләкләүче динле муллалар һәм шәригать сакчылары кайда иде?” – диде.

Мәҗлес халкы бу сүздән намусландылар һәм гаять оялдылар, Ибне Тәймиянең хәтта Газан хан янына кадәр керергә һәм аны нәсыйхәт кылырга батырчылык иткәнен, бөтен әһле Исламны өндәп татарлар белән сугышка чыкканын фикерләп, үзләренең куркак адәмнәр булуларын исләренә төшереп, тиргә баттылар. Озак та үтмәде, Ибне Тәймиянең “Әл-гакыйдә әл-васитыйя” исемле китабы китерелде. Әмир кычкырып укыр өчен Камаледдин Зәмәлкәнигә бирде. Зәмәлкәни җөмлә-җөмлә итеп укырга кереште. Кайберәүләр үзләренчә

бәхәсләшер булсалар да, Ибне Тәймия һәрберсенә җавабын биреп үтә иде. Гакыйдә тәмам булганнан соң әмиргә мөрәҗәгать итеп, Ибне Тәймия: “Чынлыкта, минем гакыйдәм шушыдыр, сәләфләр гакыйдәсенә каршы булуын күрсәтү ниятендә булган кешеләргә минем тарафымнан өч ел кадәр кичектерү бирелә”, - диде.

Әмир: Коръән хакында булган гакыйдәгезне аңлатыгыз, дөреслектә бу мәҗлес төзелү дә шул мәсьәлә өчендер.

Ибне Тәймия: Бик күп кешеләр Коръән Шәриф укылган тавышлар һәм Коръән Шәриф язылган караларның борынгы һәм мәңгелек булуын Әхмәд Ибне Хәнбәл хәзрәтләреннән алсалар да, бу бер ялгандыр. Мондый сүзне Әхмәд тә, башкалар да сөйләмәде. Бәлки Әхмәд Ибне Хәнбәл: “Кем Коръән сүзен халык кылынган дип әйтсә, ул җәһмий, кем халык кылынмаган дип әйтсә, ул бидгатьче”, - дигән. (Ибне Тәймия моннан соң Коръән мәсьәләсендә булган гакыйдәсен аңлатып сөйләде һәм бәхәсләшүчеләрнең һәрберсенә тиешле җавапларын бирде).

“Әл-гакыйдә әл-васитыйя”дә булган: “Уттан котылган җәннәт әһелләренең ысулы, иман һәм дин ул - сүз һәм гамәл, калеб һәм тел сүзе һәм калеб, тел һәм әгъзалар гамәле”, дигән сүз укылганда голәмә минбәрендә утырган затлар эчендә мондый рәвештә бәхәс булды: Әлеге сүз котылу әһелләре ысулыннан булса, “иман ул дөрес дип белү” дигән кәләм әһле белән “иман ул дөрес дип тану һәм әйтү” дигән мәзһәбләр “котылу әһелләреннән” булмаска тиеш. “Котылу әһелләре”ннән булмаганнар, табигый “һәләкәт әһелләре” булачаклардыр.

Ибне Тәймия: Минем “котылу әһелләре” дигән сүзем Расүлуллаһ хәдисләренә туры килү йөзеннәндер. Расүлуллаһ иманны без әйткәнчә аңлаткан, һәм шул сүз сәхәбәләр һәм җөмһүр сәләф мәзһәбедер. Алардан соң кайбер затлар каршы булсалар да сәләф һәм сәхәбәләр өчен моның зарары юк. Сәхәбәләр һәм элгәреге мөселманнарга каршы булучыларның һәрберсенә һәлак булу тиеш түгел, ихтимал ки иҗтиһадларында хаталанулары сәбәпле гафу ителерләр. Ихтимал ки элгәреге мөселманнар мәзһәбе аларга тиешле дәрәҗәдә ирешмәгәндер дә, шул сәбәпле хатага дучар булганнардыр. “Җәһәннәм белән вәгъдә кылынучыларга аңлатучылар керми” дип әйтерләр. Шул сәбәпле иҗтиһадларында хаталанган һәм һәрвакыт яхшылык белән мәшгуль булган затларның да котылачаклары өметледер. Ихтимал ки, бу турыда һичбер сүз сөйләмичә тик торучы кешеләр дә котылырлар. “Дәшми калган – котылган”.

Мәҗлеснең каһарманы Ибне Тәймия булып, берүзе сөйләп торыр һәм һәр тарафтан бирелгән сорауларга җавап бирер иде. Дошманнары, аяклана һәм бара алмаганга, хәзерләнергә форсат табу нияте белән, мәҗлеснең бик озын булуын сәбәп кылып, икенче вакытка кичектерү хакында әмирдән сорадылар. Әмир, вакыт билгеләп, бу мәҗлесне таратты.

Икенче мәҗлес 12 нче рәҗәб, җомга көн булды. Ибне Тәймия дошманнары бу мәҗлескә беренче мәҗлестә булмаган үз тарафдарларыннан бик күп кешеләр алып килделәр. Гыйлме кәләм шәйхе булган Сафийуддин әл-Һиндий дә килде. Әлеге сәбәптән, үткән мәҗлестә гаепле дә, җаваплы да, соралучы һәм җавап бирүче, мөфти һәм казый булып, бер үзе бөтен мәҗлесне тотып утырган Ибне Тәймияне мәҗбүр итәргә җыендылар. Ибне Тәймиягә каршы сүз сөйләр өчен Камаледдин әл-Зәмәлкәний билгеләнде. Ибне Тәймиянең иң зур дошманы булган Ибне әл-Вәкил мәҗлесләрнең башыннан ахырына кадәр булыр иде. Мәҗлес ачылу белән Ибне Тәймия әлеге рәвештә нотык сөйләргә кереште: “Аллаһ Тәгалә Коръән Шәрифтә: **“Барыгыз да бергә Аллаһның бауына тотыныгыз һәм аерылмагыз[1]”**, - дип бердәм һәм дус булу боера, бүленү һәм тарткалашудан тыйды. **“Аларга ачык аңлаешлы аятьләр килгәннән соң бүгәләнүчеләр һәм**

[1] “Әли Гыймран” сүрәсе, 103 аять

**тарткалашучылар кебек булмагыз[1]"**, - диде. Безнең Иләһебез бер, Китап һәм Пәйгамбәребез бер. Динебезнең асылында бүлгәләнү һәм каршылыклы булу мөмкин түгел. Шул сәбәптән мин әһле Исламны сәләф мәзһәбенә дәгъват кылып, каршылыкта булуларын кире кагам. Бездән алда булган өммәтләрнең һәм дәүләтләрнең бозылуларына сәбәп булган бәлаларгә мөселманнарның дучар булуларыннан гаять куркам. Инде бу мәҗлестә сөйләшүдә хикмәт юк, безнең низагыбыз монда өзеләчәк түгел, шуның өчен мин үзем солтан янына барам, тиешле җавапларны аның каршында сөйләрмен. Һәр урынның үзенә күрә сүзе бар. Солых вакытында булган сүзләр белән сугыш вакытында булган сүзләр башка төрле булыр. Бу мәҗлестә булган кешеләр берсе үзенең хәнбәли икәнлеген, икенчесе әшгарий икәнен дәгъва кыладыр, араларында булган каршылык һәм фетнәләрнең очы-кырые юк, әмма дөреслекне һичберсе белми, һичберсе үз мәзһәбен аңламый. Аңламаган нәрсәләр хакында сөйләшәләр, аңламаган хәлдә дәгъва кылышалар. Әлеге мәзһәбләрнең уртак фикергә килү, берләшү чарасын үткән мәҗлестә сөйләдем".

Ибне Тәймия нотыгын шул җиргә җиткергәннән соң мөселманнар арасында булган каршылыкларның сәбәп һәм фәлсәфәләрен, тарих һәм шәхесләрен сөйләргә керешә. Могтәзиләләрне сөйләгән вакытта мәҗлестә булган олуг һәм мөгътәбәр бер шәйх Ибне Тәймиягә мөрәҗәгать итеп: "Исламда булган беренче каршылык "фасыйк мөселман мөэминме кәферме" сүзе булды, дип ялгыш сөйләдең, бәлки беренче каршылык кәләм мәсьәләсендә булды", - диде. Моңа исә Ибне Тәймия: "Бәхәс алып бару шәригать рөхсәт иткән эш, фәкать моның үзенә күрә бер тәртибе бар, бу рәсми бер мәҗлес булганга хөрмәтле бер мәҗлес булса кирәк. Монда үзенә күрә әдәп булырга тиеш. Әбәпсез адәм фазыйләтсездер. Миңа әбәпсез мөрәҗәгать иттең, хәлбуки сүзең, үзең кебек итеп әйтер булсам, ачык ялгыштыр, дип әйтү тиеш булыр. Кәләм хакында булган каршылык иң беренче буларак Мәэмүн халифә вакытында мәйданга чыкты, әмма фасыйк мәсьәләсе һәм шуңа бүленгән могтәзилә фиркасы Хәсән Басрий вакытыннан соң Гомәр һәм Габид вакытында килеп чыкты. Боларның арасында никадәр заман барлыгын бу мәҗлестә белүчеләр булса кирәк, Исламда килеп туган бидгатьләрнең тарихлары һәм мәйданга чыгаручыларның тәрҗемәи хәлләре, аның сәбәпләре тулысынча хәтеремдә, бу мәсьәлә хакында Шәһристаниның бераз хатасы бар", - диде.

Әлеге шәйх: Әхмәд Ибне Хәнбәл үзе олуг галимдер, аның турында сүзебез юк, әмма аңа иярган адәмнәр арасында бозык адәмнәр дә бар.

Ибне Тәймия: Моны кире кагучы булмас. Имам Мәлик, Әбү Хәнифә белән Шәфигый да бөек адәмнәрдер, ләкин аларга иярүчеләрнең дә һәрберсе фәрештә түгел, араларында бәлки бозыклар да бардыр. Болар бер якта торсын, хәзрәти Гыйсә белән Мөхәммәдкә иярүчеләр арасында бозык адәмнәр булуы мөмкин. Карматыйлар, батыйнилар барысы да Мөхәммәдкә иярүне дәгъва кылырлар. Хәлбуки аларның гамәлләре һәрберегезгә мәгълүм. "Әхмәд Ибне Хәнбәлгә иярүчеләр арасында бозык кеше юк" дип дәгъва кылучы булмаганга һәм безнең сүзләребез шундый бер дәгъвага дәлил булмаганга, мондый гыйлем мәҗлесендә шундый бер мәгънәсез сүзне чыгаруда хикмәт юктыр. Һәрнәрсәне белеп һәм аңлап сөйләргә кирәк. Бу урын Ибне әл-Хатыйб ялганнары сатыла торган базар түгел.

Әлеге мәҗлесләрдә Ибне Тәймиянең гаебе исбат ителмәгәнгә эшләр элекке хәлендә калды. Ибне Тәймия исә, моннан соң рифагыйлар төркеменең бидгать гамәлләрен кире кагарга керешә һәм кәрамәт исеменнән халык хозурында күрсәтелгән хәйләләрнең асылларын һәм серләрен ачып бирде һәм: "Рифагыйларның утка кереп янмаулары кәрамәт түгел, бәлки хәйләдер. Әгәр дә моны исбат итү хаҗәт булса рифагыйлар мунча кереп тәннәрен эссе су һәм серкә белән юсыннар шуннан соң утка керсеннәр", дип, танырга мәҗбүр итте, һәм: "Могҗиза дөрес булган тәкъдирдә дә әүлиялеккә дәлил түгелдер, Ислам

[1] "Әли Гыймран" сүрәсе, 105 аять

әһле өчен тотыныр нәрсә ялгыз Коръән һәм Сөннәттер, боларга каршы килүче кеше кулында йөз төрле могҗиза булсын, кыйммәте юктыр”, - диде.

Димәшкъ мәҗлесе сәбәбеннән бер зарар килмәгәнен һәм аның өстенә ишаннар хакында шундый сүзләр сөйләгәнен ишеткәннән соң, югарыда телгә алынган шәйх Мәнбәҗий тагы да Ибне Тәймия зарарына тырышырга кереште, “гакыйдәсе бозык, үзе бидгатьче, ишаннарга каршы” дип, гаепле күрсәтеп, түрәләр ишекләрендә йөрде. Солтан тарафыннан Ибне Тәймия җавап өчен Мисырга чакырылды. Гәрчә Димәшкътә булган урынбасар: “Без гомуми мәҗлес төзеп Ибне Тәймиядән җавап алдык, аның хакында гаеп исбат ителмәде, аның гакыйдәсе сәләф гакыйдәсе икәне мәгълүм булды”, дип әйтеп караса да, Мисырдан шуның өчен ниятләп килгән түрә: “Мин үземә боерылган бер эшне җиренә җиткерергә мәҗбүрмен”, - дип, урынбасар сүзен кабул итмәде.

705 ел 12 рамазан дүшәмбе көн Ибне Тәймия Димәшкъ шәһәреннән Мисырга сәфәр итте. Бик күп кешеләр, бигрәк тә шәкертләре елап озатып калдылар, дошманнары, табигый, шатландылар.

Мисырга кергәннән соң аның хакында мәҗлес төзелеп, Шәмседдин Гадлән исемле зат аны гаепләүче итеп билгеләнеп, әлеге рәвештә мәҗлес башланды.

Гадлән: Каршыгызга килгән Ибне Тәймия Аллаһ Тәгаләне хакыйкый мәгънәсе белән “гарше өстендә”, хәреф һәм тавыш белән сөйләшә һәм Хак Тәгаләгә хисси ишарат мөмкин дип дәгъват кыла. Мондый нәрсәләр Ислам диненә каршы икәнлеге мәгълүм, шуның өчен катгый җәза бирүегез сорала.

Казый Ибне Мәхлуф (Ибне Тәймиягә мөрәҗәгать итеп): Әй, фәкыйһ, ни дип җавап бирерсең?

Ибне Тәймия: Әлхәмдү лилләһ...

Казый Ибне Мәхлуф: Җавабыңны сөйлә! Без сине монда хотбә укырга чакырмадык.

Ибне Тәймия: Бу мәҗлестә минем хакымда казый кем булачак?

Бер кеше: Мәликиләр казые Ибне Мәхлуф синең эшең хакында казый итеп билгеләнде.

Ибне Тәймия: Ибне Мәхлуф ни өчен минем хакымда казый була алсын? Хәлбуки, минем зарарыма тырышучыларның берсе Ибне Мәхлуфтер. Дошманлык итүче һич вакыт казый булмас, мондый эш шәригатькә сыймас. Казые дәгъвачы булган мәхкәмәдә гаделлек булырмы?

Ибне Тәймияне әлеге сүзләре өчен төрмәгә яптылар. Шулай ук ике туганы - Шәрәфеддин Габдулла белән Зәйнеддин Габдеррәхим, өчесе бергә төрмәгә ябылдылар.

707 елда төрмәдән чыгарылып, тагын бер мәҗлес булды исә, Ибне Тәймия зарарына бер нәрсә исбат булмады. Бу юлы төрмәдә булган гомере 18 ай булды. Аның төрмәдән чыгуын ишетеп кешеләр шатландылар. Мөгътәбәр галимнәрдән Нәҗмеддин Сөләйман бин Габделкави бер шигырь язып Ибне Тәймияне мактады.

Төрмәдән чыкканнан соң Ибне Тәймия беренче җомгада мәчеткә барып тәфсирдән дәрес бирергә кереште. Фатиха сүрәсенең тәфсирен сөйләп гыйбәдәт, сабырлык фазыйләтләрен аңлатты. Моннан соң башка мәчетләргә йөреп вәгазь сөйләр, хәдис һәм тәфсирдән дәрес бирер иде. Дәресенә җыелган кешеләрнең саны булмас иде. Мисыр халкында мөридлек, шәйхлек, могҗиза һәм кәрамәт, тарикать һәм шатхиять (транс) хөкем сөргәнен күрүе белән Ибне Тәймия тәсавуф хакында, хосусан “вәхдәт вуҗүд” мәсьәләләренә карата сүз сөйләргә кереште һәм “вәхдәт вуҗүд” каһарманнары булган Ибне Гарәби, Ибне Сәбгыйн, Садреддин әл-Каунавий һәм аларның тарафдарлары турында бәхәсләр кылыр иде. Ачык сурәттә кешеләргә: “Безнең Ислам динендә Коръән һәм Расүлуллаһ Сөннәтеннән башка тарикать юк, гамәлләре Аллаһ Тәгаләнең Китабына һәм

Пәйгамбәрнең Сөннәтенә туры килмәгән адәмнәр, кирәк һавада басып торсыннар, кирәк су өстендә йөгереп йөрсеннәр, әһәмияте юк. Ахирәт уңышы ялгыз Коръән һәм Хәдискә, сәләф әсәренә иярүдән генәдер", - дип, озын вәгазьләр сөйләгәндә ишаннар һәм мөридләр, тәкия[1] һәм ханәкаларда[2] ятучылар җыелып солтан каршына бардылар. Әлеге кеше диңгезен күргәч солтан куркуга төште һәм нинди ният белән килүләрен сорады. "Безнең шәйхләребезне яманлыйдыр, тарикатебезнең кыйммәтен төшерәдер, халык каршында булган игътибар һәм хөрмәтебезнең бетүенә сәбәп буладыр", - дип Ибне Тәймия өстеннән шикаять итәргә килгәннәр, дип җавап бирделәр. Әлеге мөридләрдән гыйбарәт булган чирүләрнең сәргаскәр һәм командирлары Кәримеддин әл-Әмәлий, Ибне Гата исемле ишаннар булып, бергә ияреп йөрүчеләре биш йөз чамасы мөридләр иде.

Солтан "Дәр әл-гадел" дип аталган урында мәҗлес ясап, Ибне Тәймияне чакыртты һәм сорау-җавап эшләре башланды. Ибне Тәймия үзенә хас булган батырлык һәм ныклык, күркәм сөйләме белән сүзгә керешеп, үзенең максатын сөйләде. Мәҗлеснең нәтиҗәсе бары Ибне Тәймия тарафыннан үзенең хаклы булуын исбат итүдән башка нәрсә булмады. Мөридләрнең шаулауларын һәм халык арасына тәшвиш салуларын басу максаты белән Ибне Тәймиягә кайбер шартлар белән Искәндәрия яки Мисырда яшәү, яки төрмәгә ябылу арасында сайлау мөмкинлеге бирделәр. (Әлеге шартларныңниләрдән гыйбарәт булуы хакында бер нәрсә дә күрмәсәк тә, фикерләрен, хосусан ишаннар хакында булган сүзләрен сөйләми тору булачагы мәгълүмдер). Ибне Тәймия моңа каршы: **"Әй, Раббым! Алар мине өндәгән нәрсәгә караганда төрмә миңа сөеклерәк!"**[3], дип, төрмәне сайлады һәм туры зинданга китте. Әлеге маҗараларның төп сәбәпчесе югарыда исеме телгә алынган Насыйр әл-Мәнбәҗий исемле ишан иде.

Ибне Тәймия зинданга керүе белән кешеләрнең намаз укымауларын, өем-өем булып ләчтит сатып, шакмак уйнап утырганнарын күрде. Шул сәгатьтә үк үзенең акылларны яулап алачак сүзләре белән вәгазьләргә керешә. Бер вакытларда төрмәдә азан һәм икамәтләр белән җәмәгать намазлары укылыр, гыйлем мәҗлесләре тәртип ителер булды. Зиндан кешеләре Ибне Тәймиягә, чынлыкта, күркәм холык һәм динлелеккә шул кадәр ихласлы булдылар ки, төрмәдән чыгарырга фәрман килгән кешеләр, төрмәдә Ибне Тәймия янында калуны төрмә башлыгыннан ялынып сорарлар иде. Читтән дә күп кешеләр берәр төрле сәбәп табып төрмәгә барырлар һәм Ибне Тәймия мәҗлесендә булырлар иде. Хөрмәт һәм әдәп әһелләре: "Бу җирне хәбесханә дияргә мөмкин түгел, чөнки халык үзе теләп керә, чыгарга кушмасалар ярар иде, дип куркып тора. Ишаннар тәкиясе дияргә дә мөмкин түгел, чөнки монда гайбәт һәм буш сүз юк, кеше белән булышу һәм яман холык та юк, бәлки бу җиргә "гыйлем йорты", "фәтвә йорты" дип атарга лаек", - дип, үз араларында сөйләшерләр иде. Ерак җирләрдән кешеләр, мөшкел мәсьәләләрне сорарга һәм фәтвәләр алырга килерләр. Ибне Тәймия һәрберсенең хаҗәтен үтәп торыр, кешедән бушауга, китап язу белән шөгыльләнер иде.

Ибне Тәймия дошманнары үзләренең планнары җиренә килмәгәнен һәм мөселманнар күзеннән Ибне Тәймия мәртәбәсен төшерә алмаганнарын күргәч, бер чара табу өмете белән аның "Искәндәрия" төрмәсенә күчерелүен солтаннан сорадылар. Әлеге сәбәптән Ибне Тәймия "Искәндәрия"гә җибәрелде, әмма янында барыр өчен һичкемгә рөхсәт бирелмәде. Ләкин "Искәндәрия" төрмәсе дә Мисыр төрмәсе кебек "гыйлем йорты" булды.

Әл-Мәлик әл-Насыйр бин Калун 709 елда (1309) рамазан гаете көнне Мисырга җиңеп кергәч, Ибне Тәймияне төрмәдән чыгартып үз янына китертте. Ибне Тәймия солтан

---

[1] Мөридләр ишан кул астына зекер әйтү өчен җыела торган урын.

[2] Суфиларның, дәрвишләрнең тора торган урыннары. (тәр.иск.)

[3] "Йосыф" сүрәсе, 33 нче аять

янына кергәндә мәҗлес, казыйлар һәм мөфтиләр, галим һәм шәйхләр, мөдәррис һәм мөәллифләр белән тулы булып, Ибне Тәймиягә көнчелек һәм дошманлык итүчеләрдән күпләр бар иде. Әл-Мәлик әл-Насыйрга каршы сугышырга котыртып йөрүчеләрдән мәликиләр казые Ибне Мәхлуф тә әлеге мәҗлестә булып, үзен үлем җәзасына хөкем итүләреннән куркып башыннан сөрем чыгып торыр иде. Димәшкъ мәҗлесләрендә каршы сөйләгән Камаледдин әл-Зәмәлкәний дә бу мәҗлестә катнаша иде. Ибне Тәймияне күрүе белән солтан аяк өсте торды һәм каршы барып ихтирам белән күреште һәм үз янына утыртты, күңелен күрде. Мәҗлес тәмам булгач, Ибне Тәймияне хосусый сурәттә алып калып вакыйгасын сорашты һәм бу мәҗлестә булган муллаларның сәяси гаеп сәбәпле үлемгә лаек булулары хакында сөйләде. Алар арасында Ибне Тәймиягә дошманлык кылучылар да бар иде. Бу вакытта Ибне Тәймия: “Әй, солтан! Аллаһ Тәгалә биргән куәт һәм кодрәтне яхшы эшләргә юнәлтергә кирәк. Начар юлда куллану мактала торган эш түгел. Мин зәгыйфь бер адәм булганым хәлдә үземә зарар кылучыларны, хәтта җаныма яманлык теләүчеләрне дә, гомумән гафу иттем, инде, сез әлеге куәт һәм кодрәтегез белән гафу итмәсәгез, гаеп булыр”, - дигән. Әлеге сүздән тәэсирләнгән Әл-Мәлик әл-Насыйр сәяси җинаятьчеләрнең һәрберсен кичереп азат итте. Маҗараны ишеткәч, казый Ибне Мәхлуф: “Сөбхәналлаһ! Ибне Тәймия кебек кичерә белүчене күрмәдек. Кичерүе белән бездән өстен чыккач, аңа каршы барырга һич мөмкинлек калмады”, - дип сөйләгәндер.

Солтан хозурында мәртәбәсе югары булганын күреп түрәләр, мөфти һәм казыйлар, шәйх һәм мөридләр Ибне Тәймия тирәсендә койрык болгап йөрергә керештеләр, хәтта солтан үзе һәрвакыт хас мәҗлесләрендә булдырырга теләсә дә, Ибне Тәймия боларның һич берсенә илтифат итмәде, бәлки элекке гадәте булган вәгазь һәм укыту, нәсыйхәт һәм язу эшләренә кереште. Бик күп кешеләр элекке вакыйгаларда катнашлары булуын сөйләп янында акланырга керешкәч, Ибне Тәймия: “Хаҗәт юк, мин үз хакымны кемнән генә һәм ни нәрсә генә булса да кичердем, Аллаһ Тәгалә гафу итсен!” – дип бу бәлане өстеннән җибәрде.

Кешеләрнең дөньяларына, вазыйфа һәм шөһрәтләренә һич катышы булмаганга, аннан көнләшүче һәм аның дошманы булмаска тиеш иде. Фәкать, Әбү әл-Галәэ әл-Мәгъринең: “Кешеләр холыкта барысы да бер” (кешеләр барысы да бер чыбыктан сөрелгән, дигән кебек. Тәр.иск.), “Кыз бала да, ир бала да тәрбияле булмас”, - дигәне белән килешкән кеше, гаять ерткыч һәм әхлаксыз бер хайвандыр. Аның яманлыгыннан азат булу мөмкин булмас. Бу яктан бер төркем кешеләр Ибне Тәймиянең күркәм холкына хөсетлек кылырга керештеләр. Төнлә кайтып барган вакытында бер аулак җирдә каршысына чыгып бик каты кыйнадылар. Хак Сөбхәнә вә Тәгалә Үзенә мәгълүм сәбәпләр өчен яхшыларны яманнар белән, күркәм холык ияләрен бозыклар һәм көнчеләр белән бәлаләндерүдә һәм имтихан итүдәдер. Ләкин моның бәрабәренә хөсетләрне хөсетлек хасталыгы белән һәм явызларны да ахмаклык һәм тинтәклек белән бәлаләндергән, явызны “сиҗҗин”гә (гонаһлыларның гамәлләре языла торган китап яки җиде кат җир астындагы урын) һәм яхшыны “гыйллийүн”гә (яхшы гамәлләр теркәлә торган китап, яки җәннәтнең югарысындагы урын. Тәр. иск.) кую белән вәгъдә кылган. **“Аллаһ Үз вәгъдәсен бозмас, ләкин кешеләрнең күбесе белми”** [1].

Әлеге хәлендә Мисырда беркадәр вакытлар дәвам иткәннән соң, Ибне Тәймия Мисыр гаскәре белән бергә Шам өлкәсенә кайтып китте. Гаскалан, Бәйтел-мәкъдис аркылы үзенең ватаны булган Димәшкъ шәһәренә керде. (712 елның 1 зөл-кагъдәдә). Ике туганы һәм беркадәр шәкертләре янында иде. Димәшкъта булган дуслары каршы чыгып ихтирам белән күрештеләр. Димәшкътан чыгып китү белән кайтып керүнең арасы 7 ел да 7 атна булды.

[1] “Рум” сүрәсе, 6 нчы аять

Ибне Тәймия элекке гадәте буенча дәрес, фәтвә, вәгазь һәм язу белән шөгыльләнә башлады. Әлеге вакытта талак хакында булган фәтвәсе таралып, кабат кешеләрнең гаугаларына сәбәп булды. Һәрникадәр солтан тарафыннан фәтвәдән тыйган фәрман килде[1] һәм шәһәрдә дә игълан ителсә дә, Ибне Тәймия: “Белгән нәрсәмне яшереп торырга кодрәтем җитми!” – дип, һаман үз гамәлендә дәвам иткәндер. Әлеге сәбәптән әмир 719 нчы ел 19 нчы рамазанда Димәшкъта “Дәр әл-сәгадә” дип аталган урында зур бер мәҗлес җыеп Ибне Тәймияне чакыртты һәм солтан тарафыннан тыела торып һаман фәтвәдә дәвам иткәне өчен шелтәләде. 720 нче ел рәҗәб аенда әмир тагын бер олы мәҗлес төзеп әлеге талак фәтвәсе хакында сөйләшер өчен дип Ибне Тәймияне чакыртты. Мәҗлестә шәһәрнең казыйлары, мөфтиләре һәм мәшһүр адәмнәре барысы җыелган иде. Ибне Тәймия һаман үз сүзен сөйләде һәм фикеренең дөрес булуын дәгъва кылды. Ниһаять әмир Ибне Тәймияне кальгада япты һәм тоташтан 5 ай 18 көн төрмәдә ятты. Моннан соң солтан тарафыннан фәрман килгәч, Ибне Тәймия төрмәдән азат ителде (721 нче ел 10 нчы мөхәррәмдә). Төрмәдән кайтуы белән шәкерт укытырга тотынды, һәртөрле фәннәрдән дәрес бирү белән шөгыльләнә башлады.

726 ел башында пәйгамбәрләр һәм изгеләр каберләренә гыйбадәт нияте белән зиярат итү өчен сәфәр кылу дөрес түгел дигән фәтвәсе таралгач, тагын имеш-мимеш күбәеп һәр тарафтан хурларга һәм сүгәргә тотындылар. Бу мәсьәлә шул кадәр зурайды ки, Ибне Тәймиянең иң галим һәм иң кыю шәкертләре үзләрендә куркаклык һәм зәгыйфьлек тоя башладылар, зур бер бәла килүе белән хөкем кылырлар иде. Хәлбуки, Ибне Тәймиянең үзендә һичбер үзгәреш булмас, элекке кебек сабырлык һәм ныклыкны кулыннан җибәрмәс иде.

Мисыр муллалары җыелып солтан янына бардылар һәм Ибне Тәймияне үтерү тиеш булуын аңлаттылар. Фәкать солтан үтерергә ризалык бирмәде, төрмәгә ябачагын вәгъдә итте. Муллалар исә, моңа ризалык күрсәтеп кайтып киттеләр.

Солтаннан килгән фәрманга җавап итеп Ибне Тәймия 726 нчы ел шәгъбанының 6 нчы көнендә Димәшкъ кальгасына ябылды. Хас шәкерте булган Ибне әл-Кайим әл-Җәүзияне дә аның белән бергә яптылар.

Хакыйкать хәлдә әлеге тоткынлык бер аңлашылмаучанлык нәтиҗәсе яки халык фикерле түрәләрне риза итү ниятенә нигезләнгән бер нәрсә иде. Солтан Ибне Тәймиянең зиярат өчен булган сәфәрдән тыюын зияраттан тыю дип аңлады, яки тавышны бастырыр өчен шулай аңлар булды.

Мәхкәмә һәм казый, җыелыш һәм тикшерү, тоткын һәм азат сүзләреннән исә бүгенге тәртипле мәхкәмәләрне җәмәгатьчелек гаепләүчеләре катнашында булган тоткынлыкларны күз алдында тоту мөмкин түгел. Ибне Тәймия хакында булган мәхкәмә һәм тикшерүләрдә тәртип һәм гаделлекнең исеме булу-булмавын һәркем үзе белергә тиеш. Бәлки болар авыл куштаннарының хөкем һәм тәфтишләре һәм плау мәҗлесләрендә булган муллаларның гауга һәм бәхәсләре, кашык бутап гайрәтләнүләре һәм тавышланулары кебек мәгънәсез булулары нисбәтендә әһәмиятсез нәрсәләрдер.

Мисыр һәм Димәшкъ шәһәрләрендә әлеге зиярат мәсьәләсе хакында халыклар үзләрен белмичә котырганнары хәлдә, Багдад галимнәре һәм, хосусан, гасырның олы галимнәре Ибне Тәймиягә тарафдарлык күрсәткәннәр һәм Ибне Тәймия сүзләрен дөрес санап рәсми хатлар язганнар. Фәкать бу хатлары Әл-мәлик әл-Насыйрга Ибне Тәймия вафатыннан соң тапшырылган дип уйланыла[2].

[1] 718 ел, җөмадел-ахирда

[2] Әлеге хатларның сурәтләре “Гаять әл-әмәнә”дә күрсәтелгән. №2, 199-206 б.

14 бүлек

Зиярат һәм сәфәр мәсьәләсенең кыскача эчтәлеге.

Әлеге язмада китерелгән зиярат һәм сәфәр мәсьәләләре, өстән укучыларның яки кайбер җөмләләрне генә күрүчеләрнең ялгыш аңлауларына сәбәп булмасын өчен Мәдинә сәфәре һәм каберләргә зиярат турында бер кадәр ачыклап бу бүлекне язарга кирәк таптык. Мәсьәләне исә түбәндәге маддәләргә бүләргә мөмкин:

1) **Мәчет Шәрифне[1] һәм Пәйгамбәребез каберен зиярат итү**. Кирәк Мәдинәдә электән торсын, кирәк нинди дә булса бер ният белән генә Мәдинәгә читтән килсен, бу кеше өчен мәчетне һәм Пәйгамбәребез каберен зиярат итү яхшы бер гамәлдер, әһле Ислам галимнәре арасында монда игътибарга алырлык низаг юк. Әгәр дә Мәдинәгә барып бу вазыйфаны үтәмичә чыгып китсә, хәрам эш кылган дип саналмаса да, гонаһлы булмаса да, фазыйләтле эшне, күңел кушуы буенча үтәлергә тиешле бер бурычны үтәмәгән булыр.

**2) Мәдинәгә сәфәр**. Сәяхәт һәм сәүдә кебек дөньяви ниятләр белән Мәдинәгә сәфәр итәргә һәркем ихтыярлы булып, теләгән вакытта һәркем өчен бару-кайту шәригать каршында тыелмаган. Бу турыда низаг юк.

**3) Мәчетне зиярат итү өчен сәфәр.** Мәчет Шәрифне зиярат итү нияте белән Мәдинәгә сәфәр кылу саваплы һәм фазыйләтле бер гамәлдер. Бу турыда да һичкемнең низагы юк.

**4) Кабер Шәрифне зиярат итү нияте белән сәфәр кылу.** Чынлыкта, низаг маддәсе шушыдыр. Ибне Тәймия бу сәфәрне тыйган хәлдә (сәбәпләре аңлатылды) чордашлары моны тыймаслар, бәлки 3 нче маддә кебек моны да саваплы һәм фазыйләтле бер гамәл санарлар. Мәчетне ниятләп сәфәр кылудан соң кабер шәрифне зиярат фазыйләтенә ирешү дә мөмкин булганга, әлеге низаглы маддәдә ике тараф максатларын берләштерү мөмкиндер. Шуңа күрә бу низагда күп әһәмият булмаса кирәк.

**5) Расүлуллаһ кабереннән башка каберләрне зиярат итү өчен сәфәр кылу.** Моны исә Әбү Мөхәммәд әл-Җивайни белән Ибне Тәймия хәрам диярләр. Казый Гийад тә әлеге тарафта. Башкалар исә дөрес санарлар.

**6) Сәфәргә хаҗәт булмаган зиярат.** Моның дөреслегендә дә игътибарга алырлык низаг юк. Фәкать хәрам эшләрне, ширек яки шуның мисалында булган тыелган гамәлләрне эченә алган булса, ул вакыт зиярат гомумән хәрам булуын ачык әйтәләр.

Пәйгамбәребезне ярату, аны ихтирам итү, өммәт өчен фарыз булуында һәм Расүлуллаһ хәзрәтләренең дәрәҗәсе Хак Сөбханәһү вә Тәгалә хозурында бөек икәнлегендә шөбһә юк. Пәйгамбәрләр Аллаһ Тәгаләнең итагатьле бәндәләре булуы хакында шәргый дәлил күптер. Фәкать әлеге мәхәббәт һәм ихтирам әсәрләрен һәркем үзе теләгәнчә белдерсенме, яки Китап-Сөннәт тарафыннан өйрәтелгән сурәттә белдереп, шулардан һич бер тарафка тайпылмасынмы? Чынлыкта Ибне Тәймия соңгы юлны ихтыяр иткән һәм көндәшләре исә, шуңа каршылык күрсәткәннәрдер.

Чынлыкта, кешеләрнең зәвыклары һәм күңел теләкләре күп вакыт үзләре сөйгән нәрсәләргә һәм гадәтләргә туры килеп, ярату тәэсире белән, үзалдына файдасыз булган бер сыйфат макталырга һәм гадәт хөкеменә мәҗбүрият белән икенче бер гүзәл сыйфат түбән күрелергә мөмкин. Төрле милләтләрнең берсе каршында кире кагылган гадәтләрнең башкалары каршында яхшы күрелүе шуңа нигезләнәдер. Яланбаш тору бер кавем каршында ихтирам галәмәте булган хәлдә, икенче бер кавем карашынча илтифатсызлык галәмәте икәне мәгълүмдер. Шуның өчен кеше үз зәвыгына һәм күңеле тартканга нигезләнеп кылган ихтирам галәмәтләрендә хаталанырга мөмкин. Шуңа күрә күңел

[1] Мәдинәдәге Пәйгамбәребез мәчете. Тәр.иск.

дөреслек Ибне Тәймия тарафында булуына тартыла. Әмма хакыйкать хәл исә Аллаһ Тәгаләнең Үзенә мәгълүмдер.

Мисыр галимнәреннән Госман бин Мөхәммәд әл-Шәмсий, Сәед Әхмәд Бәдәвийгә мөрәҗәгать итеп:

Әй Бәдәвий, әй, минем омтылышым һәм теләгем,
Әй, болгавыр көн кызуыннан саклаучым.
Мин синең яклавың астында, ә син ярдәм,
Боларны сөйләүченең өметләре акланмаудан сыенам,
Коткар аны һәм олуглык, шатлык белән көндер тәкъвалык юлына, - дигән догасы яман гадәт бәласе икәнлегендә шөбһә юк. Нигә дисәң, хакыйкать хәлдә Сәед Бәдәвийне әлеге эшләргә кодрәтле иләһ дип ышанмый булса кирәк, ин-шәә Аллаһ. Хак Сөбхәнәһү вә Тәгаләдән башкага мондый үрнәктә мөрәҗәгать итүне һәм доганы ишеткәндә һәркемнең күңеле чирканыр. Әлеге рәвештә олыланган Бәдәвий, җәннәттә булулары белән шатландырылган яхшылардანмы, әллә “сиҗҗин”дә булачаклары хакында вәгъдә ителгән яманнарданмы иде? Моны белергә бик күп эшләр бар. 1123 елда Мисырда “Җәмигъ әл-муәйид” мәчетендә булган бер вәгазь сөйләүче: “Әүлиялар дип санаган кешеләрегезнең каберләренә кандиллар, шәмнәр яндырмагыз, төрбәләргә биналар салмагыз, каберләрен үпмәгез! Мондый нәрсәләр көферлек һәм ширектер. Шәграний үзенең дәрәҗәсендә кайбер вәлиләр ләүхелмәхфузны күрерләр, дип хата сөйлидер, алданмагыз! Ләүхелмәхфузны күрү вәлиләргә түгел, пәйгамбәрләргә дә насыйп түгелдер”, - дип сөйләгәч, Мисырда булган иң бөек галимнәрдән Әхмәд әл-Нәфравий белән Әхмәд әл-Хуләйфий исемле затлар тарафыннан: “Әлеге вәгазьче сүзләре шәригатькә каршыдыр, хакимнәр тарафыннан тыелырга тиешле”, - дип фәтвә игълан ителде. Хәлбуки, әлеге фәтвә дә бозыклык ярату нәтиҗәсеннән башка түгел иде. Әлеге галимнәр үзләренең күңелләре тарткан нәрсәне шәригать урынына куялар һәм шуңа карап фәтвә төзиләр. Ахырда бу вәгазьче әлеге юлда корбан булды, уң меңнән артык Коръән-хафиз булган шәһәр эчендә **“Минем Раббым Аллаһ, дип әйткән өчен кешене үтерәсезмени?”[1]** – дип әйтүче табылмады. Бу турыда булган сүзләрнең ахыры юк, инде бу кадәресе җитсә кирәк.

## 15 бүлек

### Ибне Тәймиянең соңгы көне.

Ибне Тәймия Димәшкъ кальгасында 27 ай тоткын булып торганнан соң хасталанып вафат булды. Вафатыннан бер ай элек янында булган китаплары, каләм һәм кара савытлары, кәгазь һәм дәфтәрләре алынды, үзе дә бөтен вакытын Коръән Шәриф укуга һәм гыйбадәт кылуга билгеләде. Бу юлы ябылуында 81 тапкыр Коръән Шәриф хатем итүе әйтелә.

Хәле авырайганны ишеткәч Димәшкъта булган вәзир, Ибне Тәймия янына барып рөхсәт сораган һәм рөхсәт булгач, кереп: “Бу бәлаләргә төшүгә ихтимал минем дә катнашым булгандыр”, дип гафу үтенгән. Ибне Тәймия исә: “Гафу үтенергә хаҗәт юк, мин хакымда ни кадәр хаксызлык күрсәтсәләр дә, ниятләренә хөрмәт йөзеннән гафу иттем, чөнки, әгәр дә минем хак юлда икәнемне һәм үзләренең аңламауларын белсәләр, әлбәттә минем зарарга тырышмаслар иде. Алар минем хакымда нинди генә гонаһлар кылсалар да, үзләрен хаклык өчен тырышабыз дип уйладылар. Үз гакыйдәләренә күрә Аллаһ Тәгаләнең ризалыгына

[1] “Гафир” сүрәсе, 28 аять

ирешү өмете белән хәрәкәт иттеләр. Пәйгамбәребезгә дошманлык нияте катышмаган булса, минем хакымда ни кадәр яманлык итсәләр, итсеннәр, һәрберсен гафу иттем", - дигән.

Вафат булу хәбәрен ишеткәч шәһәр халкы шашып калды һәм һәркем эшен ташлап җеназасына җыелдылар. Гозерлеләр яки Ибне Тәймиягә дошманлыклары белән билгеле булулары сәбәпле халыкның һөҗүменнән курыккан кешеләрдән башка, җеназага иярмәгән адәм шәһәрдә калмады. Җеназада булган хатын-кызлар гына да унбиш мең кадәр иде диләр.

Әгәр дә халыклар Ибне Тәймиянең шәхесенә дошман булсалар, моның кебек вакыйгалар булмас һәм күзләреннән бу кадәр яшьләр акмас иде. Чөнки мондый нәрсәләр дөрес бер мәхәббәт һәм дуслык җимешләредер. Ибне Тәймия хакында булган дошманлык, коткылар сәбәбеннән кайбер фетнәчеләр тарафыннан мәйданга чыккан һәм бу затлар үз үлчәүләреннән югары булган бер гыйлем һәм омтылышка дошманлык иткәннәрдер. **"Кеше һәлак булсын, аны көферлеккә нәрсә кертте соң?!"**[1]

Ибне Тәймия җеназасы һәрникадәр бидгатьләрдән саф булмаса да халыклар моңа акча өчен түгел, бәлки үзләренең мәхәббәтләре сәбәбеннән килделәр. Чөнки, бу вакытларда җеназаларда акча алышу һәм Коръән Шәриф белән сәүдә итү гадәте юк иде. Булса да, Ибне Тәймия кебек төрмәдә вафат булган дәрвиштә бакыр акча да табылмаячак иде.

Акча өчен җеназага ияру гадәтенең иң көчле урыны ихтимал, безнең Русия мөселманнарындадыр. Мондый бер гадәтне ни җирләрдән һәм кемнәрдән алганнары безгә мәгълүм түгел. Инде байлар, йорт-җирләре, ат-арбалары белән ярышканнары кебек, каберләрдә һәм җеназаларда таратылган акчаларның күплекләре белән дә мактаныша башладылар. Шуның өчен Русия мөселманнары арасында җеназаларда кеше күплеге мәетләрнең гыйлем хөрмәтләреннән, динле һәм кешелекле булуларыннан бигрәк, байлык һәм ярлылыклары белән бәйле булыр. Өйләренең почмакларын мәчет итеп, гомерләрен игътикяфларда кичергән карчыклар, маңгай тирләре белән гаиләләрен хәләл кәсептән ризыкландырып балаларын укытуда булган картларның җеназаларын укыр өчен бик аз кеше булган хәлдә, көч куллану һәм хыянәт юллары белән байлык тәхсыйл иткән һәм гомерләрен мал туздыру җирләрендә кичергән бик күп исерек һәм азгын байлар җеназаларына ераклардан кешеләр килер, кабактан-кабакка йөрүче хулиганнар, ат каракლары, кесә каракларының һәрберсе башларына бүз урап җеназада шиксез катнашыр. Гомумән, Русия мөселманнарында таралган мондый нәрсәләр, хакыйкатьтә гыйбадәтләрнең әһәмиятен җибәрә һәм үлем кебек дәһшәтле хәлләрнең мәгънәви тәэсирләрен бетерәдер. Ислам кебек бөек һәм бөеклеге дәрәҗәсендә рухани булган бер дингә карата, дин исеменнән буларак мондый нәрсәләрнең ябышуына сәбәп булган һәм моның кебек хисләр юкка чыгарачак эшләрне яклау, дөресрәге, бетүен кабул итмәү бер җинаятьтер. Акча өчен җыелган кешеләрнең йөзләренең, меңнәренең җеназаларына караганда, ихластан Аллаһ ризалыгы өчен уку шарты белән бер кеше җеназасы өстен булачагында шөбһә юк. Акча янында ихласлык булмаячыгы да мәгълүмдер. Шайтан янында һичвакыт Аллаһ ризалыгы булмас, кеше һичкайчан ике тәңрегә гыйбадәт кыла алмас. Шуның өчен дини мәрасим белән дөньяның бәйләнешен бер көн элек кисәргә кирәк. Хосусан, җеназаларда акчалар алышу, Коръәннәр хатем кылдыру, гүр садакалары, шуның кебек башка исемнәр белән мал тарату, мәетнең өчен, җидесен, кырыгын, елын үткәрү кебек нәрсәләрнең һәрберсен бетереп, бу хәлләрне сәгадәт гасырында булган хәлгә кайтарырга һәм хакыйкать хәлдә Ислам диненең максатына туры килгәнчә үтәлергә тиешле. Динендә ихлас һәм Пәйгамбәребезгә мәхәббәте булганнар һәрберсе моның өчен гайрәт итәр булса, әлеге элгәреге мөселманнар әсәрләре тергезеләчәгендә шөбһә юк. Расүлуллаһ исән вакытында газиз балалары дөнья куйдылар

[1] "Габәсә" сүрәсе, 17 аять

һәм хөрмәтле хатыннары вафат булдылар. Соңыннан үзе дә бу дөньяны калдырып китте. Халифәләре һәм сәхәбәләре дә ахирәткә күчтеләр. Һичберсенең җеназаларында акча алмашмадылар, тәһлил әйтмәделәр, Коръән хатем кылмадылар, кабер садакалары бирмәделәр, өче, бише, үткәрелмәде, каберләрендә игътикяф сакланмады, мөҗәвирләр куелмады, мәчетләрдә һәул исемле намаз укылмады.

Садака бирү һәм хәерле мал калдыру бик гүзәл эш, монда низаг юк. Фәкать мондый эшләр мөселманнарның әхлакларын бозмаслык, милләт һәм иҗтимагый тормышка зарар китермәслек рәвештә булырга тиешле. Үзенең соңына мөлкәт калдырачак кешеләр мәңгелек вакыфлар ясарга, хәйрия җәмгыятьләре яки ышанычлы вәкилләр аркылы милләт һәм дин өчен файдалы урыннарга сарыф иттерү тиешле. Садака алучы күбәйтүне түгел, бәлки һөнәр әһелләрен һәм яхшылык эшләүчеләрне күбәйтү юлына тотарга тиешле. Гыйбадәтләр белән сәүдә итү, дин Ислам мәрасимен кәсеп рәвешенә китергән өчен Хак Тәгалә дә, шулай ук Илчесе дә риза булмасалар кирәк. “Хәерлене тыючылар” хакыйкать хәлдә мөселманнарның әхлакларын бозучылар һәм югары омтылышларда өлешсезлекләренә сәбәпләр хәзерләүчеләр булса кирәк. **“Аллаһ үзе теләгән бәндәсен туры юлга күндерә”** [1].

Йомгаклау

Өммәтләрнең алга китүләре һәм түбән төшүләре, куәт алу һәм бетүләре үзләрендә ныклык тапкан гакыйдәләренә нигезләнер. Дөньяда булган инкыйлабларның һәм иҗтимагый хәяттә булган сәяси һәм икътисадый, гыйльми һәм әдәби көрәшләрнең күчәре дә “гакыйдә”дер. Шулай ук, мәдәнияттә булган һәртөрле ачышлар, дини һәм гыйльми яңарышлар һәм үзгәрешләрнең нигезе дә “гакыйдә”дер. Адәм балалары арасында хөкем сөргән дәгъва һәм низаглар, берләшү һәм каршылыклар, хәят сәфәрендә булган мәшәкать һәм авырлыкларның бөтенесе дә “гакыйдә” җимешедер.

Гакыйдәләре юлбашчылык хезмәтен күрсәткән иң түбән милләтләр югары чыгарлар һәм гакыйдәләре мәҗбүр иткәнлектән иң көчле өммәтләр түбән төшәрләр, бәлки бөтенләй тар-мар булып бетәрләр, кайбер кәгазьләрдә исемнәре һәм тарихчылар күз уңында азмы-күпме ядкәрләре калыр.

Шуның өчен бер кавемнең алга баруы күрелсә гакыйдәсе тикшерелергә һәм бер кавемнең, киресенчә түбән китүе сизелсә, гакыйдәсе тикшерелергә һәм шуңа күрә чарасын күрергә тиешле. Бу кагыйдә милләтләр, кавемнәр һәм кабиләләр, ыруларга түгел, хәтта аерым кешеләргә дә кагыладыр. “Аллаһ Тәгалә миңа бәхет бирмәде, миңа насыйб юк имеш”, дип күңеле төшкән кеше ач торырга, “кеше кулыннан килгән эш, ни өчен минем кулымнан килмәсен? Мин түбәнлектә яшәргә риза түгел, җаным тәнемдә булганда тырышачакмын!” гакыйдәсендә булган кеше күпме-азмы үзенең кәсебенең нәтиҗәсен алырга хөкем ителгән. Шуңа күрә бер милләтне алга җибәрү кирәк булса, һәр нәрсәдән алда гакыйдәләрен төзәтү тиеш булыр.

[1] “Бәкара” сүрәсе, 213 аять

Бөтен һөнәрләре бер-берләре белән талашып, үтерешеп торудан гыйбарәт булган гарәпләр, Ислам динен кабул итүләре белән яңа бер хәят кәсеп кылдылар, үз араларында туганлык пәйда кылып бер фикергә җыелдылар, бер кулларында сөңге, икенче кулларында Коръән Шәриф булганы хәлдә тау араларыннан чыгып киң дөньяга таралдылар, мәмләкәтләр һәм шәһәрләр кулга төшереп хуҗалык итәргә керештеләр. Император һәм шаһ дәүләтләренә варис булып, җир йөзен хәрәкәт мәйданы иттеләр. Әли-мунзир, гассанилар, химярилар хөкүмәт сөргән урыннар Ислам бишеге булды, һәр җиргә Ислам байрагы утыртылды, дөнья йөзе Ислам әсәре белән төзелде. Сәфәр йөрү иң читен булган бер вакытта мөселманнарның кәрваннары көньяктан төньякка, көнбатыштан көнчыгышка үтеп йөрер иде. Бер мөселман өчен эшсез тору, башкасының малына кызыгу һәм кул сузу кадәр гарьлек эш булмас, зур бер завод эчендә булган конвейердагы хәрәкәт кебек бөтен Ислам дөньясы аңлатып булмас дәрәҗәдә хәрәкәттә һәм эштә булыр иде.

Әлеге могҗиза булган инкыйлабның һәм гаҗәп булган активлыкның сәбәбе нәрсәдә иде, гаҗәп?! Моны сорарга хаҗәт юк, "гакыйдә" үзгәрү иде. Коръән Шәриф: **"Ул Аллаһ сезнең өчен җир йөзендә булган нәрсәләрнең барысын халык кылды"[1], "Һәм аңа сугыш киемен ясауны өйрәттек"[2], "Дөньядан булган үз өлешеңне дә онытма"[3], "Кешегә үзе кылган гамәленнән башкасы булмас"[4], "Әгәр намаз укылса, җир йөзендә таралыгыз һәм Аллаһның нигъмәтләреннән ризыгыгызны эзләгез"[5], "Ул Аллаһ, анда Аның әмере белән кораблар йөзеп йөрсен һәм сез Аның нигъмәтләрен тапсын өчен, сезгә диңгезне буйсындырды, бәлки сез шөкер итүчеләрдән булырсыз! Һәм Ул күкләрдә һәм җирдә булганнарның барысын да сезгә буйсындырды. Бу нәрсәләрдә, әлбәттә, фикер йөртүчеләр өчен гыйбрәтле билгеләр бар!"[6], "Ул (Аллаһ) сезнең өчен җирне түбән кылды, дөнья буйлап йөрегез, (Аллаһның) ризыкларын ашагыз, соңыннан Аңа әйләнеп кайтырсыз"[7]** кебек хисапсыз аятьләр һәм: *"Берәү дә үз кулы белән эшләп тапканнан да хәерлерәк ризык ашамады, Аллаһның пәйгамбәре Дауд галәйһиссәләм дә үз кулы белән эшләп ашады". "Сезнең берегезнең урман кисеп аркасына бер бәйләм утын салып кайтуы, аңа бирә яки бирми торган кешедән ни дә булса соравыннан хәерлерәк". "Әгәр бер мөселман агач-куак утыртса яки иген чәчсә һәм шуннан кош, кеше яки хайван ашаса, ул садакадан булыр"[8]*, кебек сансыз хәдисләр, әлеге ялганчы, әхлаксыз гарәпләрнең "гакыйдә"ләрен үзгәртеп, туры бер юлга кертеп җибәрде.

Әгәр бу сәламәт гакыйдә мөселманнарда дәвам итсә иде, бүгенге франкларда булган мәктәпләр, аларда булган укучы һәм укытучылар, галим һәм һөнәрчеләр, эзләнүчеләр, тикшеренүчеләр, фабрика һәм заводлар, төзүчеләр һәм инженерлар, табиб һәм профессорлар, чын мәгънәсендә булган мәдәният Ислам дөньясында барлыкка киләчәк иде. Кызганыч ки, соңгы мөселманнар элеккеләр юлыннан йөрмәделәр. Адәм баласы сәгадәте һәм тормышы өчен кирәк булган кәсеп һәм ачышларны дин исеменнән тыйган дин сәүдәгәрләренең сүзләренә колак салдылар. Христианлыктан алыпмы, яки фикерләре туры килепме, **"Гыйлемең булмаган нәрсәгә иярмә"[9],** - дип ачык сурәттә тыюга каршы буларак, Аллаһ Тәгалә тарафыннан билгеле хәбәр бирелмәгән хәлдә үзләренең ихлас баглаган кешеләренә газизлек, әүлиялык вазыйфаларын бирделәр һәм шуларны үзләренә "кәгъбә" иттеләр. Бу затлар хакында "тәкъдирне хәл итүче", "мәхлукларга ярдәм бирүче", "галәмнең

---

[1] "Бәкара" сүрәсе, 29 аять

[2] "Әнбия" сүрәсе, 80 аять

[3] "Касас" сүрәсе, 77 аять

[4] "Нәҗем" сүрәсе, 39 аять

[5] "Җомга" сүрәсе, 10 аять

[6] "Җәсия" сүрәсе, 12,13 аятьләр

[7] "Мульк" сүрәсе, 15 аять

[8] Әлеге хәдисләр имам Бохари җыентыгыннан.

[9] "Исра" сүрәсе, 36 аять

күчәре” дип инануларыннан, табигый, максатларын шуларга белдереп, аларның рухларыннан ярдәм сорар һәм аларга өметләнеп дога кылыр иделәр.

Җимерек фабрика кебек, мондый бер гакыйдә тәэсире буларак Ислам дөньясы тәмам эшсез һәм җимерелеп калды, Аллаһ Тәгаләнең бер-беренә бәйләп төзегән һәм **“Аллаһның сөннәтендә (канунында) үзгәреш тапмассың”,**[1] дип сыйфатланган галәм фабрикасына әһәмият бирелмәде.

Кодрәт белән төзелгән машинага каршы тору һәм табигатькә каршы хәрәкәт итү зарардан башка нәтиҗә бирмәс. Чөнки елгаларны киртәләр белән һәм бураннарны чыпталар белән буып тоту кулай түгелдер.

Ислам дөньясының җимерелеп калуын һәм сәмави гакыйдәләр урынына хорафәтләр хөкем сөрә башлаганны күргәч, дошманнар мондый хәлне табыш дип белделәр һәм форсатны кулдан ычкындырмас өчен җан атып гамәлгә керештеләр һәм һәр тарафтан һөҗүм иттеләр. Элгәреге мөселманнардан мирас булып калган байлыклар һәм җәннәт мисалында булган гүзәл-гүзәл мәмләкәтләр бер-бер артлы кулларыннан китә башлады, күңелләре дә төште. Әлеге хәлләр гыйбрәт дәресләре, хисси һәм мәгънәви нәсыйхәтләр булганга гыйбрәт алырга һәм акылларны җыярга кирәк иде. Аз булса да уяну, акылга килү тиеш икән, гакыйдәләренә ияргән рухани хасталыклары табигать хөкеменә кергәнгә уяну насыйп булмады, бәлки элекке хәлләренә тагын да артыграк бирелделәр һәм гафләт шәрабларын өсте-өстенә эчеп тагын да ныграк исерделәр. Колаклары төбендә франкларның туп һәм мылтыкларының тавышлары ишетелә башлагач Ислам дөньясы шашып калды, берникадәр вакыт югалып калганнан соң дулкынланып торып ахырда үзләренең хаҗәт “кәгъбә”ләре булган каберләргә һәм мәгъбүд хөкемендә булган әрвахларга, ишаннар - (гасырдашларыбыздан бер кеше әйтүенчә) җанлы сынымнарга мөрәҗәгать иттеләр. Аллаһ Тәгаләдән ярдәм сорап Коръән Шәриф тәгълиматенә муафикъ әзерләнәсе урында мәетләрдән һәм әрвахлардан ярдәм сорарга керештеләр. Бу юл белән йөргән кешеләрнең насыйплары исә мәхрүмлек һәм бәла-казадан гыйбарәттер. Чынлыкта шулай булды да.

Бу сүзләребез гомумгә күрәдер. Юкса Ислам галәмендә сәгадәт гасырыннан бер һәм тоташ килүдә, Аллаһ Тәгаләдән башка һичкемнән курыкмауда һәм һәр җирдә хак сүзне сөйләүдә булган бер төркем бар иде. Тегеләрнең гамәлләреннән болар риза түгелләр иде. Фәкать көч башкаларда һәм фикерләр гомумия дә хилаф тарафта булганга боларның сүзләре үтмәс һәм максатлары кирәк дәрәҗәдә аңланмас иде. Хәзрәте Гали вафатыннан алып Ислам дөньясында гомуми фикер халык тарафында булып, һәр урында һәм һәр җирдә “печән базары халкы” хөкем йөрткәндер. Мөселманнарның мәшһүр адәмнәренең динсезлектә һәм көферлектә гаепләнүләре дә гомуми фикерләрнең хаклыкны җиңүе сәбәпле икәнен вакыйгаларны тикшерүчеләр белерләр.

Билгеле булганча, кайбер гонаһсыз булмаган шәхесләргә изгелек һәм әүлиялык исеме бирелсә, аннан килеп чыккан яман нәтиҗәнең очы-кырые булмас. Моның өчен христиан дөньясын җентекләп күздән кичерү кирәк. Билгеле сәбәптән, билгеле нәтиҗә килеп чыгар, бу мәгълүм бер эш, монда низаг юк. Әлеге сәбәптән электә христиан галәмендә хөкем итүдә булган хәлләр бөтенесе Ислам галәменә күчте. Әүлия һәм изгеләрнең исемнәре ризык чыганагы һәм мәгыйшәт чаралары ителде. Каберләре һәм тирә-юньнәре нәзер ашаучы дәрвишләр һәм кәрамәт сәүдәгәрләре белән тулды. Исемнәре башка булган хәлдә, асылда шул ук булган “раһбан” фиркасы оешты. Эчкерсез дуслар исемнәре хәдисләр белән уйнау сәүдәсенә мәйдан бирде.

[1] “Әхзәб” сүрәсе, 62 аять

Күп алыр өчен әүлияларның бөеклекләрен күрсәтү тиеш иде. Моның өчен гаҗәеп эшләр, могҗизалар үлчәү итеп күрсәтелде. Ниһаять, бер дөрескә ун һәм йөз ялган кушылып, хисапсыз кәрамәт һәм могҗиза кыйссалары уйлап чыгарылды. Ачыктан-ачык булмаса да, әүлия һәм изгеләргә "һәр нәрсәне бар итүче, һәр җан иясен ризыкландыручы" сыйфаты бирелде. Бер урында әһле Ислам үзләренә һөҗүм иткән дошманнары өстеннән өлешчә җиңү тапсалар, әлеге әйтелгән кешеләр бу хәлне әүлияларның ярдәмнәренә бәйләп, моны иман урынына халык алдында кабатларлар һәм көтмәгәндә җиңелү күрелсә, моны изгеләрнең ризалыклары хасил ителмәвенә (күбрәк бирелмәвенә) нигезләп, надан җәмәгатьләрне куркытырлар иде.

Шөһрәт кәсеп итү һәм дөньяны тагын да күбрәк үзләштерү өчен, алдан килгән кадәр арттыруларга ихтыяҗ булганга, кайберләре үз шәйхләрен Хозыр һәм Ильяс белән юлдаш иттерерләр һәм кайберләре тагын да уздыра төшеп Пәйгамбәребез белән сердәш иттерерләр һәм иш итеп күрсәтерләр. Кайберләре исә үз мөршидләреннән шәһәрләр яулап алдырып (ни кадәр каннар һәм җаннар коеп яуланган шәһәрләрне), дошман гаскәрләрен дә тар-мар иттертерләр. Кайберләре "мөнкирләрне" шәйхләреннән җиргә йоттырырлар һәм кайберләре ярдәм бирүчеләрнең карарлары сәбәбеннән дөнья гомерләрен озайттырырлар иде.[1] Могҗизалар һәм мактаулы эшләр турында язылган китапларда моның кебек кыйссалар, боларга охшаш маҗараларның чиге-чамасы юктыр.

Исемнәре белән сәүдә ителгән, Хак Сөбхәнәһү вә Тәгаләнең олуглыгы каршында тетрәп торачаклар дип уйланган кешеләр, үзләренә "халыкларның ярдәмчесе" кебек атамалар бирелүдә гаепле булмасалар кирәк. Чөнки алар үз хакларында мондый ялганнар һәм мондый чиктән чыккан нәрсәләр уйлап чыгарылуына, "кәрамәт" сүзенең бозып аңлатылуына һич кенә дә риза булмаслар.  Бәлки төп гаеп мондый нәрсәләр белән халык аулаучы һәм ялган белән кешеләр малын ашаучылар өстендәдер.

Бер фирка кешеләр хәзрәти Гыйсә галәйһиссәләмне аллаһ итеп алдылар һәм бер төркем хәзрәти Гали һәм аның мөхтәрәм балаларына гайре табигый булган нәрсәләрне нисбәт иттеләр. Һич шөбһә юктыр ки, бу мөхтәрәм затлар үз хакларында булган мондый гакыйдәләрдән риза түгелләрдер. "Безгә карата мәхәббәтләре көчле булганга шулай сөйләргә мәҗбүр булганнар" дип, аларны гозерле санамаслар. Шулай ук Ислам милләтенең каймагы булган Гәйләни, Ибраһим бин Әдһәм, Хәбиб Гаҗәми, Ибне Гарәби, Нәкышбәнд, Дәсукый, Бәдәви, Рифагый, Ясәви һәм башкалар да үзләреннән ярдәм сораучылардан, дин сыйфаты биреп каберләренә сәфәр кылучы һәм мал исраф итеп йөрүчеләрдән, олылау һәм ихтирам нияте белән төрбәләрендә рөкугъ һәм сәҗдәдә булучылардан, әлбәттә риза булмаслар. Илаһлыгын игътикад итүчеләр, хәзрәти Гыйсәнең хакыйкый иярченнәре булмасалар, хәзрәти Гали һәм башка имамнарны бөтен кешеләрдән өстен санаучылар һәм гонаһсыз булмаган шәйхләр хакында һәртөрле чиктән чыгуларны бизәкләп китаплар язучылар да боларның хакыйкый иярченнәреннән саналмасалар кирәк. Коръән һәм Сөннәткә туры килмәгән ихтирамнар, ихтирам булмас. Кешеләрнең зәвык һәм вөҗданнары мондый нәрсәләрдә үлчәү булырга, гореф-гадәтләре канунлаштыруга яраклы булмас. Олылау һәм ихтирамга карата бердәнбер үлчәвебез Китап һәм Сөннәттер. Дөрес акыл да боларга каршы килмәс.

Яшен тизлегендә алга бару юлында дәвам итүдә булган мөселманнар, чынлыкта шуның кебек гакыйдәләр тәэсире белән юлларында туктап калдылар, кәсеп һәм хәрәкәтләрдән тукталып, дәүләтләреннән аерылдылар. Мәктәпләр харап булды, гыйлем әһелләренең кадер һәм хөрмәтләре бетте. Һәрбер ялкау хайван ишанлык һәм һәрбер мәҗнүн галәм күчәре вазыйфасына билгеләнде. Бер очыннан икенче очына кадәр, Ислам галәме бөтенләй таркалган, мескен һәм фәкыйрь булды. Алтын хәзинәсе булган Һиндстан

---

[1] عجائب الاثار.   ج 1   ص 147

һәм гыйлем чыганагы булган Төркестан, һәрберсе әлеге гакыйдә юлында корбан булдылар. Мәракиш (Марокко) һәм Әндәлус, Мисыр һәм Төрекмән әлеге фикер җимешләре буларак җан бирделәр. Элгәреге мөселманнар гыйлеменнән һәм галимнәреннән әсәр калмады. Җитди тәкъвалык һәм ихласлык урынына рия белән нифакъ, мактанчыклык һәм күргәзмәлек барлыкка килде. Гыйфрит кебек сәламәт һәм япь-яшь кешеләр кулларына таяк һәм тәсбих тотып, гүя ишанлык иткән булып, йорттан-йортка кереп эшсез йөрер һәм әһле Ислам малларын сөлек кебек суырыр булдылар. Ни әһелләр гыйлем минбәрләренә менделәр һәм һәрбер залим, бутаучыларның һава һәм акылсызлыкларына туры килә торган сурәттә дин исеменнән фәтва төзеп золым коралы булып торырлар. Намусның, милләт сөюнең исеме дә, билгесе дә калмады. Сәхәбәләр һәм табигыйннар, галимнәр исеме дөнья малын туплау һәм шәһвәт юлларында кулланыла башлады. Бу хәлләрнең нәтиҗәсе буларак мөселманнар икътисади һәм сәяси эшләрдә артта калдылар һәм башкаларның аяк астында изелергә хөкем ителделәр. Өметсезлек, өлешсезлек һәм түбәнлек дәрьяларының иң тирән чокырларына баттылар. “Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун”.

Әрвах һәм мәетләрнең карарлары, шәйхләрнең “тәкъдирне хәл итүләре”, яшәтүләре һәм үтерүләре һәм шуның кебек башка нәрсәләр хакында булган гакыйдәләр мөселманнар арасына ни вакыт керде һәм кемнәр тарафыннан кертелгәндер, гаҗәп?! Моның кебек гакыйдәләрнең сәгадәт гасырында һәм элгәреге мөселманнар арасында булуы хакында мәгълүматыбыз юк. Пәйгмабәребез хәзрәтләре үзе чокырлар казыды, тимер сугыш күлмәкләре киде, йорт эшләрен эшләде, читек һәм башмакларын ямады. Моннан соң халифәләре дә әлеге рәвештә көн кичерделәр, маңгай тирләрен агызып һәм мең төрле мәшәкатьләр чигеп гарәп кабиләләрен буйсындырдылар, шаһ һәм император мәмләкәтләрен кулга төшерделәр. Бу юлда яшь балаларның чәчләре агарырлык вакыйгалар күп булды, һичберсендә эшләрен мәетләргә тапшырулары һәм каберләргә йөгереп гыйбадәт кылулары билгеле булмады. Кайбер залимнәр кәгъбә өстенә таш аттылар һәм кайберләре “кара таш”ны алып киттеләр, бәдбәхетләрдән кайберләре Пәйгамбәребезнең шәһәренә кереп Ислам әһлен кимсеттеләр, “пакь бакчаны” (Пәйгамбәр мәчетендә бер урын) хөрмәтсез иттеләр. Моның кебек вакытларда әрвахлар җиңү бирмәде. Мәетләр хисси һәм мәгънәви ярдәм итмәгән икән, иман белән үтүләре мәгълүм булмаган Төркестан шәйхләре, Бохара хуҗалары, Мәгъриб сәедләре ярдәм итәрләрме? Аллаһ Тәгалә тарафыннан килгән шәригать күзлегеннән караганда, мәетләрнең ярдәм бирүләре мөмкинме?

Ирләр түгел, сәгадәт гасырында хатыннар да олы вазыйфалар үтәрләр. Галәм, сәбәп галәме булганга, хасталар кебек гаҗиз һәм түбән булып тормаслар, гыйззәт белән булу, түбәнлектә яшәүдән артык, дип һәртөрле мәшәкатьләр чигәрләр иде. Кызу көннәрдә сугышларда җәрәхәтләрне бәйләп, хасталарны тәрбияләделәр, сулар ташып эчереп йөрделәр, дөресе, бу көндә булган низамлы гәскәрләрнең “санитарный” бүлекләренә йөкләнгән вазыйфаларны үтәделәр. Бу хәлләр Пәйгамбәребезнең күз уңында булды. “Кадисия” һәм “Ярмук” сугышларында ирләр белән бер сафта торып хәтта аларның уңнарына чыгып сугыштылар, Расүлуллаһ һәм башка сәхәбәләр рухларына ышанып һәм салышып тормадылар. “Мисан” сугышында мөселманнарның җиңүләренә мөслимәләр сәбәп булуы Ислам тарихларында язылгандыр. Әлеге мөслимәләр хакында франк тарихчылары: “Алар сугышта ирләрдән түбән дәрәҗәдә түгелләр, әгәр дә әсир төшәр булсалар, үз гыйффәтләрен сакларга һичкем ярдәменә хаҗәт булмаслык куәтлеләрдер”, - дип шәһәдәт бирер. Франкларның куркып һәм тетрәп торуларына сәбәп тә, моның кебек мөслимәләр тәрбиясендә үскән кешеләр булгандыр.

Милләт өстендә авыр йөк булган урам тулып йөрүче, түрләрне һәм буш урыннарны тутырып утыручы садакачылар аз булгандай, милләт малын сөлек урынына суыру өчен бик күп урыннарда “хуҗалар тавы”, “изгеләр чишмәсе” кебек нәрсәләр иҗат ителгән һәм һаман

да иҗат ителеп торудадыр, моннан мисаллар исә мәгълүм. Инде бер мәртәбә беренче мөселманнарга карагыз да, бер мәртәбә соң мөселманнарга күз салыгыз! Арада булган аерма шул дәрәҗәдә зурдыр ки, хәтта бер-берсенә бәйләнеш барлыгын аңлау да мөшкел булыр. Инде әүвәлге арысланнар урынына маймыллар, хакыйкый галимнәр урындыкларына чикмән калыплары утыргандыр. Күңел күзләре сукыраймаган кешеләрнең һәрберсе моны күрер, белер, кире кагарга вөҗданы рөхсәт итмәс.

Әгәр дә мөселманнар өчен бәхетле тормыш һәм имин бер киләчәк кирәк булса, башкаларга кол һәм кәнизәк хөкемендә көн кичерү һәм урам буйларында себерке һәм балта күтәреп эш эзләп йөрү һәм яһүди хатыннарында кучер булып гомер уздыру көтелгән өмет булмаса, Ислам динен элгәреге мөселманнар аңлаганча аңларга, мәгыйшәтләрен тиешле сурәткә куярга тиеш. Каберләргә биналар саласы урында мәктәпләр салу, кабер саклаучыларга бирәсе акчаларны гыйлем юлына сарыф итү, изгеләр чишмәләренә һәм әүлиялар каберләренә сәфәр өчен тотылачак акчалар белән шәкертләр укыту һәм милләт балаларын тәрбияләү, картлар йорты һәм шәфкать йортлары төзеп мөселман картларының мәгыйшәтләрен тәэмин итү файдалырактыр. Хосусан, дөньяви һәм табигый эшләргә дин исеме бирү һәм дин исемен Расүлуллаһ тарафыннан китерелмәгән нәрсәләр белән пычрату һич шөбһә юк, дингә каршы җинаять һәм диндә чиктән чыгудыр. **“Әй, Китап әһелләре, динегездә, хактан тыш, чиктән узмагыз”.**[1] *“Диндә чиктән чыгудан сакланыгыз, чынлыкта, сездән алда яшәгән кавемнәр диндә чиктән чыгулары сәбәпле һәлак булдылар”.*[2]

Тәкъдир ителерлек хезмәтләр[3] турындагы китапларда мактап язылачак шәхесләр хакында ишетелгән вә табылган хәбәрләрнең һәрберсен язу гадәт булып киләдер. Чыганаклар күп тикшерелмәс, тәнкыйть һәм төзәтү ысулы кагыйдә итеп алынмас, мәхкәмә фәлән кылынмас, мантыйкый кагыйдәләргә әһәмият бирелмәс. Әмма шәхесләрнең биографиясе хакында язылган әсәрләрдә һәрбер хәбәр һәм вакыйга тәнкыйть үлчәве аша кичерелер вә тарафдарлык итүдән мөмкин кадәр сакланылыр. Безнең бу язмабыз тәкъдир ителерлек хезмәтләр турындагы китап түгел, бәлки тәрҗемәи хәл (биография) булганы өчен, Ибне Тәймия хакында булган яхшы вә яман хәбәрләрне китапханәбездә булган мөгътәбәр әсәрләрдән сайлап алып бу урында яздык. Ибне Тәймия кебек, дин вә милләт юлларында булган хезмәтләре бәрабәренә даносчылык белән көн күрүчеләрнең җәфаларына тарыган мөхтәрәм затларга бүләк иттек. Бәла әһле өчен үзләре кебек бәла әһлен күрү кадәр тынычлану булмас. Әгәр дә хәлебездән килсә болар өчен бөтен дөньябызны фида кылыр идек, ләкин китапларыбыз вә каләмебездән башка безнең дөньябыз юктыр.

Пәйгамбәрләрдән башкаларны гонаһсыз дип танымаганыбыз өчен, һичкемнең бөтен сүзен дөрес вә барлык фикерен тугры дип дәгъва кылырга мөмкин түгел. Никадәр галим вә гакыллы булмасын, һәркем бер хаталык белән белер. Фәкать иҗтиһад җимеше булган хаталыклар, очраклы рәвештә табылган дөреслекләрдән күп вакытта кыйммәтле булачактыр. Шуның өчен һәр күрелгән бер хатага сугыш ачмак акыллы адәм эше түгелдер. Дөрес сүзләр кемнән булса да кабул кылынырга вә хата фикерләр кемнән булса да ташланырга тиешле. “Саф чистаны ал, тонык томанлыны калдыр”.

Бу язма хакында булган хезмәтебез төрле урында язылган нәрсәләрне вә төрле фикерләрне бер җиргә җыеп тәрҗемә итүдән гыйбарәт булды. Кирәк дип тапсалар, укучылар һәрбер мәсьәләне үзләре хөкем итәрләр вә бәхәсле урыннарда **“Әгәр берәр нәрсәдә**

---

[1] “Мәидә” сүрәсе, 77 аять

[2] Пәйгамбәребезнең хәдисе. Нәсәи, Әхмәд, Ибне Мәҗәһ риваять итәләр.

[3] Җәмгыять өчен файдалы булган хезмәтләр

**каршылыкка килеп бәхәсләшсәгез, аны Аллаһка һәм Илчесенә кайтарыгыз..."**[1] нәсыйхәте кушканча гамәл итсәләр, бәлки Расүлуллаһ ризалыгына ирешерләр. Гыйлем вә әдәб әһелләренә хас омтылыш, хаклыкны табар өчен тырышу вә хаклык алдында тез чүкмәк булса кирәк. **"Әй Раббыбыз! Безне туры юлга күндергәннән соң калебләребезне авыштырма, һәм безгә Үзеңнең рәхмәтеңне бүләк итеп бир, Син юмарт бирүчесең".**[2]

Ризаэддин бин Фәхреддин

[1] "Ниса" сүрәсе, 59 аять

[2] "Әли Гыймран" сүрәсе, 8 аять

## Сүзлек

**Ансар** – Пәйгамбәребезгә һәм Мәккә мөселманнарына ярдәм иткән Мәдинә мөселманнары.

**Бәйгать** – берәүнең хакимиятен тану һәм аңа буйсыну өчен сүз бирү.

**Пәйгамбәребезгә бәйгать** – аның пәйгамбәрлеген танып, аңа итагать итәргә сүз бирү.

**Бидгать** – элеккесенә каршы килә торган яңа бер эш, яки элек булмаган яңа гадәт.

**Вәли** – яклаучы, изге.

**Вәсилә** – чара, юл, якынаю ысулы.

**Габид** – гыйбадәт кылучы.

**Гакыйдә** – ышану, иман.

**Заһид** – күңелен дөнья белән бәйләмәгән, гыйбадәт белән шөгыльләнүче.

**Зыйһар** – ирнең үз хатынын өйләнүе тыелган туганнары, ягъни әнисе яки кыз туганы белән бертигез куюы, һәм син миңа әнием кебек, яки апам кебек, дип әйтүе. Ягъни, әнисенә өйләнү тыелган кебек, хатынын да үзе өчен тыелган дип санавы.

**Иҗтиһад** – тырышу, тырышлык кую. Дин гыйлемендә мөстәкыйль фикер йөртеп хөкем чыгарырлык дәрәҗәгә җитү.

**Иснәд** – чыганак, хәдисне тапшыручылар чылбыры.

**Иҗазәт** – рөхсәт, рөхсәт бирү. Үзләштерелгән дини гыйлемнең дөреслеген раслау.

**Иҗмаг** – бер сүзгә, бер карарга килү. Дин галимнәренең гыйльми мәсьәләдә уртак фикергә килүләре.

**Ихтиләф** – каршылыклы булу, фикер каршылыгы, үзара килешмәүчәнлек.

**Игътикяф** – гыйбадәт кылу нияте белән берәр урында, мәсәлән, мәчеттә, беркадәр вакыт чыкмыйча тору.

**Кальга** – крепость.

**Кәләм** – сүз, фәлсәфә.

**Кәрамәт** – Аллаһ Тәгалә тарафыннан тәкъва кешеләргә бирелгән гайре табигый сәләт, могҗизалы хәл.

**Кәффәрат** – гонаһны йолу өчен үтәлергә тиешле гамәл.

**Лязем** – тиеш, кирәк, мәҗбүри, зарур.

**Мохтасар** – кыска, кыскача.

**Мәзһәб** – дин гыйлемендә тоткан юл.

**Мәрсия** – үлгән кешене мактап әйтелгән сүз.

**Мәсләк** – караш, караштан чыгып алган юл, принцип, ысул.

**Мәтен** – текст.

**Мәшһәд** – изге дип саналган кеше күмелгән урын.

**Мөрид** – ишанга иярүче, аның эзеннән баручы шәкерт.

**Мөршид** – суфиларның остазы, туры юл күрсәтүче.

**Мөҗәвир** – каберлекләр сакчысы – дәрвиш.

**Мөшкел** – читен, кыен,авыр.

**Мөәллиф** – китап язучы, автор.

**Нифак** – икейөзлелек, алдакчылык.

**Раһбаният** - монаһлык.

**Рәкәгать** – намазның аягүрә тору, иелү һәм маңгайны җиргә тидереп сәҗдә кылуны эченә алган бер өлеше.

**Сәләф** – үткән заман кешесе.

**Сәхәбә** – Мөхәммәд пәйгамбәрне исән вакытында күреп исламны кабул иткән мөселман.

**Сөннәт** – Мөхәммәд пәйгамбәрнең эш-гамәлләре яки әйткән сүзләре.

**Тәвәссүл** – нәрсә дә булса, яки кем дә булса аркылы якынаю, үтенү, ялвару.

**Тәгассуб** – фанатизм, артык омтылу, артык сөю.

**Тәгъзия** – юату, сабырлыкка өндәү.

**Тәкъва** – Аллаһка итагать итүче, нык иманлы.

**Тәкълид** – кемгә дә булса иярү.

**Тәкия** – мөридләрнең ишан кул астында зекер әйтү өчен җыелып утыра торган урыннары.

**Тәсаууф** – суфилык, динне аңлауда булган серлелек.

**Фарыз** – шәригать тарафыннан боерылган гамәл, үтәлергә тиешле бурыч.

**Фирка** – төркем, партия.

**Хәбесханә** – төрмә.

**Хәез** - күрем.

**Хатем кылу**– тулысынча укып чыгу.

**Хәвариун** – Гәйсә галәйһиссәләмнең сәхәбәләре, аның пәйгамбәрлеген танып, аңа иярүчеләр.

**Әшнәлек** – танышлык, дуслык.

**Өлфәт** – дуслык, дуслашу, бердәмләшү.